# ПРОИЗВЕДЕНИЯ

В четырех томах

# Том 1

*Стихи, песни*

Казань

Татарское книжное издательство

2006

# ӘСӘРЛӘР

Дүрт томда

# 1 том

*Шигырьләр, җырлар*

Казан

Татарстан китап нәшрияты

2006

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
В97

Редколлегия:

*З.Р.Вәлиева, Т.Г.Миңнуллин,*
*Г.В.Родионов (Гәрәй Рәхим), И.М.Ибраһимов,*
*Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

**Вәлиев Р.И.**

Әсәрләр: 4 томда/Разил Вәлиев; Кереш сүз авт. М.Галиев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.

ISBN 5–298–03957–X

1 т.: Шигырьләр, җырлар (1962–2006). — 2006. — 527 б.
ISBN 5–298–03958–8
ISBN 5–298–03958–8(1т)
ISBN 5–298–03957–X
© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Вәлиев Р.И., 2006

## ЯЗМЫШКА РӘХМӘТ

Күңелдин китәрер өч нәрсә кайгу:
Йәшел чирәм, гүзәл мәхбүб, акар су.

*Г.Кандалый*

Дөньяма калын томанлы көннәр сыгылып иңгәндә, борылып карыйм да, гомеремнең кояшлы, диңгезле, кыя таулы мизгелен аерып алып, нәүмиз кинәнү тәэсирендә хатирәләргә биреләм.

Менә ул җәннәт иле...

Кайнар канлы Кавказ галибанә матурлыгын аяк астыбызга таратып ташлаган да үзе читтән генә, горур масаюлы таулар биеклегеннән күзәтеп тора. Кыялар арасыннан ургылып төшкән елгаларының дуамал кодрәтеме, пальма-лианаларындагы купшы көязлекме, үткен әҗикә исе таралган кафеларындагы чихахбили тәмеме, шәрабларында пышылдауга әверелгән назлы кайнарлыкмы — юк, әсир иткән мондагы ганимәтләрнең меңнән берен генә сурәтләргә дә каләм көчсез... Күк тәхетеннән күзәтеп, җирдә барган сугышларны бер кабындырып, бер сүндереп торган Тәңренең учына сыярлык төбәге — оҗмах белән тамугы янәшә килгән Кавказ бу!

Әле берничә сәгать элек кенә без эре, юеш карлы таңда Казан аэропортында өши-туңа самолет трабыннан күтәрелгән идек. Менә хәзер Адлер аэропортыннан Пицундага килеп җитеп урнаштык та иҗат йортының алтынчы катында абхаз кояшы астында хозурланып утырабыз. Казаннан без икәү — Разил Вәлиев тә мин. Кул сузымы арада диңгез җәйрәп ята. Сулда түгәрәк күлнең тын өслеген кытыклап үрдәкләр йөзә. Арырак — ак болытка уранган таулар. Аста — бакча, яшеллек. Гүя һәр яфрак кошка әверелеп сайрый: апрель сандугачлары өздереп кинәнә.

Әлегә безнең кәгазь-каләмгә тотынасы килми. Разил әйтмешли, мондый «рәхәтият иле»нә башта күнегергә, диңгез һавасында Казан юшкынын тәннән чыгарып бетерергә кирәк. Җәнлекләр, гадәттә, яңа җиргә күченгәч, үз өне тирәсен барлап, өйрәнеп чыга. Без дә шулай абхаз шагыйре Георгий Гулия исемендәге унике катлы иҗат йортының тирә-ягын өйрәнә башладык.

Күл кырыендагы кафега керәбез. Уртада мул ялкынлы учак яна. Чибәр егетләр эре-эре утын пүләннәрен өстәп кенә торалар. Учак ялкыны турысында бозау түшкәсе эленгән. Музыка. Бүкән өстәл, бүкән урындыклар. Алдыбызда — мамалыга (безнеңчә —боламык), шәраб. Үткен пычак белән түшкәдән кыеп алынган ит. Утырабыз истирахәт чигеп.

Ул елларда (1982) төп сүз әдәбият һәм хатын-кыз турында була торган иде (сәясәттә политбюро картларыннан көлүдән ары китә алмый идек). Разил белән янәшә булганда, «әйе»не әйе, дип, «бар»ны бар, дип кенә утыра алмыйсың. Әдәби мохиттән аерып алып кемнәндер көләргә, нинди дә булса әсәрне сүтеп ташларга уңай форсат чыга тора. Җитмәсә шәрабтан соң тел өстенә салган ысланган иттән тәндә бабалар каны, күңелдә дала иреге уяна. Рәссам кулы ясаган шикелле купшы манзарага карап, шул чорда таралган мәгълүм бер җырның сүзләрен искә төшереп көлешәбез. Нигә миңа кипарислар, имеш... Үз илемдә ямьле миңа бәрәңге бакчасы да, имеш... Гомер буе изелеп яшәгән белорусларны «бульбаши» дип йөртәләр (ягъни бульба, бәрәңге). Татарның да шулай дөньяга караган төнлеге бәрәңге сыярлык кына, ахрысы...

Разил Сибгат ага Хәкимнең «Англиягә барып кайт син, диләр» дип исемләнгән шигырен искә төшерде.

...Тик июнь бит хәзер, дусларым:
Куркам монда күрми калырмын дип,
Арышларның, әй, баш кысканын.

Менә бит ул татарның «миллитарлыгы»... Англиягә барырга мөмкинлеге бар, ә ул киреләнә. Җире дә, офыгы да кысыла барган саен, милләт үз-үзен кечерәйтеп караудан өметсез ләззәт алырга күнегә бара, ахрысы. Әнә бит, болгар да болгар, дип, күпме галим авыз суын корыта. Болгар — борын астындагы бик бәләкәй җирлектәге тарих ул. Хәзәр каганлыгын, Алтын Урданы күтәрә башласаң, Дунайдан алып Татар бугазына чаклы җәелгән кыйтганы биләгән халык тарихын иңгә салу өчен акыл да, белем дә, тәвәккәллек тә кирәк. Кайчан да булса гомум тарихыбыз мәйданга чыгармы? Ул чакта инде халык та үз тарихын кабул итә алмаслык дәрәҗәдә аңы бикләнеп, үз хәтеренә саңгырау калмасмы?

Сүз гамен артык тирәнәйтеп, Кавказ кояшын өметсезлек офыгына төшереп җибәрмәс өчен, мин әңгәмәнең очын юморга борам:

— Ничек дисең, Разил, арышларның серкә очырганын күрми калам, дигәнме?

— Баш кысканын... — ди Разил, мыек астыннан елмаеп. Кайчакларда аның Сибгат ага тарафына уклар җибәреп алуының үзенә күрә бер сәбәбе дә бар. Ел йомгагы вакытында Тукай клубы мөнбәреннән Разил шигърияткә багышланган доклад сөйләгән иде. Шунда ул Сибгат ага Хәкимнең авылга кайтып, җим чүпләгән тавык кебек йөрүе хакындагы дүртьюллык шигырен мисалга китергән иде. «Минем бер дә аксакалыбыз Сибгат аганы тавык белән чагыштырасым килми, хәер, ул үзен миңа караганда яхшырак беләдер...» — дигәч, зал ду кубып көлгән иде. Сибгат аганы үпкәләтүе дә ихтимал иде югыйсә, әмма залны көлдерәчәк эффектны югалтасы килмәде. Разил шуннан соң берничә ел Язучылар союзы әгъзасы булып раслана алмады. Сибгат ага кабул итү комиссиясе рәисе иде. Ләкин монда үч тоту, мәкер юк иде, яшь егеткә аз гына сабак бирү төсмере генә булгандыр, мөгаен.

Төн... Күлгә тулган ай шәүләсе төшкән. Олы юл кырыенда «Колхида» сигареты пыскытып торабыз. Күге бүтән, иле бүтән... Эвкалипт төбендә егетләр җырлый. Гүя таулар искәртә: грузин җыры кыя-тарлавыклар арасыннан яңгыраган кайтавазы белән бергә үрелеп агыла икән.

Ә диңгездә сары Ай юлы.

* * *

Күзем инҗир, самшит куаклары, бамбуклы яр аша диңгез киңлекләренә төбәлсә дә, күңел өянке-инешле авылым тугайларында мәтәлчек атына. Мондый ят-купшы, акварель төсләрдән тукылган табигать эргәсендә хәтер үткенләнә, балачак хатирәләренә бирелү хисе көчәя икән. Язуы рәхәт.

Разил белән бер көнне яңа повесть башлап җибәрдек. Уртак стеналы күршеләр булсак та, ишек кагу юк, бер-бер сәбәп чыкса, телефоннан гына чылтыратышабыз.

Мин бер бит язып тутырам да тәмәке тартырга дип лоджияга чыгам. Үрелеп карыйм: өстәлгә иелеп, Разил кәгазьгә «кадалган». Кәгазенең төсе... Бервакыт Мәскәү язучыларының җыелышында Юрий Бондарев болай дип сөйли икән: «Мин ак кәгазь каршында олы бер җаваплылык тоюдан каушап, чарасыз калам...» Шулчак президиумда утырган Сергей Михалков: «Ә син кәгазьнең яшелен алып кара!..» — дип, залдагы язучыларны көлдергән. Шуның кебек... Разил дә өстәленә бер өем яшел төстәге кәгазь таслап куйган.

Язу өстәленә якын килмәс өчен, әллә нинди вак-төяк эшләр уйлап тапкан булам. Өстәл әзерлим. Чәй кайнап чыккач, телефонны кулга алам:

— Куеп тор, Разил, башыңа кан сава күрмәсен. Чәй эчеп алыйк.

Иркен лоджияда түгәрәк ак өстәл янында, ап-ак урындыкларга утырып, аякларны култыксага американча күтәреп, чәй эчәбез. Аста диңгез җете зәңгәрлеге белән үзенә чакырып тора. Төсе кунакчыл булса да, суы боз кебек, апрель диңгезе тиз җылынмый икән шул. Разил беркөнне, кызыгып, бер генә чумып чыкты. Якында хатын-кызлар карап торса, утка керергә дә әзер Равил Фәйзуллин гына бар дип йөри идем, баксаң, Разилгә дә бу сыйфат ят түгел икән. Мин суга аякны гына тыгып алган идем, шунда ук борын үзенең барлыгын сиздереп йомшый башлады.

— Мин төп героемны төрткәләп урамга чыгарып җибәрдем. Хәзер инде артыннан ияреп йөреп язасы гына калды, — ди Разил.

Ул икмәк киптерә торган сушилкасына җиз иләк эзләп гасыр башында Төркиягә барып чыккан бабасы турында сөйли. Шул бабасы гомер буе колхозга кермичә, таза хәлле аерым хуҗалык булып яшәгән. Разилнең әтисе — Зур Исмәгыйль абзый — шул колхозның рәисе булып күп еллар эшләгән. Сизеп торам: болар Разилнең яңа әсәренә керәчәк, миндә «сынап» карар өчен сөйләп, ул вакыйгаларны чарлап бара. Иҗат йортында яңа әсәр башлаган һәр язучыга хас «авыру» инде бу...

Ә мин Разилнең һәр эшне җиренә җиткереп, батырып эшли белүе әнә каян, таза, нык куллы нәселдән килә икән дип уйлап утырам. Әнә бит кыска гына арада Чаллы Язучылар оешмасында нинди эш җәелдереп җибәрде. Мәскәү тикле Мәскәүдән олы язучылар китертеп, зур-зур киңәшмәләр, семинарлар үткәрде. Исеме Мәскәүдә басыла торган повестьларга, киноларга кергән Рәис Беляев белән дә килешеп эшли белә. Шәһәр советы депутаты булды. Безнең өчен Пиночет булып күренгән өлкә комитеты түрәләре — Вәлиев, Мусиннар белән дә уртак тел таба... Иҗатында нишләр? Күкрәге белән гранатасын каплап һәлак булган якташ егете турында повесть язып, Муса Җәлил исемендәге бүләк алды. Тагын... трибуналардан исемен еш яңгыратуга кызыгып, иҗатында бөтенләй «кызарып» китмәсме? Юк, ышанасы килми, аның тотрыклы холык-фигылен бел-

гәнгә күрә, бу шикләремне чынаяк өстеннән күтәрелгән чәй парына кушып таратып җибәрәм.

Өстәлгә «богауланып» язу кебек «каторга хезмәте»ннән бушаган араларда, Гагра каласына юл тотабыз. Чәй плантацияләре, кабыгын салып, анадан тума чишенеп ташлаган эвкалиптлар арасыннан сузылган борылма юл ун-унбиш минутта илтеп җиткерә. Гагра — кыя таулар эргәсендә, диңгез ярындагы тар гына уентыкка урнашкан кала. Паркта ханбикәләр кебек купшы тавис кошлары аллы-гөлле каурыйларын җилбәзә итеп йөренә, күлендә — кара аккошлар. Гагра — борынгы Рим, Византия, Төрек империяләре тоягы астында калып та яшәвен дәвам иткән, ныклыгын урам ташларында саклап калган ягымлы шәһәр.

Менә без кыя ташлы ярга кертеп ясалган өй тәүмәле мичкәләр янында тукталабыз, һәр мичкәгә шәраб исеме язылган. Шуның нәни краныннан агызып бирелгән шәрабның тәме котыртмыйча кала димени!

— Абхазларга, грузиннарга карыйм да... Болар яшәргә килгән халык, — ди Разил. — Авылларын күр, нинди йортлар! Колонналы, икешәр катлы. Болар эшләп түгел, ял итәргә килгән халыкны фатир тотып кына да баеп бетә. Без бик фәкыйрь болар янында. Агачтан йорт салып, ерак китеп булмый шул...

— Безнең татар эш аты. Тормышта да, әдәбиятта да.

— Менә минем хәлне аңла инде, шул эш атлары арасында яшим бит, — дип, Разил Чаллысына ишарә итә. — Минем бу повесть киңәергә тора, геройлар миңа буйсынмый башлады. Роман итеп җәелдерсәм, син әйтмешли, эш атларын да кертмичә булмас.

Ни әйтергә дә белми сүзсез калам. Ярый әле, авыз буш тормас өчен, алдыбызда шәраблы тустаган мөлдерәп тора. КамАЗга барып, моңарчы күрелмәгән кызыклы шәхесләр табып, тиңе булмаган әсәр язарга хыялланган беркатлылардан көлеп йөрүче без түгел идекмени! Ул заманда трибуналардан еш яңгыраган «тормышны өйрәнү» дигән сафсата фикергә алданып, үз таланты өстенә басканнарның шаһиты булмадыкмыни! Тормышны өйрәнергә түгел, ә мәгънәле яшәргә кирәклеген сиземләсәк тә, һәртөрле ымсындыргыч ялтыравыклар каршында мәсләгеңне үзгәртүең дә мөмкин ич. Ни сәләт иясе, Сент Экзюпери аквареленә каләмен манып яза белгән Фәрит Гыйльми дә, Әлмәткә күчкәч, Бикчурин, Рәхимовлар йогынтысына бирелеп, эш атларын иярли башлады түгелме... Ярый да Җәмит Рәхимов, аңга килеп, тарихи әсәрләр язарга тотынды. Ләкин Фәрит Гыйльмигә үз эзенә төшү өчен Ходай Тәгалә вакыт калдырмаган иде шул...

Янәшәдәге өстәл янына грузинмы, абхазмы карчыклары килеп басты. Кулларында шәраблы стакан. Бәлки, алар карчыклар да түгелдер әле. Кояш муллыгыннанмы, кавказ хатыннары иртә картаялар. Юк, болар Казанның Пешков-Горький чорыннан калган «биле сынган» йортлар арасында, җир асты җәнлекләре һәм күпчегән сыра исе аңкыган лареклар тирәсендә буталучы, кипкән сыйраклы, коңгырт-күмгәк йөзле ирдәүкә хатыннар түгел. Болар Кавказ таулары кебек чыныгып олыгайган, кылыч борынлы, күмер күзле, юка гәүдәле Шәрык ханымнары. Шәраблары да сусынны басар өчен генә: «Цинандали», «Мукузани», «Алазан үзәне» — тагын әллә ниләр. Эчендә айлы төн, кояшлы тау җиле, диңгез шавы йокымсыраган бу җиңел эчемлекләр яшь тәнгә дәрт өсти, олыгайганны изрәтеп, җәннәтле төш дөньясына әйдәкли...

Шәраб тәэсирендә аңны ял иттерү өчен, Разилнең көтелмәгән уенчак фикер әйтеп, шаяртып ала торган гадәте бар. Таулар ягына ымлап, ул:

— Кавказлылар хәйләкәр халык, ә! — дип куйды. — Хәйләкә-ә-р... Җиребез аз, дип зарланган булалар. Болар җирне ничә чакрым биеклеккә күтәргәннәр икән бит... Бу тауларны җәеп салып үтүкләсәң, бермә-бер арта боларның җирләре...

Безнең көлүне таулар иясе кичермәде, ахрысы, бик тиз үч алды. Гаграның тар урамында, ташка эләгеп, Разилнең «чабата» үкчәсе каерылып чыкты. Нәкъ шушы урында Александр Македонскийның аты сөрлеккән булган, дип, мин дә шаяртып алдым. Үкчәсез калсаң, бик көләсе килми шул... Ярый әле якында гына остаханә бар икән. Кердек. Күн алъяпкычлар киеп, өч ир кеше эшләп утыра. Түр кырыйдагысы, ябык чырайлысы — абхаз. Уртадагысы — йончу-сытык чырайлысы — урыс, калын кара кашлысы, куе мыек астыннан елмаеп безгә таба килгәне әрмән иде. Ул җәһәт кенә чабатаны алып әйләндереп карады да:

— Тыри рубля! — дип эшкә дә кереште.

Күренеп тора: кулларын жонглерларча уйнатып, үз шөгыленең тәмен белеп кинәнә бу. Ара-тирә башын күтәреп, сорау биреп куя: «Братья что ли? На каком языке говорите? Татарский что ли? Вот удивительный народ татары, а?! Одын живет на Тыхом океане, другой — на Чорном море, язык — одын!.. Умный народ, после армян, — дип, мыек астыннан ап-ак тешләрен күрсәтеп көлә. — В Москве ученых татар очен много, после армян...»

Аяк киемен, тиз арада гөл итеп, ул Разилнең кулына тоттырды:

— Рубэль пэтдэсять...

— У нас много общего, не забудьте, у нас и общий враг, — диде Разил акча сузганда.

Әрмән, көлә-көлә, аның иңеннән кагып алды.

— А на кого вы подумали? Я говорю об атомной бомбе... — дигәч, «Ну и татарин! Я же говорю... умный народ, после армян, — дип шаркылдап көлде дә: — Бэсплатно! Дэнги не надо!» — дип, артыбыздан озата чыкты.

Ул арада Гагра яңгырга манчылган, кыя таулар иңенә сарык көтүе шикелле өелгән болытлар тын гына яшь коя иде. Күп булса, ун ел үтәр дә, бакый заманнардан бирле шушылай әле кояшка, әле яңгырга коенып утырган Гаграның тыйнак урамнарын тетрәтеп, танклар узар, безнең иҗат йорты тирәсендәге авылларны кырып-җимереп, абхазлар белән грузиннар арасында аяусыз канлы сугыш башланыр дип, ул чагында кем уйлаган...

* * *

Суга ыргытылган таш тирәли божра дулкыннар хасил була да, үзәктән читкә тарала-тарала, куәтен җуеп, сүнә-сүрелә бара. Яңа фикер дә шулай, пайтәхет манарасыннан дулкын-дулкын булып тарала да, зәгыйфьләнеп кабатлана-кабатлана, империянең ерак почмакларына кадәр барып җитә. Әлеге чагыштыру әдәбият-сәнгать галәменә бигрәк тә карый иде. Мәскәү әдипләре үзләрен Алла тәхете янында итеп тоялар, аларның юк кына әсәрләре дә «кыңгыраулы» иде. Тукай юкка гына «Тотса мәскәүләр якаң...» дип язмагандыр шул.

Без — җитмешенче ел студентлары, дөньяның бердәнбер Әдәби институтында Разил Вәлиевнең укуына, Мәскәү каланчасыннан ташланган фикернең тәүге дулкынын тотып алырга тиешле булуына эчтән кызыгып, бераз көнләшеп тә карый

идек. Ул чакта Мәскәү кайный, шигърият мәйданнарга бәреп чыккан иде. Евтушенколар, Вознесенскийлар, Беллалар халык учында... Болар инде безнең Гаташлар кебек шигырь сөйләргә көзге каршында үзлегеннән өйрәнеп кенә калмаган, болар борынгы Римнән килгән ораторлык сәнгатен, гипноз тәэсиренә торырлык шигъри сүз егәре, тавышның куелышы, паузалары белән күңелләрне ничек яуларга икәнен махсус укытучы-режиссерлардан өйрәнгәннәр иде.

Разил Вәлиев Мәскәүнең бәхетле чорына эләгә. Җитмәсә институтның җиде катлы тулай торагы да үзе бер дөнья. Илнең төрле тарафыннан килгән төрле милләт «бөекләре» Пушкин, Толстойларны башаркан гына чөяләр...

Үҗәт-төмсә чырайлы Юрий Кузнецов русның иң зур шагыйре булачагына үзе бер дә шикләнми. Гашыйк булган кызы каршында, мәхәббәтен раслап, алтынчы каттан сикерә. Кар көртенә төшеп исән кала. Хастаханәгә аның янына алты ай буе казакъ кызы килеп йөри һәм егетнең күңелен гомерлеккә яулап ала...

Есенин музасын бу гасырның азагына тиклем җиткерергә тиешле Николай Рубцов, тулай торак залындагы классиклар портретларын бүлмәсенә җыеп кереп, шуларга чәкештереп эчәргә ярата.

Нәмҗил Нимбуев — бурят шигъриятенә көтелмәгән аһәңнәр алып килгән шагыйрь. Яшьли үлгән егетнең бердәнбер китабы чыга — «Тышауланган яшен»... Тагын әллә кемнәр...

Мәскәүнең шаулы мохитендә кайнаган Разилнең шигъри үлчәмнәргә генә сыя алмыйча, проза аланына сикерүе, бер караганда, гаҗәп тә түгел. Ләкин аңа ул чакта егерме бер генә яшь булганын исәпкә алсаң... Повестьның исеме дә нинди бит әле, кинаяле астыртын мәгънә салынган хикмәтле исем — «Эт кояшы». Юлбашчыларны кояшка тиңләп күпме шигырь язылган, аларның яктылыгы күктәге кояш белән бердәй булып канга сеңеп беткән бер дәвердә... Кояш белән этне янәшә китереп куй әле... Монда инде син, су коенып чыккач, «каз тәне» бирчәйткән беләк-балтырларыңны җылытырга дип, «Эт кояшы, тегеләй кит! Тәти кояш, болай кил!» дип титаклый-титаклый, аръяк болыннан кояшлы уйдык эзләп чапкан малай чакны искә төшереп, халыкның гореф-гадәте лә ул, диеп кенә котыла алмыйсың. Курку-шиге тотрыклы, күндәм халәт алган мөхәррирләр эт кояшыннан хәтәррәк мәгънәләр күрәчәк.

«Сүз дә юк, сәләтле малай. Көчле повесть язган. Ләкин безнең илдә бастыра торган түгел. Караңгы әсәр. Япь-яшь кешегә каян килә бу тормышның караңгы якларын эзләү... Жестокий талант!..» — Бу нәшриятның ул чактагы баш мөхәррире Марс Шабаев сүзләре. Иҗат семинарлары вакытында Аяз Гыйләҗевнең «Эт кояшы»н мактап, берничә тапкыр әйткәне булды. Әмма аның да бу әсәрне үз вакытында бастырып чыгартырга көче җитмәде. Нишлисең, ул дәвердә цензура балтасы Мәскәү кулы белән һәрдаим чарланып тора иде шул.

Башкалада яшерен-тыелган әдәбият укып, хөр фикерле мохиттә кайнап чарланган егетнең Казанга кайтып төшүе үзе бер вакыйга була иде. Теләсә кайсы студентны якынына җибәрмәс. Калын кысалы күзлектән ул кырыс-серле күренә. Иңен акыл баскандай, яһүдләргә охшатып, башын иебрәк, маңгай астыннан сөзеп карый. Пөхтә киенгән. Ара-тирә сүз кыстырып куюы — әңгәмәнең үзегенә төбәп аткан зәһәр ук кебек. Аның белән ничә еллар аралашудан шундый фикергә киләм: яшьтәшләрнең байтагы Разилнең үткен карашыннан, әче теленнән, һәр эшне мөгезеннән борып ала торган гаярьлегеннән куркалар иде. Шуңа күрә алар читләшеп, үз тирәсенә яраннарын тупладылар. Тышкы кабыклары вакытлы дәрәҗә, вакытлы урындык биләсә дә, шул мәхлуклар чолганышында канәгать яшәп, эчке рухлары бер дә үсмичә кәрлә калды. Хәер, сыек өреле, урта кул язучы өчен бу котылгысыз юл иде.

«Эт кояшы»н мин студент елларында кульязма хәлендә укыдым. Лермонтовның «Герое...» ничек канны кымырҗыткан булса, бу да шулай тәэсир иткән иде. Соңрак «Ак абагалар» повестен мин шушы әсәрдән алган илһам йогынтысында яздым шикелле.

«Эт кояшы»н язган яшь каләм иясе, Достоевский юнәлешен сайлап, адәми затның эчке хасиятендәге караңгы тарлавыкларга, иблисле чоңгылларына кадәр төшәргә сәләтле икәнен раслаячак иде. «Җенен уятып» язган бу әсәрендә Разил Вәлиевнең усаллыгы да, самимилеге дә, фикри елгырлыгы да, өйрәнчеклеге дә бер бизмәндә, җыйнак рамга сыйган серле этюдны хәтерләтә иде. Кызганыч, шушы тәүге трамплиннан сикереп, тагын да югарыракларына үрлисе чыгымчы тайга үз вакытында ирек бирмәделәр. Татарга сокландырганны, көчлене түгел, ә кызгандырганны, мескенлекне ярату хас шул...

Күпмедер еллар үткәч, ул яңадан прозага тотынды. Әмма... «Эт кояшы»ның ымсындыргыч орбитасы, андагы яшьлек очышы бүтән яссылыкка күчкән иде шул. Инде кан тибеше, йөрәк ритмы, акыл тирәнлеге башка иде... Ул инде хәзер «эт»ен ташлап, кояшлырак әсәрләр язуны мәгъкуль күрүләре белән килешә язган иде.

Ак кирмәнең һаман акмы, Казан?
Шулай киңме һаман Иделең?
Син бит миңа — туу, сөю, тормыш,
Шатлык, кайгы, яшәү һәм үлем...

Әнә шундый хисләр белән Мәскәүдән сагынып, ашкынып кайтса да, Казан, кырыс шәһәр буларак, аны кочак җәеп каршы алырга тормый. Ике катлы цензура аша кинаяле фикерләреңне үткәрә алмыйсың. Дәүләтсез халыкның пәйгамбәре дә булмасын яхшы аңлаган егет, эчтән янса да, бирешми, тыштан бәхетле студент булып күренә белә. Шул чордан ул гыйбрәтле бер вакыйганы көлеп тә, сагышланып та искә төшерә. Аңа Мәскәүнең махсус кибетендә генә сатылуга чыккан, һәр язучының хыялында булган «Эрика» дигән язу машинкасы алырга дип акча җибәрә торган булалар.

— Ул елларда шактый ташыдым мин ул машинкаларны, — ди Разил. — Бер кайтуымда бишне берьюлы алган идем. Казанга кайтып төштем. Нәшрият бинасына чаклы боларны ничек алып барырга? Таксига акча юк. Ике кулга икешәрне тоттым, берсен теш белән күтәрдем. Барам шулай. Артымнан аптырап карап калалар. Машинкаларны хуҗаларына таратып бетергәч, кичкырын берьялгызым басып калдым. Ни акчам, ни кунар урыным юк. Гарьлектән җыладым шул чакта. Нәшрият баскычына утырып төн чыктым.

Кеше хәленә керә алмаслык сөмсез булмагандыр инде ул чор язучылары, хикмәт нидә соң, дип уйлап куям. Була бит шундыйлар: йөз-кыяфәтенә, үз-үзен тотышына карап, бу ярдәмгә мохтаҗдыр инде дип һич кенә дә уйламыйсың. Разил нәкъ менә шундыйлар кавеменнән. Чарасыз-мохтаҗ чакларында да рухын тезләндермәс, кайгы-гамен эчкә йотып, ныклы тамырдан калыккан нәсел шәҗәрәсенең бер яфрагын да сискәндермичә, Зур Исмәгыйль малае булып, горур-өстен кала белер.

Әмма миллионнарча кеше кайнаган Мәскәү өчен Сталин малае ни дә, Зур Исмәгыйль малае ни... Барысын да бер мөшкәгә салып, талымсыз тегермәнендә тарта бирә. Илнең төрле тарафларыннан Мәскәү җылысына җыелып, эт типкесендә күпме

билгесез шагыйрьләр каңгырап йөри. Алар котельныйларда төн чыгалар, ишегалды себерәләр, вокзалларда кунып йөриләр, тулай торакларга ияләнәләр. Ләкин алар рәтсез тормышны бәхет итеп күрә беләләр, кызыл байракны чолгау итеп урачы, классикларның борынына чиертүче бөек билгесезләр... Болар режимга буйсынмаган сукбайлар, башка төбәкләрнекеннән бер башка өстен башкала сукбайлары!

Яшьли өйләнгән Разилгә мондый язмыш янамый, әмма ярлылык үзен сиздерә. Кызы Сөембикә тугач, ул төннәрен макарон фабрикасында эшли башлый.

Моңсуланып банан ашап йөри
Балан ашап үскән малаең, —

дип язса да, күчтәнәч алырлык та рәте булмау сәбәпле, туган авылы Ташлыкка кайта алмый. Шактый айлар үткәннән соң, әнисеннән хат килеп төшә. Анда әлеге шигырь юллары да була:

Кайтсаң иде кеше улы кебек,
Япсаң иде лапас түбәсен.
Өйләндең дә, көйләндең дә, ахры,
Бер усалга каптың, күрәсең.

Кинәт... Хыялга бай, сәмәнгә ярлы шагыйрьнең бүлмәсенә туган ягының Сарсаз, Кайнар таулары, колач җитмәслек Шишкин имәннәре килеп керә, шул калын урманнар эченнән чыгып килүче ак яулыклы әнкәсе күренә...

Ниләр языйм, әнкәй, ни җибәрим? —
Бар булганым — кара һәм каләм.
Җитмеш тиен юлы шигыремнең...
Шигырьләтә генә җибәрәм.

Әлеге «Әнкәйгә хат» дигән шигырь хатка гына сыярлык беркатлы хисләр булып калыр иде, әгәр шагыйрь саллы гомумиләштерүләргә ирешмәгән булса...

Сарык дигәч... болыннарда ни хәл?
Гыймадимы һаман көтүче?
Көтүчесез калган көтү ничек,
Без дә шулай хәзер җир өчен.

Разил Вәлиев шәп шигырьләр циклы язган дигән хәбәр Мәскәүдән без Казан шәкертләренә яшен ташыдай килеп ирешкән иде. Бу хәбәрнең пароле бер ишетүдә ятланып кала торган түбәндәге юллар булгандыр, мөгаен.

Каерып ач урыс капкаларны,
Керсен бәйрәм татар өенә!..

Казан университетында укыганда, ирекле шигырь саллылыгына омтылып язган шагыйрь Мәскәүнең Әдәби институтында үз чорының корифейларыннан дәрес ала башлагач, дөньяда тупланган китап байлыгына хәйран кала. Уолт Уитменның акылны ардыра торган шигырьләреннән ял иткән арада, испан шагыйре Лорканың Андалузия аһәңнәре, чегән романсеролары аның хисләрен әсир итә. Кырыс Балтыйк ритмына корылган Александр Чакның көтелмәгән чагыштыруларына хәйран кала. Иң кызыктырганы — Мәскәү даирәсе, Евтушенко, Вознесенскийлар. Бөтен дөнья егылып аларны гына укый, аларга гына табына кебек. Әмма шәһәр шигърияtenә бирешергә теләмичә җан карыша, усал итеп бер кычкырасы килә:

Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Йә булмаса үзем үзгәрәм.

Такташ бунтарь әйтмешли, их, тиле яшьлек! Үзебезнең дә, дөньяның да танымаслык булып үзгәрәчәге белән килешмәү үҗәтлеге бирелгән иде шул безгә. Утызынчы еллар яшьләре кебек канлы байрак асларында «сугышчан алласызлар» булып йөрмәсәк тә, гөнаһлы заманның астыртын гамәленә сабыр күнегеп үстек бугай. Ислам дигән олуг дөньядан, Коръәннән, чын фикер ияләренең җанны сугара торган акыл хәзинәсеннән мәхрүм калганбыз лабаса.

Мәңгелек дигән алдавыч төшенчәләр белән үз-үзебезне кысыр хыял белән алгысытуыбыз да сабыйлык галәмәте булган. Алласыз һәм тарихсыз (рухсыз һәм хәтерсез) әдәбият гомере — күбәләк гомеренә тиң.

Еллар үтеп олыгая барганда, шушы аяусыз хакыйкатькә төшенү рухи фаҗига түгелмени!

Изелгән милләттән яңа фикер күтәрүчеләр була алмый, буйсындырылган, иярчен милләтнең акылы да идарә ителә, диләр философлар. Каты бәгырьле дөреслек. Без әдәбиятның үтә беркатлы, самими корбаннары булып калырбызмы? Соңмы безгә Аллалы булырга?

Халыкның мәмләкәтле, дәүләтле дәверен, кыйтгаларга таралган тамырынача төшеп, җиһанда тиңе булмаган тантаналы фаҗигасен, шанлы дәһшәтен зур полотнода күрсәтерлек сәләт иясе алдагы гасырда туармы? Ихтимал... Әгәр бөтен татар галәмендә бердәй җирлектә табигый сайланышка ирешелсә. Таркалган милләтнең җан-рухиятенербөтен камиллеккә тупламый торып, көчледән көчлене тудыру мөмкин фал түгелдер.

Тарихлы булырга соңмы безгә, киләчәк кадерсезләренә? Көнлекче әдипләр мондый сорау белән гаҗизләнми. Шулай да... тәкъдиргә рәнҗемик әле, дәверне берәү дә үзе сайлап алалмый. Нәни генә юаныч күңелне җылыта: әдәби тел банкын булдыруда без дә, микъдарлап булса да, хәл кадәри өлеш керттек бугай.

Хәтер олыгая барган саен, ачынып сөйләшәбез, уйланабыз. Йолдызлы күк асларында, учак яннарында. Аек килеш тә, кайнарланып та. Шул гамьле сөйләшүләр кайтавазыннан хәтергә коелып калган каурыйлар гына бу...

Ә тормыш — газаплы могҗиза, яшисе килә, шайтан алгыры!

* * *

Менә без Малеевкадагы иҗат йортында. Мәскәүнең Белорус вокзалыннан Бородино ягына баручы электричкага утырасың да бер сәгатьтән син — монда. Кыргый урман аланында дворян особнякларына охшатып эшләнгән колонналы бина яктырып тора. Наратлыкта мансардалы коттеджлар. Язучыларның бу биләмәсе Руза районына керә. Белешмә-китапта «Ру-

за» — кальга, татар сүзе диелгән.

— Рәхәтләнеп татарча сөйләшеп йөрик әле үз җиребездә, — дип, Разил белән көлешәбез. Шаяртуыбызда хаклык та бар. Заманында Иван Грозный тәхеттән ваз кичеп торган арада, Рәсәй белән татар Сәин (Симеон) Бикбулатович патшалык иткән. Шуңа бирелгән тарихи җирләр икән бу...

Кышкы урманның үз хозурлыгы бар. Йөзьяшәр наратлар арасыннан салынган сукмаклар буйлап, бер гаилә-ыру булып йөрибез. Уфадан — Мостай Кәрим, Муса Гали, Рафаэль Сафин. Ташкенттан — үзбәк әдәбияты классигы, үз татарыбыз Әсгат Мохтар.

Разил Казаннан ук салкын тидереп килгән иде, монда бөтенләй урынга ауды. Коры ютәл. Температура. Кичен Мостай ага чәкчәк, юкә балы, һинд чәе күтәреп килеп керде. Өлкән аганың аталарча кайгыртуы, шифалы чәе, йомшак сүзе җанына яттымы, Разил икенче көнне үк аякка басты. Берничә көн буе кирәкле нотасын таба алмыйча изаланган музыкант кебек пошаманда йөрде дә дәррәү кубып яза башлады. Миңа да җиңел булып китте. Күршеңнең каләме йөгерә башласа, синеке дә дәртләрәк алдырып китә шул. «Ерак урман авазы» дип исемләнәчәк повестемның язган бер бүлеген Разилгә сөйләп барам. Шулай беркөнне сыкылы урманның әкияти ак тынлыгыннан хозурланып йөргәндә, Мостай ага миннән:

— Язылламы?.. Нәрсә турындарак әсәрең? — дип, сак кына сорагач, Разил:

— Бик катлаулы булырга охшый, Мостай ага... Көн саен Марсель берәр кешене үтереп тора, гел мәет ташыйлар, — дип - көлдерде.

Кичләрен иркен бильярд бүлмәсенә җыелышабыз. И, ул хыялда гына калган Малеевка бильярды!.. Мин аны җүләрләрчә яратып та, бәгырьдән өзәргә мәҗбүр булган хатын-кызны еллар аша сулкылдап сагынган кебек искә төшерәм... Затлы агачтан ясалган саллы өстәлнең аяклары гына да нинди бит — патша самавырлары кебек! Өслеге эбонеттан ясалган, кыл тигез, шар үзен энә очында бөтерелгән бөек балерина кебек хис итә. Яшел тукымасында ник бер чүп, тап ише нәрсә булсын, көнгә ике тапкыр тузан суырткыч белән чистартып торалар үзен. Нәкъ өстәл турында, шарларга яннан күләгә төшермичә, бронза челтәрле лампа яна. 1870 елда Германиянең атаклы Шульц фирмасында тылсым өреп эшләнгән, җиде медаль сугылган бу бильярдта кайчандыр Достоевский уйнаган булган.

Бильярд өстәле янына килеп баскач, син үзеңә бертөрле аура-дулкынга әләгәсең, үзеңне олы ауга чыккан хан-каган урынында итеп тоясың. Кулыңда корал — махсус оста тарафыннан ясалган ялтыр-кара кий-таяк (Мостай Кәрим үзенә атап ясаткан, аныкына бүтән кеше кагыла алмый. Хакы 25 сум. Минем әни авылда 22 сум пенсия алган 1981 ел бу). Ул кийның кулга рәхәт яткан авырлыгы, аның төзлеге... Бер сүз белән генә сылу дип атарга мөмкин.

Ә шарлары... Фил сөягеннән эшләнгән авыр, чын шарлар. Болар инде, таяк очы тиюгә, кая керер тишек тапмыйча тәгәрәмиләр. Нинди көч белән бәрсәң дә, акрын гына кузгалып, гүя «кем әле син?» дигәндәй, артка караш ташлап алганнан соң гына, вәкарь белән кузгалып китәләр. Разил әйтмешли, бәрәсең дә, шар лузага барып җиткәнче, туалетка кереп чыгарга өлгерәсең. Луза ятьмәсеннән шарны алганда, инде симез, тере балык эләктергән кебек, бөтен тәнеңә мәҗүси рәхәтлек тарала.

Бильярд уйнаганда, дан-дәрәҗәләр бетә, төртмә сүз, көлешү, мактанышу китә. Һәр уенның үз теле бар шул.

Әсгат Мохтар әйбәт кенә уйный. Ул нәкъ безнең Аяз Гыйләҗевкә охшаган: күзлекле, кыска буйлы, ярпач, хәрәкәтчән, «почмаклы».

— Сезгә рәхәт, — ди ул Башкортстан язучыларына. — Машинистка кызлар татарчадан аударып чыга да кулъязмагызны — башкортча текст әзер. Үзбәкчәдән алай булмый шул...

Гомере буе үз халкыннан читтә яшәсә дә, теле нәкъ Казанча, ник бер үзгә аһәң яңгырап китсен.

«Без — типтәрләр...» — дип, Муса ага сүз башлаган иде. Әсгат ага аны: «Современные типы, димәкче буласыңмы?» — дип кисеп кенә куйды. Ни хикмәт, аның бер сүзенә дә үпкәләмиләр. Үзбәк татары шул, татар татары түгел...

«Татарча язгалыйсызмы?» дигән сорауга ул болай диде: «Яза алам да... Татар телен рус сүзләре белән нык чуарлап бетердегез. Үзбәк теле төркилеген саклап калды. Миңа үзбәкчә язу җиңелрәк...»

Мостай ага шарга бик йомшак бәрә, дөресрәге, сак кына этеп җибәрә. Инде сүнә, инде бетә дип карап торасың, юк, шар үрмәләп булса да лузага барып җитә. Мәскәү шагыйре Сергей Островой белән алар акчага «пирамида» уйныйлар. Бу уен сәгатьләр буена сузыла, карап торырга түземлек җитми.

Гадәти уенда Сергей Островой «свой» суга белми икән. Разилнең үз шарларын агызып кына кертүен яисә яшен аткан тавыш чыгарып, чатнатып лузага салуын баш чайкый-чайкый карап тора да:

— Не-ве-роят-но... Не-мыс-ли-мо... — дип көрсенеп куя. Икебезнең уенны күзәтеп торганнан соң, ул шундый нәтиҗә чыгарды: — У вас Казанская, особая школа...

Рафаэль Сафин да әйбәт уйный, арабыздан бер ул гына башкортчалатып сөйләшә. Аның бер сүзен бильярд уенына термин итеп алдык. Әгәр шар лузаны «иснәп» тә кермичә китсә, «килгәйне» дип куябыз. Бу инде партнерның күңелен күтәрү өчен «керә язды» дигән сүз була. Рафаэль Сафин башын артка ташлап, чытырдатып көлә белә. Баштарак мине кызыктырган бу көлүдә егетлек тә, бәйсезлек тантанасы да бар сыман иде. Руслар мондый көлүне «заразительный смех» диләр. Бераздан мин Сафинның авызы ерылып та күзләренең бер дә көлмәвен искәрә башладым. Аннары... Янәшәбезгә Сергей Островой яки бүтән бер Мәскәү «классигы» килеп басса, Рафаэль Сафин бөтенләй бүтәнчә, башын чөеп, чытырдамыйча, тыенкы көлә.

Авыз һәм күзләрнең берочтан үзара килешеп, табигый көлүе — коллыгын җиңгән эчкерсез кыюлыкның тантанасыдыр, мөгаен.

Муса Гали бильярдны бик өнәп бетерми. Ул чиста ак йөзле, холкы тыныч, шигырьләре кебек ипле кеше. Иртән ашханә янында күрешүгә:

— Төне буе йоклый алмадым, егетләр. Кан басымы... — дип сүз башлый.

Аның шулкадәрле дә тәмле итеп, эчтән яктырып-балкып, тыңлаучыга чиксез рәхмәтле булып авыруы турында сөйләвен бер Разил генә түзеп, яратып тыңлый белә. Тыңлый гына түгел, күрешүгә:

— Муса агай, баш авыртып тора, нәрсәдән икән ул? — дип, Муса агайны кузгатып җибәрергә тел ачкычлары бирә.

Берничә елдан соң Муса агайның бу гадәтен юмореска итеп язган идем, «Син нәрсә, мине авыру итеп күрсәткәнсең, җитмешкә җитеп минем бер тапкыр да хастаханәгә кереп ятканым юк», — дип, үпкәләвен белдерде.

Иҗат эше ардыра. Сирәк булса да кичләрен бер табынга җыелышабыз. Үзәктә — хөрмәтлебез Мостай ага. Ул, каратут

йөзенә мут елмаю чыгарып, сүз сөрешенә нур иңдереп утыра белә. Хәмер тәэсиреннән дә беркайчан кызып китмәс. Сабыр, итагатьле. Фронтларда чыныгып, чорыбызның бөек әдипләре белән якыннан аралашып яшәгәнгәме, тормышының һәр мизгеленә шөкрана кыла белгән олпат шәхес.

Разил, берәр төртмә-кинаяле сүз ычкындырмаса, табыннан ямь тапмас. Менә тагын садагыннан укларын алды:

— Әсгат ага, сез Ташкентта әниегез белән нинди телдә сөйләшәсез?

Белгәннәр тик тора дигәндәй, бу сорауның асылын аңлаганнар уңайсыз тынып калды. Әсгат ага нинди мәгънәсез сорау бирәсең дигәндәй аптырап кына:

— Татарча, әлбәттә, — диде.

Соңыннан, аңлатып биргәч, рәхәтләнеп көлде. Ә вакыйганың хикмәте шунда иде: Рафаэль Сафин бер елны Казаннан килгән каләмдәшләрен үз авылына кунакка алып кайта. Анда Рафаэльдән кала берәү дә башкортча сөйләшә белми икән. Табында бердәнбер Сафин гына чәй урынына сәй эчеп утыра.

— Кыланып утырмасана, улым, үзебезчә генә сөйләш инде, — ди әнисе аптырагач.

Рафаэль Сафин, тавышын сагайтып, бармагын Күк кендегенә тери дә:

— Ярамай, әсәй... бедгә ярама-ай... — ди.

Малеевкадагы иҗат йортында дистә еллар буена нинди генә язучылар булып китмәгән. Монда илһамлы фикер һавага таралган, агач ботакларына пәрәвез җебе булып эленгән, сукмакларга кош эзләре булып төшкән. Шуларны тотып ала гына бел, ак кәгазь каршында син инде вакыт белән бергә-бер көрәшергә чыккан хакими затка әверeләсең.

Андагы күңелгә якын сөйләшүләр... Мостай ага артыннан кәрвандай тезелешеп чаңгыга чыгулар. Кышкы кошларның үзенчә сайраулары. Тиеннәрнең, кыюланып, тәрәзә төбенә сикереп менүләре, тукранның, каты агач кәүсәсен серле тукылдатып, Морзе әлифбасы белән галәмгә хәбәр салуы... Болар бар да Малеевка урманының иҗат әһелләре хуш килерлек ганимәтләре иде.

* * *

Икенче кышта без Рәдиф Гаташ белән бергә туры килдек. Разил Переделкинода иде. Ул иҗат йорты Мәскәүнең Киев вокзалыннан читә торган якта, Твардовский, Фадеев, Пастернак кебек корифейларның әле дә исән дача-йортлары янәшәсендә зур ихатаны биләп тора.

Беркөнне, җыенып, кичкырын шул тарафка юл тоттык. Килеп төштек, каңгырап йөрибез. Ярый әле Муса ага Гали очрады, Разил күптән түгел генә Гариф ага Ахунов белән бергә Лев Ошанин дачасына кунакка киткән булып чыкты.

Мин Ошаниннның дача телефонын белешкән арада, затлы коньяк, кофе, шоколад исләре аңкып торган буфет янында кәкре башлы таяк тоткан бер өлкән кешенең зажигалкасыннан тәмәке кабыздым.

Моны күреп торган Муса Гали:

— Син кемнән ут алганыңны белдеңме соң? Арсений Тарковский үзе бит ул! — диде.

— Димәк, минем аркада тарихка керәчәк.

— Кайчан шул мактанчыклыгыңны ташларсың икән!

— Ул аның мәңгелек авыруы, — дип сүзгә кушыла Гаташ.

Ниһаять, табып, телефон номерын җыябыз. Трубканы башта Разил алды, аннары, нидер аңлатып, Ошанинга бирде.

— Марсель, приезжай скорей, для тебя дымит шампанское! — Ясалмарак булса да, хуҗаның кунакчыл, җылы сүзен ишетү рәхәт иде.

Урман-поселоклар аша киттек эзләп. Якты гына бер урамда басып торган өч кеше янына адресны белешергә дип тукталгач, Гаташ кычкырып җибәрде:

— Рәфкат абый, кадерлебез!..

Ул арада рус шагыйре Михаил Львов, күз алдында Рәфкат Маликовка әверелеп, татарчага күчте:

— И минем татарларым... — дип кочаклаша башлады. — Вот, познакомьтесь, со мной всемирно известный писатель Анатолий Рыбаков с супругой, а это, Анатолий Наумович, мои татары... Казан нишли, Казан... Сибгат абый!..

Без «Кортик», «Бронзовая птица» кебек маҗаралы әсәрләр язган Рыбаковның кулын кыстык. Алты-җиде елдан ул яңа романына Сталин образын кертеп дөнья шаулатыр...

Михаил Львов бик йомшак күңелле, самими җанлы шагыйрь икән. Хисләнеп сөйләшә-сөйләшә, Ошанин дачасына кадәр озата барды. Әмма тиз генә кереп китмәле түгел, капканы бәреп аударырлык итеп, ярыша-ярыша, эчтән ике эт өрә иде. Ул арада ихата түрендәге йорт болдырында хуҗа күренде, бер генә эндәшкән иде, этләр капылт тынып, әллә кая гына юкка чыктылар. Эчкә уздык. Веранда ягында Гариф ага, Разил утыралар. Өстәл мул, нинди генә илнең хикмәтле шешәләре юк. Ә теге этләр... Берсе зур гәүдәле, икенчесе карсаграк икән, шунда верандада йөриләр, баягы зәһәрлекләре юкка чыккан, күзләрендә бары кунакларга хөрмәт билгесе. Килеп ышкыналар, кулны ялап китәләр. Татар эте булса, кунак килеп кергәннән алып чыгып киткәнчегә хәтле, үз-үзен ярсытып, чәчәп, карлыгып, ябыгып беткәнче, камалый-камалый өргән булыр иде.

Без килеп кушылгач, табын отыры кыза төште. Мин Ошанинга Испаниядән алып кайткан китапны бүләк иттем. Евтушенко белән икәү алар Гарсиа Лорканың туган авылы Фуэнто-Вакироста булганнар. Икесенең дә шигыре кергән бу китапны мин шунда алган идем. Ошанин бүләгемне шатланып кабул итте.

Табын гөрле. Ошанин егетләрчә. Асравы Людмила Денисовна тәм-томнарны китереп кенә тора. Ара-тирә Мәскәүдән телефоннан шалтыраталар. Нинди тавыш ул сездә, дип сорыйлар, ахрысы.

Ошанин болай дип шаярта:

— У меня татарское нашествие! Нет, Чингизхана нет... Во главе с Ахуновым и Разилем Валеевым, моим учеником...

Разил, институтта укыганда, шагыйрь, профессор Лев Иванович Ошанин алып барган поэзия семинарына йөргән. «Шәп кеше, — ди. — Бик бетеренгән чагымда акча алып торган идем. Һаман түләгән юк әле. Алмый, баегач бирерсең әле, ди. Кайчан баермын, Алла белә...»

Яши белә мәскәүлеләр. Дача иркен, күркәм. Бер бүлмәдә камин тора. Мич кашагасында бөркет карачкысы. Ут тергезеп, учакка карап утырасы иде дә бит... Теләгемне Лев Ивановичка әйтәм. Сарайдан утын алып керергә кирәк икән. Мин кузга-

лам. Ике эте дә миңа ияреп чыга. Берсе уң, икенчесе сул ботка елышып, тар сукмактан мине тайпылдырмыйча алып баралар. Утын дигәне штабельләп өелгән имән паркет булып чыкты. Шәп утын — кисәсе дә, ярасы да юк.

Каминда чыртлап янган утка тәмәке төтене өреп, ак аю тиресендә аякны бөкләп утыру рәхәт икән. Бездә шушылайрак яшәүче язучы бармы, дип, Разил белән барлап карыйбыз. Юктыр. Мөмкинлеге булганнар бар. Әмма татар, байлыгы булса, кара көнгә дип оекка җыя шул, кефир эчүдән узмый. Үзе үлгәч, сантый балалары байлыгын исраф итеп бетерә.

Каминда ялкын үрсәләнә. Чибәр хатын-кызларны иләсләндереп гашыйк итү ягыннан Муса Җәлил тарафдары буларак, Разил төтенсу-өрфия күлмәкләрен җилфердәтеп биегән җарияләр чолганышында утырыр иде хәзер, әгәр үз ханлыгында яшәсә... Ризыкның да, сүзнең дә тәмен белеп кенә, дусларның да, яшьлекнең дә кадерен мыскаллап тоеп, фәкыйрь генә табынны да баетып, мул табынны исә тагын да күркәмләндереп җибәрү ягыннан аңа берәү дә тиңләшә алмыйдыр, мөгаен.

Һәр табынның да соңы җитә шул. Төнге икеләрдә без кайтырга дип кузгалдык.

— Тур! Степанида! Проводить гостей! — дип, Ошанин этләренә әмер бирде. Бер чакрым чамасы булыр, этләр безне озата килделәр дә, борылышка җиткәч, кайтып киттеләр. Без артларыннан шаккатып карап калдык.

— Их, безнең язучыларда да шундый эт акыллары булса!.. — дип, Гариф ага шаркылдап көлә башлады.

— Алай булса, «Эт кояшы»н да басарлар иде, — диде Разил.

— Һы! — диде Рәдиф Гаташ, ул безнең арада бердәнбер аек кеше иде.

— Яһүдләрнең эте дә зыялы шул.

Бусын кем әйтте, мин идемме, карлы тымызык төн идеме?..

* * *

Шанлы заманнарда Кырым капкасы ягыннан килгән хан аргамакларының тояк тавышын яңгыраткан, хәзерге көндә дә дәүләти машиналарны иңендә йөрткән Кремль урамы — мәркәзи Казанның иң күркәм урамнарыннан берсе. Шул урамда университетның клавиш-колонналарының ак шәүләсен зур тәрәзәләрендә чагылдырган сәнгатьле бина булыр.

Китаплар храмы ул!

Тоткалары арыслан башлы имән ишекләрне ачып керәсең дә кытай бизәкләре сурәтләнгән баскычлардан икенче катка күтәреләсең. Анда Разил Исмәгыйль улы Вәлиевнең тәрәзәләре якты урамга, Лобачевский бюстына караган кабинетына рәхим итәсең. Ул сине өстәл артыннан чыгып, ачык йөз белән каршы ала. Утырышып, бераз гәпләшүгә, секретарь кыз — Гүзәл туташ — күрәгәле, лимонлы чәй кертеп өстәлне бизи.

Әлбәттә, мин монда борынгы хан сарайлары, аксөяк каберлекләре, зиннәтле сәнгать әйберләре таланган, юк ителгән татарның бердәнбер милли байлыгы-мирасы тупланган олуг китапханә икәнен акыл-зиһенем белән аңлап кергәнмен. Шунысы куанычлы: Разил Вәлиев директор булып эшләгән соңгы дәвердә китапханә бинасының тышкы кыяфәте генә түгел, эчке асылы да күзгә күренеп үзгәрә, бөтәя бара.

Узган гасырда ук Россиядә Мәскәү һәм Санкт-Петербургныкыннан кала мәртәбәле урында торган бу китапханәнең меңнәрчә китаплары бүгенге көндә подвалларда тынчып ята икән, моны күреп кем битараф кала алсын. Бу — никадәр акыл, аңбелемнең тышаулы халәткә төшүе түгелмени! Менә шуларны ничек тә коткару, өстәмә бина табу, яңаны төзетергә проект әзерләү, китап белән эш итүче хезмәткәрләрнең дәрәҗәсен, матди хәлен яхшыртуны Разил Вәлиев кичектергесез максат итеп куя һәм моңа ирешеп тә бара. Аның булганлыгына, шушы миллионлы шәһәрнең лабиринтларыннан кирәкле нокталарны табып, шактый катлаулы хуҗалык эшләрен дә хәрәкәткә китерергә сәләтле икәненә күнегеп тә барабыз шикелле.

Ә бит ул, моннан егерме еллар элек туган авылы Ташлык мәчетенең кыйшайган манарасын торгызу уе белән янып йөргәндә, күпләребезне гаҗәпләндергән иде. Башта ул җеген-җеккә уйлап, югары инстанцияләрдәге җитәкчеләрне дә матур саташтырырлык кәгазьләр әзерләде. Чоры нинди бит: Алла сүзен кулланырга ярамаган, фәрештәләр канатын таптап, «якты киләчәккә» барган чаклар иде. Бабасы гыйбадәт кылган, әтисе мәктәп иткән мәчетнең манарасын менә хәзер улы торгызмакчы... Ул дәлилле сүзенә колак салырдай җитәкчеләрне дә үз ягына бора, осталарны да таба. Яшь вакытта ук дисбе турында уйланып юкка гына шигырь язылмагандыр, бәлки, әбисеннән калган дисбе төймәләрендә буыннан буынга күчеп килә торган саваплы доганың тәэсири җылысы калгандыр.

Манара төзелеп бетеп, очына Ай беркеткән вакытта, хәер-садакаларын тоткан Ташлык халкына күрше авыллар да килеп кушыла. Манарага менеп азан әйтергә җөрьәт итүчеләр дә табыла. Дәһшәтле дә, гаярь дә, соклангыч та халык ташкынына карап торган бу мизгелдә шагыйрь җанында ничек инде горурлык уянмасын! Ирек даулап, бу халык белән таулар күчерергә дә көч-дәрман җитәчәк.

Үз тарихын халык үзе ясый,
Бирми халык үзен үлемгә!

Манарага Айны беркеткәндә, якташларының өмет белән күккә баккан утлы карашын шагыйрь мәңге онытмас. Ходай рәхмәтенә мохтаҗ бу йөзләр, озак көттереп килгән куанычтан яшьләнгән бу күзләр, мең учак булып, шагыйрьне гомере буена җылытып торыр.

Шушы вакыйгадан соң, Казанга кайткач, Разилнең тәэсирләнеп сөйләгәне исемдә: «Халык ташкынын күрсәң... Башта куркып калдым. Искиткеч күренеш, соклanудан күзгә яшь килә. Халык бар икән ул, дары бетмәгән әле безнең...»

Милләтнең азатлыгы өчен көрәш дәвере килгәч, парламент мөнбәреннән чыгыш ясыймы ул, кануннар кабул иткәндә туры сүз әйтәме, публицистик каләмен кузгатамы — һәрчак аны халыкның беренче тапкыр кузгалышын күргән әнә шул онытылмас мизгелдә туган тойгылар кыю булырга өндәп киләдер.

Ләкин парламент мөнбәрләренә менеп җиткәнче, язмыш Разил Вәлиевкә шактый четерекле сынаулар әзерләп куйган иде. Чаллыдан соң, Язучылар союзы рәисе урынбасары итеп куелгач, аның баш очында болытлар куера башлады. Ерак китәчәк бу егет, дип көнләшүчеләр йокысыз калдылар. Ул дәвердә кешене юлыннан алып ташлау җиңел эшләнә, юк кына гөнаһын табып, шуны демагогик фикергә төрәсең дә... баш очында партия йодрыгы күтәрелә, акылга буйсынмый торган ул көчкә инде берәү дә каршы чыга алмый иде. Илне шикаять баскан, партия белән Черненко дигән туң акыллы астматик карт хакимлек иткән еллар иде ул. Бик кыска вакыт эчендә бөтен ил, чатнап, өч кисәккә бүленде: яла ягучылар, яла ягылганнар һәм шуны тикшерүче комиссияләр. РСФСР Язучылар союзына, Үзәк Комитетка ул чакта язучылар тарафыннан җибәрелгән аноним

хатлардан томнар төзеп булыр иде. Бер-берсе өстеннән яла ягып язылган, коточкыч пычрак анонимкаларны Мәскәү кабинетларында: «Менә татарларның чын йөзе!» — дип, мыскыллы көлә-көлә укыдылар. (Мәскәүдә укыган чак иде, кайберләренә үзем шаһит булдым.) Язучылар союзы рәисе Туфан Миңнуллинның бер чыгышы истә: «Әллә жалобачылар секциясе ачарга инде... Мәскәүләрдән оят. Шулкадәр хаталы язып җибәрәсез доносларыгызны!..»

Язучы буларак үз сәләтенә ышанып бетмәгән, бары тик урындык биләп кенә вакытлы данга ирешеп булу мөмкинлеген чамалаган бер төркем, шулай итеп, астыртын, мәкерле эш җәелдереп җибәрде.

Сибгат ага белән сөйләшүебез хәтердә. «Разил тирәсендә казыналар... Куркалар. Булдыклы егет... Күпме яклап карадым... Тегендә... Минем генә көч җитми», — дип, ул бәгыреннән ачынып әйтте. Соңгы елларда Разилгә карата аталарча якын мөнәсәбәттә иде ул.

Аккош күлендә Сибгат аганы актык күрүем булган икән. Рухы сынган, кәефе төшенке иде. «Союзга барасы килми... Тартмый... Әдәбият кемнәр кулына кала... Шуңа борчылам... Утыз җиденче ел кабатланган шикелле... Яшәүнең кызыгы калмады... Архивымны барлап бетерәм дә...»

Фикерен кинәт өзеп, әйтеп бетермәгән шикелле, тәкъдирдә язылганын да яшәп бетермәде, төп йортка ашыгыбрак китте шикелле. Болгавырга әйләнгән заманга үпкәләп, кемнәргәдер рәнҗеп китте гаделлек хакиме — соңгы могикан...

* * *

1985 елның сентябреннән бер көн: Эгей диңгезендә шторм купкан. Герострат яндырган храмның бер колоннасы гына торып калган Сәлҗүк шәһәре яныннан төштек тә, яр буенда зәйтүн куаклары арасындагы виллаларга урнашып алгач, су коенырга йөгердек. Кая ул, дулкыннар тау-тау килә. Без, бер төркем татар язучылары, хатыннарыбыз белән кулга-кул тотынышып, яр читенә бастык. Көчле дулкыннар аяктан егар булып китереп бәрә. Сабыйларча чыр-чу киләбез, кычкырышабыз. Шулчак Разил, дулкынга ташланып, эчкә йөзеп кереп китте. Диңгез кайный, шаша. Күк йөзе караңгылана башлады. Ә ул, безнең кычкырганны колагына да элмичә, отыры ерагая бара, дулкыннар арасында күмелеп, югалып ала.

Каядыр укыганым бар иде: Муса Җәлилне шулай Кара диңгездә чак коткаралар. Пошаманга калдык.

Шактый вакыт үткәч кенә, Разил ярга чыгып ауды. Икенче көнне, биек тау башына Мәрьям ана «туган» йортны тамаша кылырга менгәч, икебез генә калган тын арада ул болай диде: «Дулкынга каршы йөзә беләм мин. Юри эчкә кердем. Үлү бик җайлы икән, су төбенә китәсең дә... Барыбер яшәүнең кызыгы юк. Эгей диңгезендә үлеп калуы шәп бит!.. Аннары, уйладым-уйладым да... Дошманнарым минсез нишләр? Аларга күңелсез булачак бит...»

Аның уенын-чынын бергә кушып әйткән бу сүзләреннән мин Разилнең күңелендә нинди тетрәнүләр барганын азмы-күпме аңлаган кебек булдым.

Шул елны Разил өстеннән партия Үзәк Комитетына язылган шикаять (күпме тикшерү-казынулардан соң, ниһаять) идарә утырышында каралды. Утырыштан чыгып килүче кайбер язучыларның кызышкан йөз-кыяфәтләре истә...

Утызынчы елларда адәми затның кеше кешегә карата бүре дигән зәһәр асылын кузгатып, бер-берсен кырдырганнарын мин шунда ачык күз алдыма китердем. Татар язучылары бер-берсен сатып, кырышып бетергәч (фронтка киткәннәрен исәпләмәгәндә), инде бер дә кулга алыр кеше калмагач, Язучылар союзы рәисе итеп бакча каравылчысын куялар бит. Беркайда да кабатланмаган хурлыклы тарих.

* * *

Җаныңа урын таба алмаганда, Кырымга, Кавказга китеп бер онытылырга, ял итәргә дә була югыйсә. Разил Вәлиев ул чакта кайнар якка — сугыш давылы котырган Әфганстанга китеп барды. Бу бәхетсез ил белән танышуны ул Татарстанның элеккеге «ханы» — Фикрәт Табиев илчелегеннән башлый. Президент Бабрак Кармәлне күрәсе килүен әйткәч, шәп оратор, Брежнев чорында да курыкмыйча, саллы фикерен ярып сала торган Табиев болай ди:

— Бабрак у меня в кармане! Я сам привез его на своем танке!

Бу илнең хуҗасы кем икәнен аңлаган шагыйрь каршында Әфганстанны карта аша гына түгел, бөтен чынбарлыгы, фаҗигасе белән гамәлдә күрү мөмкинлеге ачыла. Ләкин сугышның хәтәр йөзен, сәясәтнең олы ялганга корылганын аңлап кайткан шагыйрьгә боларны язу насыйп булмый. Кисәтү өстендә кисәтү... Кулы артка каерылып бәйләнгән Муса һәйкәле сыман чарасызлык... Сызланган күңел үз эченә бикләнә бара, бикләнә бара...

Разилне каты авырып, хастаханәгә эләгер дип башка да китерми идек. Бер көндә түгел, елларга бүленсә дә, кайгы-хәсрәт барыбер төенләнеп, бер йөрәк аша уза икән. Әтисен җирләү... Үзеннән дә өстен күреп яраткан энекәше Рәмзилнең машина белән бәрелеп үлемнән калуы... Эштәге талкынулар, каләмдәшләренең хыянәте, каты бәгырьлелеге... Иҗат кешесенең нәзберек күңеле боларны кабат-кабат кичереп, яра өстенә яра ала шул.

Нәкъ шундый унике операция ясап, унике пациенты да үлгән табибның скальпеле астына кереп ятканда ниләр уйлагандыр, дүрт айдан соң Мәскәүгә кабат операциягә китәр алдыннан без Разил белән хастаханә бакчасында сөйләшеп утырдык. Ябыккан. Йөзе саргаеп, суырылып калган. Тонык тавыш белән сүзләрне сайлап кына сөйләшә. Картлар шикелле, үлем турында көтмәгәндә, ачыктан-ачык, тыныч кына әйтеп куйды:

— Күп уйландым бу айларда. Үлемгә фәлсәфи яктан да, рухи яктан да әзерләнеп беттем шикелле. Шактый күрелгән инде бу дөньяда... Артыгы кирәкми... Димәк, Аллаһы тарафыннан миңа кырык ел гомер бирелгән. Үлемгә әзер кеше чистарып кала икән. Эчтәге бөтен гөнаһларым чыгып бетте. Беркемгә рәнҗүем юк...

Үзем тыңлыйм, әллә соң бәхилләшүме бу, дип, үзем шомланып уйланам. Бүлдереп, нинди дә булса юату сүзе әйтү дә урынсыз, әллә нинди, күңелгә сыгылып иңгән авыр минутлар бу.

Бераздан яныбызга танышлар килеп өстәлде. Разил сүзне икенчегә борды:

— Әл-лә-лә, чибәр кызлар күп монда. Палатага килеп керәләр: сулышка каба... Хастаханәдә шундый чибәрләр эшлидер дип уйламый идем.

Шушы сүзе белән үлем турындагы фикерен үтерде дә куйды. Яши болай булгач, яшәргә тиеш «Яшисе килә!» авторы.

Нәсел-нәсәбенең нык тамырлары сут биргәнме, ихтыяр көчеме, җирдәге саваплы эшләреме, Кәҗәмөгез йолдызлыгының мәрхәмәтле нурымы — һәммәсеннән кәүсәр тамчылары кергәндер, әмма күңел догасының иң мөкатдәсе — үлемнән йолып калучы илаһи кодрәт иясе — Тәңрегә...

Яңадан туып, дөньялыкка кайтып төшкән Разилне Казан урамында очраткан бер шагыйрь, аның ябык кыяфәтенә карап, болай ди:

— Син бөтенләй Тукайга охшап калгансың...

— Йөз-кыяфәтне эшләдем, хәзер язасы гына калды, — ди Разил.

* * *

Китапханә турында сүз чыккач, без Төркиядәге Эфес хәрабәләрен карап йөргәнебезне искә төшердек. Үз чорында Архимед яшәгән бу шәһәрнең ак мәрмәр урам ташлары да, җир тетрәү аркасында җимерелгән бина калдыклары да исән иде. Амфитеатрга җитәрәк, мәйдан уртасында грек осталары бер бинаны торгызып яталар иде. Колонналы мәһабәт бина. Бу Эфеснең китапханәсе булган икән. Гаҗәп бит! Эфес шәһәренә безнең эрага кадәр уникенче гасырда нигез салынганлыгын да искәртсәк...

Хан, шаһ, корольләрнең китапка карашы югары дәрәҗәдә булуы борынгы заманнарга гына карыймы? Мәдәнияте үскән бүгенге илләрнең президентлары да китапны зурлый белә, китапханәләргә җитәкче итеп дәүләт эшлеклеләрен, зур галим-язучыларны куялар икән, димәк, кешелекнең киләчәгенә өмет бар.

Безнең милләткә дә, алардан гыйбрәт алып, үткәнгә һәм киләчәккә карап, рухи хәзинәсен барлар чак җиткән.

Татар язма китабының барлыкка килү дәвере ерак гасырларга, Шарыккә барып тоташа. V–X гасырларда Ислам империясе отыры көчәя, чикләре Кашгардан башлап Атлантик океанына кадәр барып җитә. Кордова, Каһирә, Багдадны кул астында тоткан өч бөек ислам хакиме үз сарайларында китап хәзинәсе булдыруны горурлык саный.

Шушы Ислам дөньясының дин, фәлсәфә, шигърияте белән кергән шифалы нур татар китабы язмышына әнә шул заманнардан килеп ялгана. Кол Галиләр япан дала күкрәгеннән генә калкып чыга алмый. Монда Шәрык белән рухи бәйләнешнең аз өйрәнелгән солтанатлы дәвер күперләре бар.

Аннары — Болгар ханлыгы, Алтын Урда, Казан ханлыгы җәүһәрләре... Туздырылган, яндырылган, дөньяга таралган, каядыр яшерелгән татар китаплары — болары үзе бер үкенечле тарих.

Шушы олы тарихны аңында һәм иңендә тойганнар гына бүгенге китапханә залларыннан үткән чакта галиҗәнап китапларның йөрәк тибешен ишетергә мөмкин.

Кайсы халык үзенә иң мәгънәле, иң биек пирамида кора ала? Ул пирамидалар гади телдә китапханә дип атала.

Разил Вәлиев, миллионнарча китап язмышына җаваплы буларак, милләтнең бибәһа мирасын алдагы чорларга җиткерүне дәүләти максат икәнен белеп, зур илләр казанышы белән чагыштыру мисалында эш алып бара. Бүгенге көндә Милли китапханә дөньяның иң зурлардан саналган китапханәләре белән элемтә урнаштырган. АКШның ике мең галим эшләгән Конгресс китапханәсе һәм Төркиянең Милли китапханәсе белән дә эшлекле элемтә җайга салынган. Электрон почталар, компьютерлар аша гына бәйләнеш тотмыйча, Разил Вәлиев үзе дә күп илләрдә үткәрелгән киңәшмә-форумнарда катнаша. Соңгы елларда ул Пекин, Нью-Йорк, Тель-Авив, Истанбул, Белград, Варшава, Барселона, Торонто, Лондон кебек мәртәбәле шәһәрләрне күрү бәхетенә иреште.

* * *

Ярты гасырлык гомер… Аны билгеләп, шаулатып уздырган тантаналардан соң, тагын ун ел гомер сызылып үткән. Бу дәвер эчендә дөньяда, илдә, һәммә кеше күңелендә кайнап узган тетрәнү-фаҗигалар, өмет-алгысынулар, кабатланмас вакыйгалар, борылып карап уйлансаң, исең-акылың китәрлек.

Борынгы Рим чорларыннан ук шулай килә: Цицерон, Аристотель, Сенека кебек акыл ияләре, сүз осталары, лирик каләмен читкә куеп, кырыс сәясәт дөньясына кереп киткәннәр. Җәмгыятьтә фидакарьлек соралганда каләм иясе читтә кала аламыни. Разил Вәлиев тә шигъри ритм кысаларыннан чыгып, сәясәт юлын сайлады. Халык эчендә кайнап, күзгә-күз, сүзгә-сүз килеп, көрәш-дуэльләрендә көндәшләрен җиңә-җиңә, үз көче белән халык депутаты булып сайланды. Милләтебезнең гасырлар буена омтылган хыялын, телен, мәдәниятен, тарихын саклау-үстерү буенча дәрәҗәле комитет җитәкчесе буларак, Разил Исмәгыйль улы хиссез кануннар теленә күчкәндә дә эчке иманына тугры калып, үз мәсләген фидакарьләрчә яклап бара.

Ул дәүләти мөнбәр биеклегеннән торып, милләтебезнең гасырлар буена тапталган хокукларын аягүрә бастырып күрсәтә; Шәрык олпатларына хас булганча, катлаулы мәсьәләләрне дә егәрле сүз хикмәте, тормышчан мисаллар белән сипләп, җанны уятырлык итеп исбатлый, дәлилле белү осталыгы аңа тумыштан бирелгән ганимәттер.

Ул — кешеләрнең гозерен тыңлый белә. Ярдәм күрсәтүне намус эше, нәсел-нәсәбеннән күчә килгән кешелекле сыйфатка тугрылык дип карый.

Ул — һәрчак халык арасында, җәмгыятьнең тере дулкынында кайный. Үзенең сайлаучылары белән очрашырга дип Түбән Камага ай саен кайтып килергә дә җай таба ул. Монысына инде үзем шаһит булганым бар. Аның кабул итү бүлмәсе ишеге төбенә илледән артык кеше җыела — яше, карты… Һәрберсенең үз язмышы, үз гозере, үз өмете. Ни гаҗәп: арадан биш-алтысы бер йомышсыз килгәннәр, рәхмәт әйтергә… «Теге вакытта сөйләшкән идек бит… Тәки барып чыкты… Булдыргансың… Рәхмәтләр укып туя алмыйм, үзең дә куанычта яшә, улым!..» — дип сөенечләрен эчкерсез уртаклашалар. Мондый үтенечләрне гамәлгә ашыру өчен күпме кабинет хуҗаларын кузгаткан, күпме борчу-мәшәкать лабиринтын узганын үзе генә белгән депутат — Разил Вәлиев өчен иң кадерле мизгелләр шушыдыр бәлки.

Күңелендә шигырь уты сулкылдап кабынганда үкенгән чаклары да буладыр. Сәясәт көле астында калган утлы кузларны актарып, каләм дәртен кузгатканда, бер-берсе белән чагышмаган ике яссылык арасында бәргәләнгән җаны (югалтулар аша — табу, табулар аша — югалту...) бер мәлгә лирик сүз кимәленә төшә алмыйча интегәдер…

Бәлки Аңа шушы аяусыз-кырыс сәясәт галәменең сүрүен ачып, эчке дөньясын саллы итеп сурәтли алу миссиясен дә йөкләгәндер Ходай…

Ни генә булмасын, аңа халкыбыз күз уңында, заманабызның мәртәбәле шәхесе, әдибе булып яшәү һәм яшьнәү бәхете бирелгән.

Җирдә яшәү дигән бөек могҗиза һәммәбезгә дә тик бер генә тапкыр иңдерелгән. Аның кадере дә шунда бит, яшьтәш,

каләмдәш!

Гомер тавына менеп, ерак офыкларга күз ташлыйк та (тәкъдирнең ачыласы күк капулары алда да булыр бит…), кайтавазы күңелләрдә кабатланырлык итеп, бер кычкырыйк әле:

— Язмышка рәхмәт!

*Марсель Галиев,*
*Татарстанның Г.Тукай исемендәге*
*Дәүләт премиясе лауреаты*

***

...Әйе, минем көчле рухымнан
җир вә күкләр калтырар.

*Һ.Такташ*

Елый-елый, сугыша-сугыша җирдә
Акыл күпме җавап эзләгән...
Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Йә булмаса үзем үзгәрәм.
Аңламыйлар, җилне зәңгәр, дисәң,
Тормышыбыз — сабантуй, дисәң.
Һәрнәрсәгә минем үз атамам:
Айны Кояш диям, теләсәм.
Чәчәкләргә үз исемем бирәм,
Мең тереләм көнгә, мең үләм.
...Үлем белән якалашканда да
Акны кара диеп сөйләмәм.
Дуслар юкта чын дуслыкны мактыйм...
Бу дөньяда яшәү — мең рәхәт!
Адашыпмы, кайчак килеп чыга
Безнең йөрәккә дә мәхәббәт.
Кайчак ялгыш уңны, сулны бутыйм,
Булгалый ла инде, булгалый...
Кешеләрдән гел яхшылык телим,
Мин хыялый бугай, хыялый.
Хаксызлыкны күреп ярсыйм, шашам,
Матурлыкны күреп тезләнәм.
Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,
Йә булмаса үзем үзгәрәм.

***

Маҗаралар дөньясында
Маҗаралар бетәрме?
Маҗарасыз картлыгымны
Бу йөрәгем күтәрме?
Дөнья тулы күзләремнән
Бу юләрлек китәрме?
Зәңгәр дулкын, ап-ак бәхет
Миңа кагылып үтәрме?
Зөһрәләрдән калган серне
Ул соң миңа сүтәрме?
Күлгә төшкән Ай шикелле
Әллә соң тик үртәрме?
Маҗаралар дөньясында
Маҗаралар бетәрме?
Бер мәхәббәт табар өчен
Бер яшьлегем җитәрме?..

*

***

Иң беренче төшкән карлар
Иң соңыннан эри, диләр.
Ә мин сиңа яз көнендә килдем,
Карлар эреп беткән чакта.
Иң беренче янган йолдыз
Иң соңыннан сүнә, диләр.
Ә мин сиңа таң атканда килдем,
Йолдызларың сүнгән чакта.
Күп еласаң, бер көләрсең,
Бик күп көлмә, бер еларсың, диләр.
Мин боларның кайсына да
Ышанырга белмим.
Тик онытма шуны:
Бу дөньяга
Көлеп килсәм киләм,
Ләкин елап үлмим.

***

Зәңгәр кабырчыклар эзләп килдең.
Табалмагач ташка эндәштең.
Үтенүләр, ялварулар нигә?
Аңлыймыни диңгез күз яшен.
Диңгездә тик зәңгәр сагыш яши.
Бу хаклыкны күптән ачканнар.
Бәхетеңне генә югалтырсың,
Йөрәгемә төшмә, акчарлак.

***

Язлар миңа сине китермәде.
Хәбәр бирми үтте җәйләр дә.
Ничәнче ел инде бу йөрәгем
Җир тирәли ялгыз әйләнә.
Бураннардан табармын күк сине.
(Юраганга, диләр, юш килә.)
Яз гөлләрен күкрәгенә тезеп,
Тәрәзәләр әнә төш күрә.

## МИНЕМ ӘТИ

*Дустым көндәлегеннән*

Минем әти
Тарих тәгәрмәченә
Тимер кыршау кидергәндә
Таптапып үлде...
Иптәшләрем
Чал сакаллы әтиләренең
Үткәннәрен
Әрни-әрни сөйләгәндә,
Мин
Кабер ташлары белән сөйләшәм.
Кеше гомере —

Тулы бер ел:
Язы була,
Җәе, көзе, кышы.
Тагын бер кат
Язлар күрү уе белән янып,
Иске ел үлә.
Минем әти һаман яз аенда!
Минем әти һаман кырык биштә!
Минем әти мәңге кырык биштә!
Минем әти...
Тапталып үлде...
Тимер кыршау кидергәндә...
Тарих тәгәрмәченә...
Минем әти!..

## ИЛЛЕ ЯШЬ ТУТЫРГАН АБЫЙЛАР

Гасырга унҗиде яшь тулган...
Давыллы карт Идел буенда.
Әтиләр канында сабыйлар...
Уемда, уемда, уемда.
Гасырга өч дистә кагылган —
Дошманнар зур Идел төбендә.
Буразна башында малайлар...
Күңелдә, күңелдә, күңелдә.
Гасырга кырык бер яшь тулган...
Кичләрен ал Идел буенда
Кул болгый тузгыган толымнар...
Уемда, уемда, уемда...
Гасырга кырык биш яшь тулган...
Мең кояш шат Идел күзендә.
Елаусыз, көлүсез минут юк
Күңелдә, күңелдә, күңелдә.
Гасырның чәченә чал кунган...
Яшь Идел, сыйсаңчы куенга.
Илле яшь тутырган абыйлар
Уемда, уемда, уемда.

## ГАШЫЙК БУЛГАЧ

Бер тамчы су — төссез.
Бер бүлмә һава — төссез.
Океан — зәңгәр.
Күк тә зәңгәр.
Кайчандыр бу күзләр төссез иде...
Хәзер — зәңгәр!

***

Аны миннән көннәр генә алды.
Йөрәк каргый хәзер елларын.
Сагынганда инде элеккечә
Ызаннарга ятып еламыйм.
Ләкин әле җитәкләшеп йөргән
Урман сукмакларын юксынам.
Гомер юлым тагын шул сукмакка

Алып барып чыгардыр сыман.

***

Җилләрне син күп күргәнсең, дисең.
Сөелгәнсең, дисең, сөйгәнсең.
Сөенечтәнме, көенечтәнме икән
Керфекләрең юган күз яшең?
Алдый алмыйм,
Диңгез диңгез инде, —
Җилләр күрсә,
Диңгез теле белән сөйләшә.
Бу дөньяда яшәү нигә кирәк,
Җилләр миндә дулкын күрмәсә?
Ә син миңа Одиссейны җиңгән
Соңгы давыл булып кил әйдә!
Тик башкалар күрмәсеннәр, яме,
Кешеләргә:
— Әнә бит ул
Минем арттан болытларга менде, диеп,
Яшен теле белән сөйләмә.

## АЛ ЧӘЧӘК

Чәчәкләр аланында йөрдем.
Күпме ак чәчәкләр — саф чәчәкләр.
Зәңгәрләре күпме, сарылары.
Тик ал чәчәк берәү генә...
Такыялар үрдем.
Ак чәчәктә — ак бәхеттер,
Зәңгәрендә — мәхәббәттер,
Сарысында — сагышлардыр...
Барын җыеп такыялар үрдем.
Бер ал чәчәк күрдем.
Бер чәчәктән такыя үреп буламыни?
Ал төс белән сары янәшә торамыни?

Чәчәкләр белән исәнләштем.
Йөрәк сорый:
— Ак чәчәктә ак бәхеттер,
Зәңгәрендә — мәхәббәттер,
Сарысында — сары сагыш,
Ә ал чәчәк нигә ал икән?
Беләсе иде.
Кулларыма алып
Оялчан таҗын,
Таҗы эчендә нәрсә барын
Күрәсе иде.

Чәчәкләр белән саубуллаштым.
Ал чәчәкне үзем белән алдым.

Чәчәкләр белән тагын исәнләштем.
Ал чәчәкне кабат алып килдем.
Кичерегез мине, чәчәкләр!
Инде хәзер
Аның нигә ал икәнен белдем.

Кичерегез!
Ул бит миңа
Нигә ал икәнен сөйләде.
Кичерегез!
Минем
Бөресе дә ачылмаган бер чәчәкнең
Таҗын күрәсем,
Төсен беләсем килә.
Кичерегез!!

## МИЛӘҮШӘЛӘР БӘХЕТ ӨЛӘШӘ

Елгаларның бозы елаган чак.
Кушылып үксер идем, көлмәсәң.
Сөйли халык:
— Язга күкрәк ачып,
Миләүшәләр бәхет өләшә.
Елгаларга кушылып елаган чак.
Ташкын булыр идем, теләсәң.
Сөйли халык:
— Ашык, тизрәк, ашык —
Миләүшәләр бәхет өләшә.
Ташкын булып ашып ташыган чак.
Болыныңа киләм, сүнмәсәң.
Сөйли халык:
— Менә шушында, дип,
Миләүшәләр бәхет өләшә.
Болын күкрәгендә сары чәчәк.
Елар идеммени, көлмәсәң.
Соңлаганмын, җилләр килеп киткән...
Миләүшәләр бәхет өләшкән...

## САУБУЛЛАШЫР ӨЧЕН БАРГАЧ...

Саубуллашмый киткән идем синнән,
«Хуш мәңгегә» сүзен әйтер өчен
Кире килдем.
Өегезгә исәнләшеп кердем.
Кулың бирдең.
Күз куеныннан алып,
Чәчәкләргә
Җылы сулыш өрдең.
Ә соң нигә өрдең?
Алда кыш торганын,
Табигатьнең догма икәнлеген
Күрдең бит син, күрдең.
Үткән барыбер кире кайтмый,
Ул кайтмаска киткән.
Саубуллашыр өчен баргач,
Исәнләшмә икән...

## ИКЕБЕЗ ДӘ АЛДАДЫК...

Чәчәк өзеп бирдең.
Бу — мәхәббәт, дидең.
Сукыр идем.
Тымызык күлгә алып кереп,
Бу — зур диңгез, теләгәнчә йөз, дидең.

Сукыр идем.
Мин төсләрнең санын белми идем:
Барысы шушы, диеп,
Җидесен дә бирдең.
Мин дә юмарт идем.
Ә син
Кыргый җимешләрдән бик тиз туйдың.
Яр буеннан икебезгә
Зур алмалар алып керим диеп,
Алдап китеп бардың.
Ә мин сиңа җавап итеп:
— Сине сөймәдем дә һәм сөймим дә, — дип
Алдап калдым.
Төсләрне мин
Тагын аера белмим инде.
Салават күперен
Кояш тагын йөрәгенә яшерде.

## ВАЗАДА ЯЗ

Ачы буран...
Егетенең кочагына сеңгән
Капрон оеклы кыз яз көтә.
Бөреләрен учларында сузып,
Яшь каеннар, карт имәннәр көтә.
Бозларыннан иңрәп,
Мәңге кыз елгалар көтә.
Ак болытлар,
Беренче кат күкрәп,
Шашып елау көтә,
Сөю көтә.
Ә вазада инде күптән яз.
Куллар кулны эзли, күзләр — күзне,
Ә аяклар —
Карда калган ялгыз эзләрне.
Ә йөрәкләр күптән йөрәк эзли,
Иреннәрдә пышылдаган сорау
Иреннәрдән эзли сүзләрне.
Ачы буран...
Ә вазада инде күптән яз.

## ГАРМУН УЙНЫЙСЫҢ

Гармун уйныйсың...
Синең кулларда күпме кояшлар,
Йолдызлар,
Диңгезләр,
Давыллар.
Ә мин дөньяга гашыйк.
Гармун телләренә басып
Өскә менә,
Аска төшә,
Йөгереп китә,
Туктый йөрәгем.
Кинәт...
Бармакларың алдың йөрәгемнән...

Нигә тындың?
Кояшларда,
Йолдызларда,
Диңгезләрдә
Давыл тынды...
Ә мин шау дөньяга гашыйк.
Тукта!..
Чү!..
Йөрәгем кояшлар янында
Адашып калган.
Ә син гармун уйный идең.

***

Кыш бабайның һәрбер кызы
Яз була, дип өйрәттеләр.
Мин кызларның
Унҗидесен күрдем:
Әй усаллар инде,
Йөрәгеңне күрсәт, диләр.
Унсигезенчесе,
Яздан хәбәр биреп,
Керфекләргә кояш тамчылары тезде.
Ә югыйсә
Эндәшмәде дә бит үзе.

## АВТОБИОГРАФИЯ

Мин дөньяга
ярсып елый-елый килдем.
Баштарак,
елый-елый,
әнием күкрәгеннән татлы сөт сорадым —
алдым...
Миннән зурракларның
ике аякта басып йөргәннәрен күреп,
елый-елый мүкәләдем.
Көнләдем, таләп иттем —
алдым...
Кешеләрнең көлгәннәрен күргәнгә түгел,
бәлки
күзләремдә кояш уйнаганга,
тамак төбемне җылы сөт кытыклаганга
көләргә өйрәндем.
Йомшак ипи чәйнәрлек
сөт тешләрем чыкты —
чын күңелдән сөендем.
Вакыт җитте —
алар какшадылар...
Тешсез калам диеп куркып,
төннәр буе елап чыктым.
Һәм беркөнне
алсу аңкавымнан
дөньяның катысын кимерерлек
каты тешләр төрткәч,

бәхетем эчемә сыймаганга
көлдем!
Елый-елый көлдем.

Бүген минем нәрсәләрем юктыр —
белмим...
Өметем бар, ләкин
түм-түгәрәк өметем —
күгем.

## КЕШЕ

Бу дөньяның мин бер кисәкчеге,
Мин — кечкенә генә материк.
Таулар да бар миндә, упкыннар да,
Батырлык бар миндә, матурлык.
Бу дөньяның мин бер кыйтгасыдыр...
Урман миндә чәч дип атала...
Минем кояш — бәхет, аем — шатлык,
Яңгыр булып миннән тир тама.
Кайгыларым җир тетрәве төсле,
Сагышларым — гүя ак томан,
Чишмәләрем — чиста күз яшьләрем,
Ә сүзләрем буран, җил сыман.
Култык та бар миндә, бугаз да бар,
Ике күзем ике күл кебек.
Ә йөрәгем — утрау, утыра ул,
Дулкын күбегенә күмелеп.
Тарих миндә хәтер дип атала...
Ак битләре инде аз аның.
Очы да юк аның, уртасы да,
Күреп булмый аның азагын.
Баш миенең сырларына ятып,
Хәтер сөйли үзенең үткәнен...
Ничек итеп җирләр, кыйтгаларның
Океанга батып беткәнен...
Ул заманда җир дә җир дип түгел,
Башка исем белән аталган...
Чәчләремне, күзләремне капшыйм...
Алар миңа мирас атамнан.
Кеше атлы нәни бер кыйтга мин...
Матурлык бар миндә, батырлык.
Күпме тырышсаң да, булмый мине
Хәят диңгезендә батырып!

## 1. ТӨСЛӘР

Бихисап дөньяда буяулар...
Җир үзен яшелгә буяган...
Тургайлы үзәнгә карыйм да
Җанымны җылыткан уй табам.
Кызыл төс күрдисәм — кан уйный,
Зәңгәр төс күңелгә моң сала.
Нигәдер төсләргә табынам,
Тормышым бертөсле булса да.
Сап-сары көземә күз багып,
Җаныма сагышлы уй табам,
Салават күперенә сокланып,
Уйларда, хисләрдә буталам.
Үгиме әллә мин дөньяда?!

Илдә җәй, ә миндә кыш һаман...
Буранда югала бар төсем —
Дөньяда ак, кара төс кала.

## 2. ҖИР БЕЛӘН САУБУЛЛАШУ

Нишлим инде, тагын китәм...
Сау бул, җир, сау бул, күгем.
Мәңге монда яшь түгәргә
Мин ялгыз каен түгел.
Кара балчык — матәм кебек,
Кызыл балчык — кызыл кан,
Сары балчык — минем кайгы,
Ак балчыгың... югалган.
Барысын ташлап китәм инде,
Миңа зәңгәр төс кирәк.
Бәлки, дулкыннар күтәрер
Биеккәрәк, өскәрәк...

## 3. ДИҢГЕЗДӘ

Саумы, диңгез, саумы, давыл!
Саумысез! — дип кычкырам.
Дулкыннары, мине күреп,
Каршыларга чыктылар.
Тауларга менеп кычкырдым,
Үзәнгә өстән карап:
«Монда алтын балык иле,
Монда ярык тагарак!»
Таулар күкрәп куәтләде,
Тик эндәшмәде үзән...
Алтын балык та килмәде...
Яшь тәгәрәде күздән.
Ярык тагарак югалган,
Ак йолдызлар сүрелгән;
Үләннәре томырылып
Ярга таба үрелгән.
Диңгез зәңгәр түгел икән,
Дулкыннар бишек түгел.
Бар өметемне югалттым...
Калды түгәрәк күгем.

## 4. ДИҢГЕЗ БЕЛӘН САУБУЛЛАШУ

Кара балчык — кызлар чәче,
Кызыл балчык — таң кебек,
Сары балчык — сагыну күк,
Ак балчыгым — ак өмет.
Җирдә — шатлык, җирдә — җылы,
Җир — Кояшның сүзе күк!
Ә диңгездә акчарлаклар
Канатлы сагыш кебек.

***

Һәр көз саен таллар телсез калган,
Телсез калган юкә, имәннәр:
Яфракларын җилгә чәчә-чәчә
Язга кадәр алар үлгәннәр.
Яфраклары үлгән, карлар күмгән,
Җир җылыткан ләкин тамырын...
Көзге җилләр телем алсалар да,
Тамырымда мәңге калырмын.

## ҖИРГӘ МӘДХИЯ

Бу агачлар агач түгел әле,
Бу агачлар — җирнең өмете.
Бу далалар дала түгел әле,
Бу далалар — җирнең киң бите.
Елгалар да елга түгел әле,
Алар бары җирнең күз яше.
Таулар да тау түгел — җир сакчысы,
Ә болытлар — җирнең түшәге.
Давыл, туфан, вулкан — берни түгел,
Алар җирнең көче, тавышы.
Бу бомбалар бомба түгел әле,
Бу бомбалар — кеше ялгышы.
Кояш кояш түгел — җир яктысы,
Ә йолдызлар — җирнең маягы,
Мине сугыш исән калдырмады,
Мине шушы җирем аяды.
Ул ул түгел әле, ул — минем дус,
Күк — күк түгел — Киек Каз Юлы.
Мин мин түгел әле — мин уйламыйм,
Минем аша Җир бу, Җир уйлый.

***

Дөнья матур Такташ җырлаганча,
Тукай шигыре кебек оптимист.
Мәшрикъ белән мәгърип буталдылар...
Менә гаҗәп! — таң аттырдык кич.
Айны ваклап йолдыз ясадылар,
Кеше саен хәзер бер йолдыз.
Юллар тигез, арттан еллар куа.
Без соң әле кая барабыз?

***

Егет икән, әйдә, егет булыйк!
Ак мендәрне кочып елыйк та...
Акыл, йөрәк, горурлыкны алып
Чыгып китик моннан еракка!
Кара җирдән ап-ак бәхет эзләп,
Картлар киткән, киткән малайлар.
Әйтерсең лә далаларга китеп
Язмышыннан качкан бала бар...
Күлләр диңгез булган, диңгезләр — күл,

Буталганнар таулар, үзәннәр.
Тәне анда, җаны илдә килеш
Яшәгәннәр алар, түзгәннәр.
Бәхет туган җирдә икәнлекне
Ышандырган вакыт аларга.
Кара түбәтәйле картлар кайта
Шул туфракка ятып карарга.

## ТОРМЫШ

— Кояш ерып,
чыклы аланда
таңнан нишләп йөрисең?
— Мин бит сабый,
мин урманда адаштым.
— Кояш таптап,
чәчәкле аланда
иртән нишләп йөрисең?
— Мин — яшүсмер,
җирне каргыйм:
ярлы да ул, саран да.
Мин — яшүсмер,
мин урманда юл таптым.
— Кояшны онытып,
җиләкле аланда
көндез нишләп йөрисең?
— Мин бит гашыйк...
Мин бәхеттә,
мин хәсрәттә адаштым.
— Төнгә каршы
сары аланнан
кая болай ашыгасың?
— Кояш артыннан.
— Айны саклап,
кара җирдә
төнлә нишләп йөрисең?
— Мин — кайтаваз,
Җирне зурлыйм:
бик бай да ул, юмарт та!
Мин — кайтаваз,
мин кояшны югалттым.

## МЕТАМОРФОЗАЛАР

Карый-карый күзем дөнья булды,
Үсә-үсә дөнья күзгә тулды.
Ага-ага инеш Идел булды,
Агып томан булды Идел суы.
Үсә-үсә имән бөре булды,
Бөре йөрәгендә чәчәк туды;
Ә чәчәкнең тәне орлык булды,
Җаны очты, сызылып калды юлы.
Үсә-үсә сабый егет булды,
Әти булды әтисенең улы.
Үсте, үсте, бөтен нәрсә үсте,
Һәм дөньяда зур мәхәббәт туды.

***

Елмаерга өйрәтермен сине... —
Тик елама гына, елама.
Сабый шул син. Ярны сынамыйча,
Карагансың текәп елгага.
Ышанырга өйрәтермен сине... —
Үткәннәрең генә уйлама.
Бер ишелгән әйдә ишелсен дип,
Елга ярын юри буйлама.
Мин көләргә өйрәтермен сине... —
Тик елама гына, елама.
— Ул үлде, — дип җавап бирдем бүген
Сине сорап килгән елларга.

*

**ВАКЫТ**

Арыдым бүген.
Дөньядагы барлык сәгатьләрне
туктатып,
бер йоклыйсы иде.
Әй, Җир!
Үзең белән әйләндереп
тилмертмәче мине.
Әй, Җир!
Бер минутка гына туктыйсы иде.
Арыдым бүген.
Кичтән бирле
үзем генә киләм.
Әй, Җир!
Кирегә әйлән әле?!
Ул бит артта калды...
Әй, Җир!!!
...Тыңламый Җир...

***

Төн карасына каләмемне манып
хатлар язам,
карам беткәнче язам...
Ә син
шуны да белмисең,
йөрәгеңне кулларыңа тотып
килмисең.

**КАРТЛАР ЗАРЫ**

Безнең йөрәкләрне
сулган, дисез,
анда
мәхәббәт чишмәсе
күптән кипкән,
ялкыннары сүнгән, дисез...

Коры әйберне
ялкын тиз алганын
белмисез.

## МӘХӘББӘТ

Монда Кояш
океан төбеннән күтәрелә.
Монда сукбай һәм буйдак Ай —
кул сузымы җитә.
Монда давыл
дулкын биеклеге белән үлчәнә.
Монда болытларның күз яшьләре
иш янына куш кына бит.
Монда бар йолдызлар,
ике пар күз караганга, ахры,
бик якыннар һәм бик тоныклар.
Монда юллар, сукмаклар юк.
Монда адашканнар —
Өметсез өметлеләр.
Монда төн һәм көн бар,
кыш һәм җәй юк.
Монда
шигырь,
шигырь,
шигырь —
Шагыйрьләр юк.

## МӘХӘББӘТТӘ АЛДАНГАННАР ҖЫРЫ

Әй бай идем, шундый бай идем мин...
Акылым булды, булды йөрәгем.
Кемнең миннән нәрсә урлаганын
Күз яшьләрем аша күрмәдем.
Әй бай идем, шундый бай идем мин...
Бер бөркетем калды читлектә.
Анысын да югалтыр дип уйлап,
Тәрәзә артында соңгы чик көтә.

***

Иң беренче
уйчан булуыңны сөйдем.
Аннан — исемеңне.
Аннан — сүзләреңне,
аннан — борыныңны,
күзләреңне,
сөям диюеңне,
минем янга
йөгереп килгән чакта
күкрәкләрең белән бергә
биюеңне.
Хәзер исемеңне сөймим,
бары исемеңне.
Ачуланма,

исемеңне генә алыштырыйм,
исемеңне...

## АЛМАГАЧЛЫ ӨЙДӘНМЕ СИН?

**I**

Егет:
Алмагачлы өйдәнме син?
Алмагачка сүзем бар.
Кыз:
Алмагачлар өнсез әле —
Алмагачлар бөредә.
Егет:
Алмагач бөреләренең
Син белмәгән күзе бар.
Кыз:
Ул күзләрдән таң атканда
Яшел шатлык күренә.
Егет:
Ак чәчәкләр эзләр идем
Шул күзләрнең түрендә.

**II**

Егет:
Алмагачлы өйдәнме син?
Алмагачка сүзем бар.
Кыз:
Алмагачның юләр чагы —
Алмагачлар чәчәктә.
Егет:
Чәчәкләргә сөйләрмен дип
Саклап йөрткән серем бар.
Кыз:
Серләрендә — кайгы төсе...
Калдырчы киләчәккә.

Егет:
Таҗына ятып хәл җыялмыйм...
Чәчәк коела чәчкә.

**III**

Егет:
Алмагачлы өйдәнме син?
Алмагачка сүзем бар.
Кыз:
Алмагачның юмарт чагы —
Алмагачта мең күкрәк.
Егет:
Алмагачның бәхетендә
Күпме сафлык, түзем бар!
Кыз:
Бар алмасын алыр әле
Яшьле болыт бер күкрәп...
Егет:
Алмагачлы өйдәнме син?
Сиңа әйтер сүзем бар.

***

Юкәнең балланып килгән,
Миләшнең ап-ак чагы.
Төне буе көлде алар,
Янды урман учагы.
Таң атуга, миләш китте...
Юкәне кортлар сарды.
Усал гайбәт тараттылар
Карурман куаклары.
Олы алан уртасында
Юкә ялгызы калды.
Миләш карт имән төбендә
Куак белән шаярды.
Урманда көз. Орлыклы һәм
Җимешле агачлары...
Тик юкәнең каны зәңгәр,
Миләшнең бәхете сары.

## ...ГА

Тешләреңә бәрелеп чыңлый-чыңлый
Көлү тавышың соң кат ташыган.
Яшь каенның яшел күкрәгендә
Яшеренгән күпме яшь булган.

## АЛМА

Алма өзелеп төште
Кызның уч төбенә.
Кем ташлады аны,
Кем ташлады?
Толымнарның тынычлыгын алды
Кем ул анда, кем ул?
Керфекләргә таң чыклары тезде
Кем ул анда, кем ул?
— Синме бу?
— Килдеңме?
— Синме?
Беркем дә юк,
Бернәрсә юк —
Бары җил генә...
Уч төбендәге алма
Тәгәрәде җиргә.

## ҮТЕНЕЧ

— Сагышларың оныттыңмы? — дисең,
ә нигә соң үзең
үткәннәрне күмгән
каберлекне эзләп йөрисең?
(Теге пар каен төбендә
ялгызыңны күрдем.)
Кирәк түгел, кагылмачы! —
мин аларның барысын да
йөрәгемә күмдем.

## МИН КОЯШНЫ СӨЙДЕМ

Мин Кояшны сөйдем.
Миллион таңны алып килгән ике бите
тапсыз булган өчен,
иреннәре тулып торган өчен
мин Кояшны сөйдем.
Мин Кояшны үземнеке генә диеп белдем.
Ул көлгәндә көлдем.
Ул болытлар күрсә,
мин
сагынуның татлы сагышын тойдым.
Мин Кояшны кояш булганы өчен сөйдем.
Ә ул
      көлде,
            көлде,
                  көлде.
Яз бар иде,
үтте.
Көз килмәде,
                        кыш килмәде...
Тик җәй, тик җәй генә булды.
Мин әлсерәп күләгәгә качтым,
Ә ул күрде, һаман көлде.
Мин йөгереп төнгә кереп киттем...
Ә ул инде хәзер көлмәде...
Кызарынган битенә ал яулыгын ябып,
чигенә-чигенә сүнде...
Айны сөйдем.
Төнлә януына сокланып,
әлсерәгән йөрәгемә ләззәт табып,
Айны сөйдем.
Һаман-һаман
төннең куенына
ныграк кердем.
Айны сөйдем.
Кергән саен
иреннәренең ап-ак,
битләренең гел тап икәнлеген күрдем.
Сиздермәдем,
                         көлдем.
Салкынлыкны тойдым,
                              туңдым,
                                айныдым.
Адаштым, саташтым, даулаштым...
Хәлдән таеп,
таңның итәгенә килеп тезләндем...
Мин Кояшны кояш булганы өчен сөйдем.
Мин Кояшны үземнеке генә диеп белдем.
Мин бу Айны ай булганы өчен сөйдем.
Мин бу Айны кояш кызы диеп белдем.
Мин
        үз күзләрем белән
Кояш белән Айның очрашканын күрдем.

## СОҢГЫ ҮТЕНЕЧ

Янәшәңнән үтеп киткәндә дә,
— Нишләп йөри бу, — дип
орышасың...
Миңа артык берни кирәкми бит,
бары
мине сөймәвеңә,
мин ышанган кебек,
сине сөюемә ышан син.

***

Көз.
Чибәр кызый,
елый-елый,
иядәшкән күлмәген алыштыра.
Бөтен гәүдәсеннән,
кызыктырып,
байлык, муллык ташып тора.
Көз.
Оялчан шул кызый...
Күрсәтергә курка байлыгын.
Керфекләрне бөгә, күзгә өрә,
биткә каплый
сөттәй яулыгын.
Көз.
Түз, йөрәгем,
түз.

## КОЯШКА МӘДХИЯ

Шәп егет тә инде бу Кояш!
Ә мин үзем,
егет кеше була торып,
бер кыз өчен күпме яшь коям,
Мәсхәрә һәм оят!
Җитте, йөрәк, җитте, шашынма!
Бүгеннән соң һәр кыз белән
кызарынып исәнләшеп,
кызарынып саубуллашырга!
Шәп егет тә инде бу Кояш!

***

Хатларыңны утка яктым синең.
«Сагыш» сүзе, «сагынам» сүзе, «сөям» сүзе янды.
Үткән язда, утка салып мине,
«сөям» сүзен, «сагынам» сүзен, «сагыш» сүзен
алган идең.
Кире бир аларны!
Гөнаһларым бик күбәйгән икән...
Синең янга йөгергәндә
юлымдагы бер йөрәкне таптаганмын.
Хәзер түлим аны.

Карашымның бер җылысын көтеп,
салкын йөргән кызны
күрә торып,
көлә-көлә
янар елларымны алдың.
Кире бир аларны!
Ә... юк...
алар... янды инде...
Хатларыңны утка яктым синең.

## ЯКОРЬ

Нәрсәдер әйттең,
нәрсәдер кычкырдың,
давыллардан туйдым, дидең бугай.
Нәрсәдер шалтырады,
нәрсәдер ычкынды
түземсезлек якоре бугай.
Хәзер инде
артта — ал офыкта
соры корабыңның
ак яулыгы гына күренә.
Мә-ә-ә-хә-ә-ә-ббә-ә-әт!!!

## ВӘГЪДӘ

Оҗмах вәгъдә итмим сиңа...
Бик тар әле чикләрем.
Бар байлыгым — шигырьләрем
Һәм дә кара икмәгем.
Күкне бирә алмам  сиңа...
Йолдызсыз да итмәмен.
Айны бөтен көе саклап,
Сине, ахры, көткәнмен.
Шатлыкларым тулы килеш,
Кайгымны да түкмәдем.
Йортым тәбәнәк булса да,
Биек әле күкләрем.
Бәлки, бәхетле булмассың...
Бәхетсез дә итмәмен.
Оҗмах бирәм димим сиңа,
Тәмугка да кертмәмен.

***

Төне буе шигырь язып чыктым,
Таң атуга инде көз килгән.
Шәрәлеген күреп телсез калган
Өрәңгеләр чагыла көзгедә.
Бар шигырем язга багышланган,
Идеалым — ап-ак алмагач.
Язда иде бөтен өметләрем...
Җәй алдамас инде, алдамас.
Ә урамда бүген көз көзгесе —
Җәе дә юк анда, язы да.

Зур сөюдән өмет өздем инде,
Ярар иде әле азы да.

## ТАУ КЫЗЫНА

Тауларың тора томанда,
Туңып, өшеп, калтырап.
Бозларын эретер идем,
Җан җылысына урап.
Төш инде, төш син түбәнгә,
Мин мәңге тауга менмәм.
Сулар да ага үзәнгә,
Ташлар тәгәри түбән.
Кыяларда яши алмый
Үзән җирдә туган тән...
Сикер әйдә! — Колач җәеп,
Упкын төбендә көтәм.
Таудан биек горурлыгың...
Син — Сок, ә мин Сак кебек.
...Әфлисуннар лимон булды,
Туган ягын сагынып.

***

Останкино. Җиденче кат күктә,
Таш шәһәрдән өстә — ресторан.
Саф татарча җырлап,
ресторannaн
биегерәк җиргә исәп бар...

## БУМЕРАНГ

Ташладым мин юлда дусларымны...
Дошман булып кире кайттылар.
Кайттылар да ялгышларым җыеп,
Таш урынына йөзгә аттылар.
Оныттым мин бик күп чибәрләрне...
Гайбәт булып кире кайттылар.
Вәгъдәләр һәм антларымны җыеп,
Йөз бәягә артык саттылар.
Ялгышлар һәм гайбәтләрне җыеп,
Еллар елгасына аттым да...
...Чыгалмыйча шунда баттылар.
Һәм тагын да чибәр кызлар булып,
Шатлык булып, якын дуслар булып
Минем янга кире кайттылар.

***

Мәскәү, Мәскәү...
Монда кем аңласын мине,
Кем соң минем көйне көйләсен?!
Кулларымны сузып аста көтәм... —
Ыргыт миңа, ыргыт кочагыма
Останкино Сөембикәсен!

## ЯЗ

Утызы да тулмый февраль киткән...
Урамнарга шыплап март тулган.
Агачларның саллы җәясенә
Ук түгел лә... яфрак тартылган.
Каргалар да безгә каркылдамый...
Без мәңгелек инде бу җирдә.
Бер туйганчы күккә карыйк әле,
Ике кулны куеп бөергә.
Кайгыларны салыйк гөрләвеккә,
Тургай итеп чөйик шатлыкны!
Яз хәбәрен ишетеп, барча кошлар
Безнең якка таба ашыкты.
Такса таксын дошман төрле исем...
Бар табигать безне үз итә...
Безне сагынып кошлар килә бүген,
Күңелләрдә бүген боз китә.

***

Көзгеләрне, тәрәзләрне ваттым...
Өзгәләнмә юкка, эзләмә.
Хәзер инде, шәүләң күрер өчен,
Карарсың син минем күзләргә.
Күршеләрдән качтым, кешеләрдән...
Йөрәк һаман башны өйрәтә.
Дуслар да юк, дошман да юк хәзер...
Кереп адаш минем йөрәккә.
Кырыслыгың, горурлыгың оныт,
Миндәй бул, дип, күңел ялвара.
Яна-яна тәмуг булдым инде,
Йолдыз да юк күктә санарга.
Син кайдадыр читтә, бик еракта,
«Сөям» сүзе сиңа сүз генә.
Сүзләреңнең кайтавазы калды,
Тик исемең калды үземә.

## КАЗАН ПОЕЗДЫ

Мәскәүдәге татар зиратыннан чыккач,
Казан вокзалына килеп,
мин һәрвакыт поезд көтәм, —
Казан поездын.
Шпаллар хыянәтен
бары тәгәрмәчләр белә торган,
тарих китабыдай тигезсез тавышлы,
ике рельслы
поезд көтәм, —
Казан поездын.
Вокзал өстендәге
«Мәскәү» дигән язуларны,
Сөембикә манарасы шәүләләрен,
ерактагы азаннарны уйлап,
поезд көтәм, —
Казан поездын.

Тепловозга
«Татарстан» вагоннары урынына
ялгыш
башкаларны тагарлар дип курка-курка,
поезд көтәм, —
Казан поездын.
Килер,
аклы-каралы шлагбаумнарны һуштан
яздыра-яздыра
килер ул поезд!
Мин бүген —
марка ябыштырмыйча
почта әрҗәсенә ташланган хат кебек.
Үзем һаман поезд көтәм, —
Казан поездын...

## КАЗАН БЕЛӘН САУБУЛЛАШУ

Казанның җәе шәп иде,
Шәп иде бураннары.
Казанда көз кызгылт иде...
Ә монда никтер... сары.
Казанда сөю бар иде,
Актан иде йортлары.
Нигә үпкәләде Казан? —
Озатырга чыкмады...
Без дала балаларына
Казанда юллар тармы?
Белмим, белмим... Мин Мәскәүнең
Миллионынчы татары...

***

Бу Мәскәүдә көннәр резина күк,
Төннең кайтавазы — чиксезлек.
Чиксезлеккә шикле соравым бар:
«Шигырьләрем минем үксезме?»
Таш урамда үскән карт юкәләр,
Мин ышанам бары тик сезгә.
Бу шәһәрдә синең җырың бар, дип,
Әйтегезче миңа — юньсезгә.
Ә юкәләр дәшми, дәшә алмый...
Алар йөрәгендә — үксезлек.
Үксез юкәләрне җырлап килсәм,
Аңларсыңмы, шигъри чиксезлек?

## ӘНКӘЙГӘ ХАТ

Менә без дә үсеп җиттек, әни...

*Р.Фәйзуллин*

Мне страх не нравится,
Что ты поэт...

*С.Есенин*

Ниләр языйм, әнкәй, ни җибәрим? —
Бар булганым — кара һәм каләм.
Җитмеш тиен юлы шигыремнең...

Шигырьләтә генә җибәрәм.
Үпкәләмим сөйләмәдең диеп,
Уитмен һәм Лорка турында.
Сорый идем: «Әнкәй, Зәй артында
Күк белән җир нигә орына?»
Матурлыкны аңлый белгәнсең син,
Белмәсәң дә якташ Шишкинны...
...Хәлең ничек, билең сызламыймы?
...Безнең монда алты эш көне.
Шәһәр матур, яшәү рәхәт, диеп,
Үткән хатта сине алдадым.
Моңсуланып банан ашап йөри
Балан ашап үскән малаең.
Ә бананнан кабак тәме килә...
Безнең якта кабак мул була;
Сарыкларга кабак алыр өчен
Базга төшкән чакта егылма.
Сарык дигәч... болыннарда ни хәл?
Гыймадимы һаман көтүче?
Көтүчесез калган көтү ничек,
Без дә шулай хәзер җир өчен.
Гүргә түгел илгә китәбез бит...
Елап бардык ләкин юл буе.
Озатып калды кое, синең өчен
Иң кадерле нәрсә шул кое.
Шул коеда синең бар фәлсәфәң:
Без — мәңгелек, дисең, кое күк.
Ә шулай да күз алдында йөзең
Еламсырап тора, боегып.
Тәрәзә артында, сиренага охшап,
Гүлимәле һаман багана?
Тәрәз аша синең күз нурларың
Кояш нуры белән ялгана.
Киттек инде, киттек, теләп киттек,
Монысында беркем кумады.
Кая барсак, ай ияреп барды,
Һәр урманда бүре улады.
Без киткәнгә юллар сөенделәр,
Җирләр гизеп аяк арыды...
Улларыңны саклый алмадың шул...
Үз-үзеңне сакла, ярыймы!
Ниләр языйм тагын, ниләр салыйм?
Бар булганым — кәгазь һәм каләм.
Җитмеш тиен юлы шигыремнең...
Шигырьләтә генә җибәрәм.

## МӘҢГЕЛЕК УТ

Һәйкәл тора мәйдан уртасында,
Мәһабәт тә йөзе, салкын да...
Каршысында яна мәңгелек ут,
Салкын һәйкәл карый ялкынга.
Урамда кыш. Сугыш күптән тынган.
Дөнья тыныч. Тик кул күшегә.
Ут янына җылынырга килә
Бала-чага, олы кешеләр.

Җылынырга килгән чал чәчле карт
Нигә салган әле бүреген?
Бу ялкында таныш чалым күреп,
Дустын уйлый, ахры, ул бүген.
...Медале дә юк иде бит хәтта...
Болай гына... гади бер батыр.
Атакада пуля тигәч аңа:
«Син туктама, — диде, — бара тор...»
Кабереннән күтәрелгәнме ул,
Җимереп чыккан мәллә төрмәне?!
...Һәйкәл булып тәне кайткан илгә,
Мәңгелек ут булып — йөрәге.

## САМОЛЕТТА

Самолетта очам, самолетта...
Аста калды Мәскәү, Касыймнар.
Монда инде мәңге болыт булмый! —
Аермачык монда гасырлар.
Рәхәтият иле шушы мәллә? —
Шушы мәллә минем өлешем?
Бөтен нәрсә монда күктәгечә:
Хәтта кызлар кәнфит өләшә.
Җирнең генә түгел, кояшның да
Буйсынам мин тарту көченә...
Бабам хыялланган күккә мендем!
Нәрсә кирәк тагын кешегә?!
Гасырлар һәм чорлар кысылдылар,
Тарих сыйды сәгать эченә...
Сәгать нәрсә? — Аяз күктә вакыт
Чакырымнар белән үлчәнә.
Самолетта очам, самолетта —
Мин дә менә күккә мендем бит!
Ут кабызган аэропортлар кебек,
Бар йолдызлар тора тезелеп.

## КӨЗ

Аягүрә йортлар елап тора...
Кызганалар бугай дөньяны.
Көз китергән сары күлмәк киде
Җир шарының менә бу ягы.
Саубуллашмый-нитми кошлар китте,
Кошлар китте кояш артыннан.
Кошлар халкын уйлап басып тордым,
Чапкан чакта төшеп атымнан.
Җир нарасый, сабый бала кебек,
Юынды да һаман юынды.
Чистармады ләкин пычрагыннан...
...Мин югалттым бугай юлымны.
Мине ташлап аргамагым качты,
Чабып китте дала ягына...
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ияренә менгермәсә дөнья,
Асылынып барыйк ялына!
Кабат кайтмас яфракларын сагынып,

Бар агачлар ятып елады.
Агачларга кушылып мин еладым,
Сагындым да үткән елларны.
Урамнарда йөрдем дәрвиш кебек...
Ай урамда йөзә, ай арган.
Боз астында катып калыр кебек...
Айны кудым пычрак сулардан.
Кышны уйлап моңсуланып йөрдем,
Каурыйларын койган казлардай.
Бар өметем минем кышта инде...
Кыш артында чөнки язлар бар.

## ЯШЬЛЕК

Якорьларын онытып юлга чыккан
бу корабта бары бер теләк:
соры ярлар алда күренгәнчә,
бер исемсез давыл килеп
адаштырсын иде тизрәк.

***

*Мәскәү янындагы куе урман эчендә шагыйрь Лермонтов яшәгән йорт бар.*

Мин Лермонтов йөзгән күлдә йөздем,
Ул сокланган гөлгә сокландым,
Ул йөрегән урманнарда йөрдем,
Аның аланында йокладым.
Мылтык атып кошлар каршылыйлар,
Кошлар озаталар бу илдә.
Шагыйрьләр һәм кошлар бертугандыр —
Чын шагыйрьләр үлә дуэльдә.
Шул күпергә басып озатып калдым
Кавказына очкан казларын.
Лермонтовны кабатладым бүген...
Тик ул язган җырны язмадым.

## ДИСБЕ

*Орчык тартып әби җеп эрләде,*
*Эрли-эрли җырын җырлады:*
*«Йон бәйләгән кабам кояш кебек,*
*Орчык җебем — кояш нурлары»...*

Әби, әби, синең истәлекне
Ничек кенә инде яңартыйм?!
Кулларымда синең серле дисбең,
Күз алдымда җылы мич артың...
Минем әткәй — синең шахтер улың,
Зур Исмәгыйль аның исеме, —
Күчтәнәчкә җимеш алып кайткан,
Төшләреннән җыйган дисбеңне.
Шул дисбеңне тартып ялваргансың,
Нык булсын, дип, шахта терәве.
Теләкләрең кабул булган синең...
Әле дә тибә эткәм йөрәге.
Сугыш килгән. Шул дисбеңне тартып,
Син озатып аны калгансың,

Күз яшенә манма сүзләреңне
Ишеткән тик яшел намазлык.
Әткәй хәзер телевизор карый,
Алланы ул бераз оныткан.
Тик шулай да сине онытмаган,
Кабереңә каен утырткан.
Күз яшьләрең сеңгән намазлыкны
Яшереп куйган сандык төбенә.
Искә төшкән саен алып карый,
...Ул кадәр үк «көфер» түгел лә.
Кулларыма серле дисбең тотып,
Мич артында уйлап утырам...
Мич елый да елый, әллә инде
Эченә кайгы кереп утырган.
Минем хәзер, әби, үз иманым,
Минем, әби, хәзер үз Аллам...
Тик шулай да, кайгы килгән чакта,
Кулга дисбең алып уйланам.
Йорт салыгыз, уллар үстерегез,
Бәхет керсен, дидең, өйләргә...
Насыйп булсын, дидең, туган җирдә
Буразнага ятып үләргә.
Иген чәчмим, әби, ачуланма,
Бер «җилкуар» шунда, җыр язам.
Ә җыр язу шулкадәрле авыр,
Җибәрми ул, алса бугаздан.
Дисбең исән... Күрсәң иде, әби,
Дөнья хәзер ничек үзгәргән...
Ә мин һаман тугрылыклы сиңа:
Дисбе тезәм, әби, сүзләрдән.

***

Мин яу булып түгел, яучы булып
Бусагаңа бастым, Европа.
Дөньябызда әле хаксызлык күп —
Берәү елый, берәү елата.
Без күтәргән йөкне кем җиңел, ди!
Кем кайгыны безнең аз дия?!
Азияне Европага димлим,
Европаны сиңа, Азия.

## ҮПКӘ

Тулы аем бар иде,
Яртысын кемдер урлады.
Тулы аем бар иде.
Ярты аем бар иде,
Аны кемдер урлады.
Ярты аем бар иде.
Кара күктән айны эзләп
Инде күзем арыды.
Тулы аем бар иде,
Ярты аем бар иде.
Ябык күңелем арыгы.

***

Сәгатенә ничә шигырь туа...
Бер көн җитәр,
язалмассың, тема бетәр, дисеңме,
Дөнья бетеп,
тик берүзем калсам да,
берне түгел,
бер мең тема табармын.
Һич югында:
«Дөнья бетте,
шигырь яши!» —
диеп язармын.

*

## ШАГЫЙРЬ

*Ш.Бодлерга*

Сабый чакта урындыктан егылды.
Көне буе әнисен көтеп,
еламыйча,
уч төбендә бер тамчы кан саклап йөрде.
Аңламадылар.
Малай булгач,
беренче тапкыр
йолдыз атылганын күрде.
Кешелеккә яңалык сөйләр өчен,
йокламыйча,
төне буе таңны көтеп ятты.
Тыңламадылар.
Урам тутырып җырлылар да,
җырсызлар да җырлап үтте.
Күз яшенә малайлыгын кушып,
ул җыр язды.
Җырламадылар.
Кайгыларның
ак төстә дә, зәңгәр төстә дә
булуына инанып янды.
Еллардан ул бәхет үтенмәде,
тик ашыкмауларын сорады.
Еллар көлде, юллар көлде. Кешеләр белде.
Еллар соңламадылар.
Менә бүген
барысы үтте, барысы бетте.
Кешеләр аны әрнеп тыңладылар...
Аңладылар... Соңладылар...
Каберенә башларын орып,
җырын җырладылар.

*

***

Юмарт булыйк әйдә,
Чын күңелдән
Бөреләргә чәчәк дип дәшик.

Син куанмый бүген кем куансын.
Туган көнең җиткән бит, яшьлек.
Кояш әле яңа баш өстендә...
Кич җиткәнче җырлыйк, гөрләшик.
Син дуламый бүген кем дуласын,
Туган көнең җырлы бит, яшьлек.
Идел әле яңа ташыган чак...
Болыннарга бәхет өләшик.
Син моңаймый бүген кем моңайсын,
Туган көнең җиткән бит, яшьлек.
Табигатьнең әле юләр чагы...
Юләр чакның серен сөйләшик.
Син җырламый бүген кем җырласын,
Туган көнең җырлы бит, яшьлек.

*

## КӨТҮ

Әнисеннән ул елмаю көтте,
Әтисеннән — киңәш,
Дошманнардан иң көчлесен көтте,
Дусларыннан — тиңдәш.
Болыт килсә, ул кояшны көтте.
Аяз булса — болыт.
Юкәләрдән һаман алма көтте,
Тупыллардан — шомырт.
Шагыйрьләрдән акыллы сүз көтте,
Музыканттан — зур хис.
Кешеләр аннан көлеп сөйләделәр:
«Ул көтәргә хирыс...»
Ә хатыны тап-тар бүлмәсендә
Көтте кара малай.
Язмыш көтте, җилдән бишек асып
Кәкре карамага.

*

## АВЫЛДА ТУЙ

Киереп ач урыс капкаларны!
Керсен кунак безнең өйгә дә!
Авылда туй. Тракторчы егет
Сыер савучыга өйләнә.
Урамнар тар бүген егетләргә,
Җыр агыла басу ягына.
Бии бабай. «Кеше көлдермә» дип,
Еламсырап әби ялына.
Коеларның суы эчелеп беткән,
Колхоз аты баткан күбеккә,
Иске җырлар яңа булып яңгырый, —
Тургай кунганмыни күреккә!
Авылда туй. Гап-гади бер егет
Гап-гади бер кызга өйләнә.
Машиналар тынып калган бүген...
Атлар чаба, чаба... әл-лә-лә!
Калым да бар, бирнә дә бар туйда...
Нинди искелек бу? — димә лә.
Егет батырлыгы калым булса,
Кызның мәхәббәте — бирнәгә.

Чаба-чаба тезгеннәрне өздек,
Тик һаман да җырлар өзелми!
Гасырлардан күчә-күчә килгән
Кыңгыраулар ярсып зеңгелди.
Урамнарны иңләп шатлык килә,
Дус сөенә, дошман көенә.
Каерып ач урыс капкаларны! —
Керсен бәйрәм татар өенә.

*

## ЭПИТАФИЯ

Аның гомере шатлыклардан — кайгы,
Кайгылардан шатлык эзләп үтте.
Бар төшләрен гел начарга юрап,
Өзә иде безнең үзәкне.
Менә бүген бар нәрсәсен биреп,
Берни алмый бу дөньядан китте.
Кабере өстендәге ябь-яшь каен
Аңлый алмас инде бәхетне.

*

## ШИГЫРЬ ЯЗДЫ АБЗАГЫЗ

Шигырь яздым
мактап яхшы колхозны.
Тәнкыйтьчеләр тик бер карап бактылар,
«лаклаучы» дип, «матур» исем тактылар.
Шигырь яздым
сүгеп начар колхозны.
Тәнкыйтьчеләр күз аттылар,
«каралтучы» исемен тактылар.
— Тормыш бит ул ала-кола, — диделәр, —
күрим дисәң, яхшы күзлек ки, — диләр.
Хәзер инде өйрәндем:
Шигырь язам алар кушканча...
Бик начар бер колхоз алам,
башлыкларга күпме кирәк кара ягам:
ашламалар чыгарттырмыйм,
басуларны тырматтырмыйм,
яңгырларны яудырттырмыйм,
сыерларны саудырттырмыйм,
фермаларны җимерттерәм,
атларына коры улак кимерттерәм.
Бер сүз белән — бөтенесен тилмерттерәм.
Һәм шуннан соң
бер бик яхшы председатель
китерттерәм,
ярты елда шул колхозны
бер гасырга сикерттерәм,
Сәләхине, Лотфыйларны
тук тормыштан кикерттерәм.
Иң азактан — җитәкчегә
бик зур бүләк бирдерттерәм.
Тәнкыйтьчеләр,
менә монысын карагыз:
тешегезне сындырырлык
шигырь язды

абзагыз!

## МИЗГЕЛ

Җир шарына утырып тәмәке төрдем,
Җир шарына басып сүндердем.
Җир шарында арлы-бирле атлап йөрдем.
Санап чыктым барлык шатлыкларны,
кайгыларны.
Карап чыктым:
кемнең күзе йомык, кемнең ачык
һәм ни өчен.
Бизмәнләдем күз яшьләрен, таң чыкларын —
барын, барын, барын.
Онытып тордым йолдызларның
тик төннәрен януларын.
Бер мизгелгә
уч төбенә куеп тордым
бу Җир шарын.
Әйе, әйе,
мин бер мизгел
шагыйрь булып алдым.

*

***

Мин — яшьтәше атом бомбасының...
Мин мәңгелек уйда утырам.
Галимнәр, сез бомба ясаганда,
Әниләр бит безне тудырган.
Безгә күптән акыл теше чыкты...
Акыл кердеме соң аларга?
Матдәләрнең җанын суыра-суыра,
Галимнәрнең чәче агара.
Илләр бүләр өчен атом бүлеп,
Сак йокысын бүлеп кешенең,
Бәхеткәме, ләхеткәме икән,
Тарих, безгә юллар түшәдең?
Җәй життисә, шомлы күк күкрәде,
Без яшенгә кушылып яшьнәдек.
Мин — яшьтәше атом бомбасының —
Икәү бергә чакта яшәү юк!

*

## ИСКЕ КӨЙМӘ ЗАРЫ

Тыңладым мин машиналар шавын,
Күрдем кызлар кирпеч өйгәнен.
Әй, беләсе иде ни уйлавын
Яр буенда иске көймәнең.

...Актарылды туфрак, ауды таллар,
Күтәрелде гасыр тузаны.
Моңсуланып карап торды көймә
Горур атлап заман узганын.

Урамнарны иңләп йөрде заман...
Ә заманга урын — гел түрдән.
Кирпечләрдән чәчәк ясый-ясый,
Такыясын ташчы кыз үргән.

Карт көймәнең күңелендә сагыш...
Япа-ялгыз калгач, нишләсен?
Дулкын бәргән саен талпына ул,
Онытадыр, ахры, үз яшен.

«Рәтләсеннәр, төзәтсеннәр иде,
Төясеннәр иде кирпеч, таш.
Мин — төзүче! — диеп әйтер идем,
Син кем? — диеп, дуслар сорагач.

Тирә-юньдә шундый дау барганда,
Кем тик ятар түзеп, кем йоклар...
Көне-төне дулкын яра әнә
Теплоходлар — минем оныклар.

Оныттылар мине, оныттылар...
Урын, диләр, сиңа музейда.
Бу якларны ташлап китә алмам...
Тән тузса да, йөрәк тузмый ла.

Иске яр да калыр минем белән,
Мине аңлый бары ул гына.
Яңа заман, яңа утлар, йортлар,
Яңа ярлар — яңа буынга...»

...Ишеттем мин машиналар шавын,
Күрдем кызлар кирпеч өйгәнен.
Һәм тыңладым моңсу хикәясен
Яр буенда иске көймәнең.

## ИГЕНЧЕЛӘР НӘСЕЛЕ

Җиргә ятып сабан сөргән бабам,
Чалгы селтәп чапкан печәнне.
Аршын түгел, метр, сажин түгел —
Өмет булган җирнең үлчәме.
Гомерендә алтын күрмәгән ул,
Янчык тулы көмеш йөртмәгән.
Алтын төсен күргән игеннәрдә,
Көмеш сулар эчкән чишмәдән.
Ракеталар очмаса да ул чак,
Ай турында җырлар җырлаган.
Ачмаса да серен йолдызларның,
Күккә карап язмыш юраган.
Вакыт җитте безгә, галәм иңләп,
«Карурман»ны җырлап үтәргә...
Тик һаман да туган җирне сөю
Җитеп бетми әле күпләргә.
Нәселемә мин хыянәт итмәм! —
Игенчеләр безнең ыруда.
...Буразналар ярып барсаң иде
Шигърияттнең олы кырында.

*

***

Яшьләрне бит галәм кызыктыра,
Кызыктыра мода, рок-н-рол.
Озакламый салып куярбыз күк
Ай янына кадәр такыр юл.
Бөтен нәрсә җирдә җитешмени! —

Күзләребез күккә төбәлгән.
Ә Җир безгә, ятим бала кебек,
Гаҗәпләнеп карый түбәннән.
Безнең өчен урман — ял урыны,
Алып бара анда машина.
Кайвакытта, гидка ияреп, без
Чыккалыйбыз авыл башына.
Исәплибез бүген көн буена
Ракеталар күпме юл узган,
Булмаганмы давыл Меркурийда,
Атмаганмы вулкан йолдызда...
Без төп-төгәл әйтеп биралабыз
Йолдыз белән йолдыз арасын.
Ачтык әнә музей, күргәзмәләр —
Үткән буын килеп карасын.
...Картлар йөри шәһәр урамында,
Моңсуланып, җиргә сыенып,
Йөри алар, кибет саен кереп,
Ипи муллыгына сөенеп.

*

## БЕР КӨНЕМ

*Бәхет атлы хыял дәүләтенә*
*Бара торгач туры юл салып,*
*Онытылган тормыш кануннары,*
*Онытылган хәтта усаллык.*

Кемнәр дошман, кемнәр дус соң миңа? —
Буталып ла беттем дөньяда...
Чал карт булып, кич йокыга ятам,
Сабый булып, таңда уянам.
Яхшыларын, матурларын гына
Җыеп куям җанга сүзләрнең.
Һәр иртәне зәңгәр күккә баккач,
Зәңгәрләнә тагын күзләрем.
Сәламләгән чакта кешеләрне
Булмасын дип каты кулларым,
Саф чишмәгә барам. Беләм чөнки
Дорфалыкны аның юарын.
Бусагадан сабый бала кебек
Атлап китәм тәүге адымны.
Бөтен дөнья миңа көлеп карый,
Бөтен дөнья шундый ягымлы.
Урман-кырлар тыңлый сүзләремне,
Һәр сүземә минем ышана.
Кешеләр дә көләч, шат күңелле —
Бүленмәгән дуска, дошманга.
Бәхет атлы хыял дәүләтенә
Карап барам, үзем юл салып...
Бар күңелем тулы кояш белән,
Тамчы да юк җанда усаллык.
Аяз күкне кинәт болыт баса...
Мин кычкырам: «Хыял, алдадың!»
Күкләр күкри...
Әйтерсең лә ул мин
Яңагына сугам ялганның.
Егылам да торып алга атлыйм,

Абынам да тагын егылам.
Һәм кемнәрдер, кулларымнан тартып,
Яздырмакчы була юлымнан.
Кемдер мине алга таба әйди:
Кулларына янар ут алган...
Ә кемнәрдер дәшә башка юлга —
Яхшы белән яман буталган.
Кулларымны тартып алам да мин
Үз сукмагым буйлап йөгерәм.
Ябылганда,
Офык капкасына
Көч-хәл белән килеп өлгерәм.
Офык сала алтын бишегенә...
Мин саташам, тирлим, ут янам.
...Чал карт булып кич йокыга талам,
Сабый булып таңда уянам.

*

***

Минем гомер әле башланмаган,
Мин дөньяга әле килмәгән...
Күкрәгемдә — әнкәм биргән йөрәк,
Иңнәремдә — әткәм күлмәге.
Шатлыгым да үземнеке түгел,
Үземнеке түгел кайгым да.
...Абыемның гомере кыска булган —
Бар хисләрен миңа калдырган.
Мин үткәннәр белән яшим әле...
Эзлим җирдә бабам бәхетен.
Ул менмәгән тауга мендем инде,
Ул үтмәгән озын юл үттем.
Үткәннәргә таба йөзне борып,
Күп таптармын әле бу җирне.
...Үземнекен түгел,
Язам әле
Шагыйрь язмый калган шигырьне.

*

**ҺӘЙКӘЛЛӘР**

Күңелләргә сыймый дала моңы,
Җырларга ул ничек сыйсын ди?!
Һәйкәл булып өстән карый шагыйрь,
Булмаса да зурдан буй-сыны.
Без бөек тә, таш һәйкәл дә түгел,
Без бу җирдә гади кешеләр.
Дус-дошманга ачык күңелебез...
Без акыллы һәм без шыр юләр.
Урамнардан җырлап узабыз без,
Юллар безнең арттан иярә...
Ай-йолдызга менеп булмас, ахры...
Безнең язмыш гади иярдә.
Без кешеләр, гади кешеләр без.
Без очрашкан мәлләр — шәп мәлләр!
Ә бөекләр һәйкәл булып калган...
Тик очраша алмый һәйкәлләр.

*

## ИДЕЛ

Ярларына ятып Идел ага,
Казан тора аны озатып.
Акчарлаклар күз яшедәй — елга...
Күбек дулкын — гүя акбүз ат.
Ярга бәрде дулкын Болгарны да,
Гасырларны алды якадан.
Әтил дә ул, Идел дә ул булды,
Волга дип тә инде аталган.
Җир әйләнсен, елга аксын гына! —
Килсен Пугач, йөзсен Разиннар...
Аны мактап җырлар чыгарсыннар,
Яр комына дастан язсыннар.
Бер җәйделәр аны, бер кыстылар...
Ә безгә ул гел зур, гел көчле.
Идел койган диңгез саега бара,
Кешеләрнең хәтере шикелле.
Афәт килсә, аны каргадылар,
Һәм башланды имеш-мимеше...
Югыйсә бит бозлар — кыш бүләге,
Ә дулкыннар — давыл, җил эше.
...Елга да мин. Башка беркем дә юк.
Әйтерсең лә җирдә без генә.
Ярларына кысылып Идел ята,
Кысаланган иске көзгедәй.

*

## АУЧЫ

Дары. Ядрә. Мылтык. Ике көпшә.
Бармак капшый корыч күрекне.
Җәнлек кача. Аучы өзгәләнә,
Ычкындырдым, диеп, бүрекне.
Тагын дары. Тагын ядрә. Мылтык.
Ат, ат тизрәк! Нәрсә көтәсең?
...Аучы күкрәгенә ачу белән
Кире бәрә мылтык түтәсе.
Һәр көн саен шулай, һәр ел саен,
Шулай булган мең ел, гасырлар.
Усалланган кеше. Бар кошларны,
Җәнлекләрне читкә качырган.
...Җәнлек тунын нигә кия кеше?
Лаеклырак үзен саныймы?
Әллә соң бу, үзе дә аңламыйча,
Маймыл бабаларын сагынумы?

*

## БӨЕКЛЕК

Туган чакта — бөтенебез тигез.
Ә үлгәндә? — Белмим ул ягын.
Һәрбер аксак нигә Байрон түгел,
Һәр саңгырау — түгел Бетховен?
Һәр акыллы нигә бөек түгел,
Һәрбер батыр — түгел Газинур?

Һәр авыру Тукай булса әгәр —
Бер минутта мең том язылыр!
Һәр кешедә баш бар, кул, йөрәк бар,
Бөек фикер килә һәркемгә...
Ләкин аны күпләр таный алмый,
Таныганнар кыймый әйтергә.
Фикер җирдә шәрә килеш йөри —
Яңа туган сабый баладай.
«Асрамага бала бирәм», — диеп
Чыгаралар аны базарга.
Каксалар да, суксалар да күп чак...
Бөтен кеше аңа бик якын.
Итекче карт Вәли аңлый аны,
Ишетә аны саңгырау Бетховен.
Ашаталар, сөеп үстерәләр,
Кидерәләр тыйнак киемгә...
Ул дөньяга чыга. Килеп керә
Бәхет булып һәркем өенә.
Намуссызлар өчен намус була,
Өметсезләр өчен — ак өмет.
Җан өләшә җаны үлгәннәргә,
Ул терелтә тик бер кагылып.
Урамнарда йөри ятим фикер,
«Асрамага, — диеп, — кем алыр?»
...Һәрбер сукыр нигә Гомер түгел,
Батыр түгел һәрбер Газинур?!

## БАКЧАСАРАЙ ФОНТАНЫ

Тәүге кат мин бу тауларда,
Туган җирем — ачык сәйран.
Тик тарихка хөрмәт саклап
Килдем сиңа, Бакчасарай.
Биек идең хыялымда:
Күккә ашкан манаралар...
Әллә инде картайгансың,
Биегәйгән әллә таулар.
Каплый мәллә таш кыялар,
Күренмиме сиңа ал таң...
Ә фонтаның һаман елый,
«Күз яшьләре» атлы фонтан.
Күптән тынды сугышлар да,
Заман һаман алга бара...
Шатланырга иде дә бит...
Әллә бармы яшерен яраң?
Кайта алмый калды мәллә
Сөйгән ярлар шул сугыштан? —
Мәңге бергә булырга дип,
Алар монда сүз куешкан.
Кайта алмас инде алар,
Оныт инде, кайгың оныт.
Илләр имин, дөнья тыныч,
Күк йөзендә юк бер болыт.
Күп шатланган, күп сөенгән
Бу дөньяда озак яшәр...
Шатлыкны еш күрмәсәк тә,
Сирәк тама күздән яшьләр.
Бик елыйсы килгән чаклар

Була инде бездә дә ул.
Күңел — диңгез. Җил юкта да
Була анда дулкын, давыл.

Күз яшьләре белән генә
Булмый ләкин җир сугарып.
Без кайгыдан онытылсак,
Таңнар атар бит соңарып.
Кичер, фонтан, ачуланма!
Без төзибез дөнья ямен...
Кайгыбызны күрә калсаң,
Безнең өчен ела, яме?!

*

**ЯҢА «КАРУРМАН»**

Кара да гына урман, караңгы төн,
Юл читендә юк шул маяк та.
Иһаһайлап чапкан кашкаларың
Көчкә басып тора аякта.
Кара да гына урман, караңгы төн,
Бал кортлары чәчәк табалмый.
Чишмә кипкән, агачлары корыган,
Бушап калган инде тау алды.
Кара да гына урман, караңгы төн,
Әй яктыра инде, яктыра...
Бары үлгән, бары сорыланган,
Тик күңелдә генә ак тора.
Кара да гына урман, караңгы төн,
Хатирәләр генә ак тора.
Һәр яз саен сандугачлар килеп
Авылыма мине чакыра.

*

***

Карап торам шәһәр урамына —
Чаба авто. Йөри җәяүле.
Бүлмәм минем — тарих музеедай:
Түбәтәйләр, уклар, җәяләр...
Ә урамда чаба машиналар,
Төтен генә кала ургылып...
Җылы булса, мин күлмәкчән йөрим,
Суык булса, киям тун-толып.
Тәрәз аша урам керә миңа,
Качып керә салкын болыттан.
Ә мин аны, тәгәрмәчтән аерып,
Кочагыма алып җылытам.

*

**УРМАН**

Ил урманы көн-төн шаулый.
Урманда без куак түгел.
Әйдә, түрдән узыйк әле, —
Без бит монда кунак түгел.
Сыйпап узыйк чәчәкләрне —
Алар олы урман яме.

Олысына, кечесенә
Бер үк җылы нур тияме?
Анда берәр сөрхәнтәе
Тимәгәнме кырмыскага?
Кечеләрне кимсетергә
Кайберәүләр, һай, оста ла.
Күрә калсаң андыйларны,
Йөзенә бәр, әйт турысын.
Каеннар да, мин ак диеп,
Алгы рәткә чыкмый торсын.
Тыңлап торма: «Нарат яхшы,
Усак начар», — дигәннәрне.
Һәр агачның үз урыны —
Күккә чөймә имәннәрне.
Урман булгач урын җитәр
Имәнгә дә, үләнгә дә.
Аланнарда пешсен җиләк,
Гөмбә үссен күләгәдә.
Монысы карт, кирәксез дип,
Ташлап китә күрмә тагын,
Ныграк назла андыйларны,
Ә корыса, кис ботагын.
Ил урманы көн-төн шаулый.
Урманда без куак түгел.
Түргә атла хуҗа булып,
Син бит монда кунак түгел.

## ТОРМЫШ САБАНТУЕ

Билне буып, без көрәшкә чыктык
Иң беренче булып мәйданга.
Егылсак та җир күтәрде безне,
Юатырга картлар бар янда.
Яманлыкны күрсәк, Җәлилләрдәй,
Без атылып кердек уртага.
Дөреслекне эзләп дөнья кичтек,
Зарланмадык бер дә юл тарга.
Алда өч юл — әкияттәге кебек...
Бәхетлесен, дидек, кем сайлар?
...Юл өзелде... Сугыш... Яуга китте
Мылтык буе уйчан малайлар.
Тешне кысып, без көрәшкә чыктык,
Беренчеләр булып, мәйданга.
Үтте сугыш, йөрәкләрне таптап,
Күмеп безне яшькә һәм данга.
...Чаба атлар — тормыш сабан туе!
Кемнәр кыю? — Билдән алышыйк!
Малайларның йөрәк түрендәге
Батырлыкны эзләп табышыйк!

*

## ТОРМЫШ АСЫЛЫ

Ни җәй түгел, ни көз түгел җирдә —
Табигатьнең яңа фасылы...
Оныттылар кошлар сайрауларын,
Нидер көтеп җил дә басылды.
Кышкы пристаньдай буп-буш йөрәк.
Сөенеч тә юк, каргыш, ачу да.

Туй төшәсе йорттай... күңелемнең
Капкалары шәрран ачылган.
Җиңел үлем булмый. Качып елый,
Болытларга качып елый җәй...
Көз — җиңүче! Көз тантана итә!
Ике бите ике алмадай.
...Тынычлыгын бүлдерергә куркып
Исеме юк шушы фасылның,
Әкрен генә көзгә кереп барам,
Аңлый барам тормыш асылын.

*

## БЕРЕНЧЕ КАР

Җиргә тагын карлар ява инде,
Җир төренә тагын аклыкка.
Җир яшерә үзенең гөнаһларын,
Җир күмелә сафлык, пакьлеккә.
Нигә миндә кышлар булмый икән?
Күңелемдә нигә көз генә?
Гөнаһларым җирнекеннән күбрәк...
Карый алмыйм хәтта көзгегә.
Кайнарлыгым карлар басар иде,
Охшап калыр идем болытка...
Кешеләр кышка керә. Ә мин янам
Көз калдырган моңсу бу утта.
Ап-ак карлар гүя шәфкать кызы,
Ап-ак карлар җирне дәвалый...
Ә мин янам, ә мин һаман янам,
Мин әйтерсең көзнең дәвамы.

*

## КОЯШ КӨЛӘ

Кояш
Алтын тешләрен күрсәтеп
Көлә...
Карт бөркетләр
Таулар җырын җырлый,
Җырлап калыйм, дия.
Кояш көлә.
Капка астыннан башын тыгып,
Көчек өрә —
Тавыш сыный.
Кояш көлә.
Акчарлаклар,
Шаулы диңгез сорап,
Көне-төне елый —
Тавыш сыный...
Кояш көлә.
Сандугачлар, көне-төне сайрап,
Гөлҗимешләр сорый,
Тавыш сыный.
Кояш көлә.
Колагыңны җиргә карат!
Кояш көлә, димә.

*

## БӘХЕТ

Кыя ташка менеп шигырь яздым —
Бу шигырем бәхет турында.
Хозурланып тауда басып торам,
Болытларга башым орына.
Шундый якын миңа бар кешеләр,
Туган ягым кебек киң җиһан.
Ташлап киткән ярым кире кайтты —
Кулларына алсу гөл җыйган.
Иңнәренә шатлык йөге төяп,
Сизелми дә үтә ай, еллар...
Үзәннәрдә илләр сугышмыйлар —
Сугыш-сугыш уйный малайлар.
Уенчыклар тезеп шук малайлар
Мәйданнарда ясый парадлар...
Диңгезләре — язгы ташу суы,
Бата анда кәгазь кораблар.
Кичләр җитсә, кулга-кул тотышып,
Әйлән-бәйлән уйный дәүләтләр...
Бар кешеләр шундый киң күңелле,
Бар кешеләр шундый әйбәтләр.
Хозурланып тауда басып торам —
Болытларга башым орына.
Кыяларга менми аңламассың —
Бу шигырем бәхет турында.

*

***

Кабул булмый нигә бар теләгем? —
Бу дөньяда мин дә кеше бит.
Янып яшим дөнья суык чакта,
Дөнья җылы чакта — күшегеп.
Юлга чыксам, юрый-юрый барам,
Аяз торсын, диеп, гел көннәр.
Тик уемнан кире кайтаралар
Яңгыр көткән хәлсез игеннәр.
Кайнар җилләр исә, ә мин түзәм,
Басса да тир бөтен җилкәмне...
Беләм, чөнки диңгезләрдә шулчак
Бәхетледер кораб җилкәне.
Якты көннең тартам чабуыннан:
«Төннән куркам, китмә, ашыкма!»
Бу уйдан да кире кайтам тагын —
Сөенсеннәр әйдә гашыйклар.
Ачу килә кайчак тулган айга,
Йолдызларга, хәтта кояшка...
Ник минемчә түгел бер нәрсә дә?! —
Шулай килә туа-тумыштан.
...Үземнеке тора онытылып:
Дус кайгысын бүләм иң элек —
Яшим шулай, кеше шатлыгына,
Кеше бәхетенә сөенеп.

*

***

Туктатып булмый ла вакытны:
Яз үтә, җәй үтә, көз үтә.
Мең кабат ялгыша табигать,
Мең кабат ялгышын төзәтә.
Язларын ялгыша сөюдә,
Шуңадыр җәй буе көенә.
Көзләрен, тук җимеш өлгергәч,
Кызарып, алланып сөенә.
Кыш килеп чәченә чал саргач,
Моңаеп сагышлы җыр суза:
«Нигә мин бу кадәр ашыктым,
Гомерләр, ай-һай, дип, тиз уза».
Туктатып булмый ла вакытны:
Табигать яңадан уяна.
...Кичләрен офыкта алланып
Үткәнгә хатирә-моң яна.

*

## ДИҢГЕЗ ДУЛКЫНЫ

Тын торган ярларын калдырып,
Юл тотты диңгезгә дулкыннар.
Аларны сагынып, ярларның
Йөрәге бик озак сулкылдар.
Шундый зур, шундый киң һәм иркен,
Куәтле һәм назлы ул диңгез.
Теләсәң, тын гына күккә бак,
Теләсәң, талганчы йөз дә йөз.
Ияртте аларны үзенә
Диңгезнең ягымлы агымы...
Тик бераз баргач та, иңнәргә
Усал җил куллары кагылды.
Калтырап, сискәнеп куйдылар
Дорфалык күрмәгән дулкыннар...
Әйттеләр: «Без — диңгез баласы,
Тияргә нинди, дип, хакың бар?»
Ә җилләр шаркылдап көлделәр,
Ачынып кычкырды акчарлак.
Аңлады дулкыннар бик тиздән:
Җилләргә иярми юк чара.
Ә җилләр әйләнде давылга...
Диңгездә тоз исе, яшь исе.
Кабатлый туктаусыз дулкыннар:
«Бик килә яш-ши-се, яш-ши-се!»
Яр калган тарафка күз атып,
Борылды кирегә дулкыннар.
Ярларны тапканчы йөрәкләр
Шашынып, авыртып сулкылдар.
Җил белән көрәшеп талдылар,
Күзләрдән тамчылар чәчрәде...
Кайттылар дулкыннар тын ярга...
...Агарган, чаларган чәчләре.

## МИНЕМ ДОШМАНЫМ

Төн үткәнче күңлем бакчасының
Шиңә калса бары бер гөле —
Таң атуга, минем дошманыма
Бу турыда инде билгеле.

Әллә кайдан читтән күреп тора,
Барган чакта юлда адашсам.
Тик күрми ул, аяз төндә әгәр
Йолдызларга кадәр мин ашсам.
Кешеләргә әйтер, кайгылы, дип,
Сөенечтән әгәр еласам.
Тик кул сузмас, дулкыннарга чумып
Кичкән чакта кайгы елгасын.
Ул һәрвакыт көләч, шаян булыр,
Ачуланмас һич тә, каргамас.
Итагатьле, тыйнак сүзләр сөйләр,
Тик күземә туры карамас.
...Дошманыма карап юлга салам,
Үзгәртәм мин тормыш агышын.
Ул булмаса, каян белер идем:
Кайсы дөрес, кайсы ялгышым.

*

## ИҢ БЕРЕНЧЕ ТИРӘК

Эшлә, дисең. Кулларыма минем
Тоттырасың көрәк.
Эш — мәңгелек, эш ул тамак ялы.
Миңа бәхет кирәк.
Чокыр казы. Менә шушы төшкә
Утырт, дисең, тирәк.
Утырттым ди. Үсә бирсен әйдә...
Миңа бәхет кирәк.
— Төбен йомшарт, яраларын бәйлә,
Суын сипмә сирәк.
— Барысын да эшлим. Тик барыбер
Миңа бәхет кирәк.
Үскән инде. Калдыр тирәгеңне.
Ары киттек тизрәк.
Үстер, дисең, бакча. Тик барыбер
Миңа бәхет кирәк.
Хәзер инде шушы һөнәреңне
Башкаларга өйрәт.
Барысын да эшлим. Тик барыбер
Миңа бәхет кирәк.
...Эш күрсәтеп, кулларына бирдем
Балта, пычкы, көрәк.
Кабатлады алар, миңа кушылып:
«Безгә бәхет кирәк».
Сорадылар аннан: «Бәхет ни?» — дип,
Ярсып типте йөрәк...
Сүз тапмадым. Искә төште шулчак
Иң беренче тирәк.

*

## ДЕКАБРЬ

*Яшьли вафат булган дустым*
*бурят шагыйре Н.Нимбуевка*

Кайгыларның кара төсен күрдем,
Әй күрәсе иде бер кадер!..
Өләшенеп бетте көз алтыны...
Күңелләргә керде декабрь.

Җәйләр, көзләр күргән бу күңелем
Бик сусаган икән ак төскә.
Кыш салкыны баса кайнарлыгым,
Күңелләрдә ап-ак җил исә.
Ап-ак уйлар, ак хыяллар килә,
Туй күлмәге керә төшемә...
Ап-ак кышның салкын мәгънәсенә
Кемнәр генә икән төшенә?
Ап-ак карлар күмде кайгыларым...
Кар астында калды ул кабер...
Салкын да мин, ап-ак та мин бүген...
Күңелемә керде декабрь.

*

***

Шәһәр өстендә ак болыт
Тоела мендәр булып.
Баш өстендә йолдызлы күк —
Чигүле, чуклы толып.
Шәһәр үзе олы базар —
Сата һәм ала сатып.
Арыдым. Бер йоклар идем,
Болыт мендәргә ятып.

*

**ДИҢГЕЗДӘ ЯВА ЯҢГЫР**

Искә төшә әллә ниләр...
Сагышлар бигрәк авыр.
Инде менә ничәнче көн
Диңгездә ява яңгыр.
Чүлләрнең кипкән ирене,
Сөяк булган саксаул.
Оеп утыра барханнар —
Диңгездә ява яңгыр.
Саргайган йөзе болынның,
Иелгән бодай башы.
Күзе күктә игенченең,
Моңсу аның карашы.
Тын калган басу юллары,
Юк бер юлчы узганы.
Бер көндә куна тарихның
Бер гасырлык тузаны.
Искереп бетте кояш та,
Уңды күкнең буявы.
Күңел төбенә күмелгән
Бар сагышлар уянды.
Каралды күптән инеш тә —
Елганың зәңгәр җиңе...
Диңгезгә барып егылды
Даланың кайнар җиле.
Кунды йөзгә җыерчыклар —
Җир-анага, һай, авыр.
Әлсери кырда игеннәр...
Диңгездә... ява яңгыр.

*

## ӨМЕТ

Больницаның ап-ак стенасы
Ничәнче кат керде төшемә.
...Кем ул анда кара пәрдәләрне
Күтәрә дә тагын төшерә?
Яктыра да тәрәз тагын сүнә...
(Ник сүнәсең? Сүнмә, гел яшә!)
Ә больница шушы тәрәз аша
Җиһан белән гүя сөйләшә.
Янәшәдә генә Идел ага,
Болыт йөзә күктә агарып.
Бер кайгысыз кошлар агачларда
Уйный әле һаман шаярып.
Яр буеннан парлар үтеп бара,
Бала-чага таган атына.
Больницага хәбәр җибәргәндәй,
Төпсез күктә йолдыз атыла.
...Ә палата ап-ак... чиста, тынлык...
Оҗмахы да шундый булмасын...
«Сәгатең бор. Туктамасын, кызым...
Ә аннан соң... дару юлларсың...»
...Больницаның ап-ак стенасы
Бүген тагын керде төшемә.
Кем ул анда кара пәрдәләрне
Күтәрә дә тагын төшерә?!

*

## САБАНТУЙ

Байрак булып күккә күтәрелгән
Сабантуйның чуар сөлгесе.
Ат уйнатып йөри чабышчылар,
Мәзәк сөйли шаян теллесе.
Аксакаллар әнә горур атлап
Узып бара мәйдан түренә.
Ә малайлар, иң беренче тапкыр
Көчне  сынап, билгә үрелә.
Авызларга кашык кабып кына
Су ташыйлар авыл кызлары;
Берәүләрнең күзе юл башында —
«Алмачуар быел узармы?!»
Яулык белән күзне бәйләсәң дә,
Чәлпәрәмә килә чүлмәкләр.
Көрәшченең биле кысылганда,
Кысылалар бергә йөрәкләр.
Кызлар гына түгел, табигать тә
Аллы-гөлле яңа киемнән...
Якты күзен олы итеп ачып,
Хәтта кояш җиргә иелгән...
Яшел чирәм яшел ястык кебек,
Хозурланып, җирдә ятарлык.
...Тәүге шатлык килә сабантуйда
Һәм кылына тәүге батырлык.

*

***

Онытылды инде күз яшьләре,
Онытылды антлар, вәгъдәләр...
Тик... йөрәкнең почмагына поскан
Намус кына нидер дәгъвалар.
Акты сагыш күз яшьләре белән
Бушатты ул тулган күңелне.
Күңел ачык... Кем беренче керә? —
Кем керсә дә барыбер түгелме?
Керде күпләр күңел түренә үк,
Исән-саулык сорап тормады...
Сәерсенеп тәрәзәдән карый
Гаҗәпләнгән шәһәр урамы.
Күлмәкләрен салды яшь каеннар,
Йөрәкләрен сузды миләшләр...
Төн аларны кочагына алды...
Ал миләштән тамды ал яшьләр.
Таң атуга кипте күз яшьләре...
Онытылды антлар, вәгъдәләр.
Буш күңелләр тулар шатлык белән,
Намус кына нидер дәгъвалар...

*

## ЯЗГЫ ШИГЫРЬ

Ак каеннар арасына кереп,
Гел аклыкка чумып югалдың.
Ак каеннар янып көнләделәр,
Күреп күлдә чәчең юганың.
Мин көнләдем сине сөйгән өчен
Тып-тын торган күлнең суыннан.
Күктә — Кояш. Тик нигәдер синең
Күзләреңнең нуры суынган.
Иманнәргә карап телсез калдың,
Төз наратны алдың кочакка...
Бер мизгелгә шашып карап тордың
Ялкынланып янган учакка.
Урман кочагына кереп чумдың...
Сүз әйтергә хәтта базмадым.
Сине миңа көз китергән иде,
Алып китәр, ахры, язлары.

*

## СИНЕ ОЗАТКАНДА

Сагынуым басылмады әле,
Ачылмады синең йөрәгең;
Күзләреңнән яшь тә кипмәгән бит,
Елмаюың әле күрмәдем.
...Билет юктыр бүген самолетка,
Буш урыннар юктыр поездга,
Трамвайлар тулы халык белән,
...Җил дә әнә моңлы җыр суза.
Адашырсың... күктә йолдызлар юк,
Юл тапмассың... төн бик караңгы.
Тутырыр күк Айсыз, йолдызсыз төн
Синең белән минем араны.

Көз сагышы миңа күчә, дисең...
Телисеңме? — Хәзер яз ясыйм!
Чәчәк белән күмәм йөрәгеңне —
Мәхәббәтнең алсу вазасын.
Кирәк түгел чәчәкләрең, дисең,
Кирәк түгел сүзең: «Яз ясыйм».
Калсам — бары мине табарсың син,
Китсәм — сагынып шигырь язарсың...
Ничек итеп җырлар языйм ди мин? —
Ачалмадым синең йөрәгең...
Күзләреңнән яшь тә кипмәгән бит,
Елмаюың әле күрмәдем.

*

## РЕЛЬСЛАР

Поездларны юлга күп озаттым,
Тик берсен дә каршы алмадым...
Шул поездлар белән киткән инде
Сөюемнең чыны-ялганы.
Син дә киттең, кояш чыгып калды,
Китеп бардың офык ягына.
Мин әйтерсең синең поездыңның
Тагылмыйча калган вагоны.
Хат язгансың: «Син күрмәгән гөлләр,
Син белмәгән йолдыз бар бездә.
Йөрәгемдә яңа утрау таптым,
Кил, — дигәнсең, — булчы Робинзон».
Сагышларым төяп юлга чыктым,
Шатлыкларың белән каршыла.
...Үз хатасын төзәтергә теләп,
Поезд бүген шундый ашыга.
Шпалларның кайгыларын эчеп,
Юл буенда сары гөл үсә.
Алга карыйм, алда матур ялган —
Кушылалар кебек рельслар.

*

## ЧАКЫРМА

Чакырма туган ягыңа,
Чакырма, диңгез кызы.
Өметтәй олы ул диңгез,
Күз яше кебек тозлы.
Диңгезне мин аңлый алмам,
Минем хыял башкада.
Тик нигәдер бар елгалар
Ага диңгезгә таба.
Чакырма туган ягыңа,
Чакырма, диңгез кызы.
...Сезнең яктан килгән болыт
Күкне күкрәтеп узды.
Күкрәгемне ачып тордым
Саф диңгез һавасына,
Яңгыр түгел, синең сагыш
Болыттан тама сыман.
Чакырма туган ягыңа,
Чакырма, диңгез кызы.

Җибәрми туган ягымның
Давылы, кары, бозы.
Җир кызы ярата мине...
Күзләре диңгез төсле.
Дулкынланган толымнары
Әйтерсең диңгез өсте.
Кайгы кебек олы диңгез
Күз яше кебек тозлы...
Сагышларым болай да күп,
Чакырма, диңгез кызы.

*

***

Бүген тагын мине ташлап киттең...
Төне буе сине эзләдем.
Таңга кадәр мөлдерәшеп торды
Бар йолдызлар — синең күзләрең.
Синең күзләрең күк бар йолдызлар,
Синең гәүдәң кебек ак таллар,
Син киткән юл кебек Айның юлы...
Мин адашам, батам, буталам.
Йолдызларга үреләм — буем җитми,
Кочагыма керми таллар да...
«Ул кайда?» — дип, гөлләр сорасалар,
Мин ни диеп әйтим аларга?..
Син кайт инде. Йолдызларны кызган...
Алар кабат йолдыз булсыннар.
Кояш чыгып килә... Кояш юлы
Син кайтачак алтын юл сыман.

*

***

**1**

Бертуктаусыз уйный, шаярасың...
Шатлыгыңны кемнәр уяткан?!
Син бит башка. Син бит уйчан идең,
...Бу җылы җил исә төньяктан.

**2**

Кара кайгы баскан бүген сине,
Йөри идең элек гел актан.
Син бит башка. Син бит көләч идең.
...Бу салкын җил исә көньяктан.

*

## ӘКИЯТ

Фирүзәдәй зәңгәр күк астында
Икәү калдык. Башка беркем юк.
Рәхәт монда. Юк гайбәтләр, сүзләр...
Дөнья тора оеп, онытылып.
Әллә кая качкан аек акыл,
Ваклык качкан, качкан явызлык.
Ел елгасы акмый, тып-тын тора...
Сират күперләрен тиз уздык.
Көмеш сарай кебек айлы төннәр...

...Әкият тәмам. Алда — ялгызлык.

*

## РӘСЕМ

Әйдә рәсем ясыйм әле —
Булсын бер кызык.
Томаны ак кәгазь булыр,
Яңгыры — сызык.
Аннары сине ясармын:
Яңгыр астында —
Минем янга ашыгасың
Ак томан аша.
Күз ясармын, зәңгәр буяу
Табалсам әгәр —
Чөнки синең күзләрең бит
Сагыштай зәңгәр.
Тын калырмын, күзләреңдә
Күренгәч яшьләр.
Шул чагында йөрәгемдә
Яшеннәр яшьнәр.

*

## КАБАТЛАНА ЯЗЛАР

Гел кабатлап йөрим йөрәгемә:
«Утың, — диеп, — сүнгән».
Тик шулай да үзем читләп йөрим,
Качып йөрим синнән.

Сынап карыйм инде ничәнче кат
Ихтыярым көчен.
Диңгезләргә барып егылдым мин,
Онытылыр өчен.

Кирәк түгел сөю сүзләре дә,
Кирәк түгел назың.
Гел кайтмаска диеп киткән инде,
Үткән инде язым.

Ә хыяллар хыял гына алар,
Матур сүзләр — ялган.
Мин дөньяда беркемгә дә, ахры,
Бәхет бирә алмам.

Чәчәк төсен инде онытып барам...
Өстәлемдә — җикән.
Бу карсыз кыш минем кышым булыр —
Кара кышлар җиткән.

Тик йөрәгем разый түгел бер дә,
Миннән — иясеннән.
Нигә диеп читләп йөрим, имеш,
Качып йөрим синнән.

Нишләргә соң? Көзнең бар сагышы
Минем җанга иңде.

Күңелемә хәзер пакьлек кирәк —
Мин бит кышта инде.

...Көтмәгәндә үзең очрадың син —
Тиле йөрәк хаклы!
Сүзләремне кире алам инде —
Мин йөрәгем яклы!

Тышауланган хисләр — ирек сезгә!
Йөрәк азса, — азар...
Юккамыни һәр ел саен җирдә
Кабатлана язлар.

*

**ГАЕПЛЕ**

Барысына гаепледер, ахры,
Чал Иделнең яшел нараты.
Сине күрми узып китә идем,
Ул үзенә мине каратты.
Гаепледер, бәлки, кара төндә
Юл күрсәтеп торган якты Ай.
Сукмак булып ул алдыма ятты,
Колагыма дәште: «Якынай!»
Гаепледер аннан яр буеның
Кочагыңдай җылы ал комы;
Гаепледер тагын яңгыр, давыл,
Болыт, яшен, елга дулкыны.
Гаепледер, бәлки, урман җиле...
Көнләштереп башта ул үпте...
Чыкмас идем Идел ярларына —
Үз йөрәгем, ахры, гаепле.

*

***

Сине эзләп, мин тауларга мендем,
Аннан аштым күккә.
Мин яратмыйм, имеш. Күрче мөнә —
Юкка синең үпкә.
Телисеңме, кара күк йөзендә
Булам янар йолдыз.
Аңладыңмы инде сөюемне,
Күктә дә мин ялгыз.
Наз кирәксә, битләреңне сыйпап,
Җылы җилдәй исәм.
Хат язармын яшен уты белән,
Мин, дип, яшим, исән.
Ышандыңмы инде сүзләремә,
Онытгыңмы үпкәң?
— Ышандым... тик минем күңел инде
Башкаларда күптән.

*

**ТАМАШАЧЫ БУГАЙ...**

Син уйныйсың, һаман шаярасың...

Тик күзләрең моңсу.
Моңсу булгач күзләр, ничек инде
Җанда шатлык тусын?!
Күренмидер соры күзләреңә
Бу дөньяның яме.
Сөйлисең гел үткән гомереңне,
Ә киләчәк — ләм-мим.
Кайгыларың ерак яшергәнсең —
Рухың, ахры, көчле.
Тик тавышың көлгән чагыңда да
Үкси башлар төсле.
Кабызалмыйм сүнгән йолдызларың,
Баш очында юк Ай...
Синең тормышыңда мин бары тик
Тамашачы бугай.

*

***

Син күрмисең, әйе, күрмисең син...
Үзең һаман алга барасың.
Ашыкмачы! Ялгыз үтеп булмый
Кайгы белән Бәхет арасын.
Син сизмисең, әйе, сизмисең син...
Син сизмисең — йолдыз атыла.
Җиргә карап, күрми каласың син,
Син күрмисең — күктә Ай тула.
Син тоймыйсың, әйе, тоймыйсың син —
Көзләр килә, аннан кыш була.
Салкын җилләр әнә ятып елый,
Ятып елый җилләр таш юлга.
Шулай күрми, сизми, тоймый гына
Күңелең соң кая ашыга?!
Йөрәк җилең ятып елар әле...
...Минем йөрәк тиздән таш була.

*

## САУБУЛЛАШУ

Мәхәббәттән өмет өзгән чакта,
Синең белән нигә кавыштым?
Сау бул инде! Шушы кавышуым
Булса иде соңгы ялгышым.
Без барасы юлдан, бәхет эзләп,
Синең белән күпләр үткәннәр...
Сау бул инде! Такыр юлың ташлыйм,
Онытылсын уртак үпкәләр.
Учларымда кысып тотармын мин,
Йөрәк куйса кайчак атлыгып.
Сау бул инде! Гел үзеңә калсын
Үткәннәрнең мизгел-шатлыгы.
Якынайтыр өчен икебезне,
Яңгырлар да юкка койганнар...
Кавыштырмый икән уртак кайгы,
Кирәк икән уртак хыяллар.
Кирәк икән яшерен көенечләр,
Кирәк икән уртак сөенеч.

...Бер мизгелдә башым югалтсам да,
Мәңгелеккә диеп сөйдем ич.
Кешеләргә бәхет биргән сөю
Миңа бирде бары сагышын.
...Сау бул инде, соңгы мәхәббәтем,
Сау бул инде, соңгы ялгышым!

*

## ЧӘЧӘК БӘЙЛӘМЕ

Язмыш мине алга әйдәде дә...
Гомер бирде чәчәк бәйләмедәй.
Яңгырларда калдым, күрдем карны.
Гөлләремне юлга сибеп бардым.
Килеп җиттем инде җир читенә.
Ялгыз бару юлда, һай, читен лә.
Үткәннәргә борылып карадым да...
Чәчәк эзләп кире барам менә.
Кайда соң син, кайда, умырзаям?
Үткән мәллә яшь гомерем зая?
Кайда соң сез, кайда гөләпләрем?
Үтәлгәнме олы теләкләрем?
Бәхетлеме соң мин, әйт, ромашка?!
Хыялларым чынга ашканнармы?
Язмыш мине тагын алга әйди,
Чәчәкләрдән бәйләм бәйли-бәйли.

*

## ЯҢГЫР ИЛЕ

Аяз иде күгем. Ялгыз идем.
Кавыштырды июль яңгыры.
Яшен яшьнәп күкләр күкрәгән кич
Күңелемдә һаман яңгырый.
Мин китмәсен диеп, яуды яңгыр,
Коеп яуды төннәр буена.
Онытылды үткән гөнаһлар да...
Яңгырда бит эзләр җуела.
Күзләр җитте. Хәзер тагын ялгыз
Йөзем куям яңгыр җиленә.
Минем өчен әле син һаман да
Күк күкрәгән яңгыр илендә.
Октябрьдә манма чыланып, мин
Эзләп йөрим июль яңгырын.
Шул яңгырлы төнне йөрәгемә
Җибәргәндер яшен тамырын.

*

## СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫ

Сөембикә моннан ташланган, дип,
Риваятьләр йөри халыкта.
Онытса да тарих күп нәрсәне,
Бардыр кебек монда хаклык та.
Үз тарихын халык үзе ясый,
Бирми халык үзен үлемгә!
Риваятьләренә төреп, саклап
Алып килгән сине бүгенгә.

*

## КАБАН КҮЛЕ

Серләреңне аччы, Кабан күле,
Сөйлә әле бөтен белгәнең,
Яттан сөйлә Тукай шигырьләрен,
Шушы булыр иң зур бүләгең.

Суларың да әнә кибеп бара,
Аерылгансың инде елгадан.
Болагың да соңгы мәлен көтә, —
Яшел кәфененә уранган.

Сөйләп калчы, Кабан, серләреңне...
Йөзгән, диләр, синдә пароход.
Үпкәләмә... сине гаепләмим,
Болай гына сорыйм, яратып.

Ничә еллар инде эндәшмисең,
Бер давыллап, ярсып ал, Кабан!
Урамнарга, мәйданнарга чык бер,
Сәлам тапшыр җиргә Тукайдан.

Шаула, гөрлә Печән базарыдай,
Сөйлә әле бөтен белгәнең:
«Кисекбаш»ны сөйлә, «Шүрәле»не,
Карахмәтнең тимер беләген.

Барысы яңа, барысы кызык безгә:
Күпме алтын синең төбеңдә?
Ничә дистә мәчет манарасы?
Күпме кан-яшь сиңа түгелгән?

Чынын сөйлә... Тукайларның гомере
Нигә алай иртә өзелгән?
Аннан сөйлә ниләр күргәнеңне
Унҗиденче елның көзеннән...

Тирә-юньдә дөнья шундый матур!
Ярларыңа басып карале.
Тукай нәселе киләчәккә бара,
Безнең белән син дә бар әле.

...Эндәшмәде Кабан... Яшел күзе
Өмет катыш моң һәм зар тулы.
«Китмә!» дигән кебек, дулкыннары
Аягыма килеп сарылды.

## ТРАМВАЙДА

Көтмәгәндә яңгыр түккән өчен,
Сүгә-сүгә болыт ертыгын,
Чыланудан качып, трамвайга
Болай гына кереп утырдым.
Трамвайга кыйбла кирәк түгел,
Аңа барыбер, кая барса да...
Рельслардан чыгып булмый ла шул, —
Китәр идек туры Арчага.
Чабар идек Тукай якларына,
Әй тәгәрәр иде «Кисекбаш»...
Бер-беребезне аңлар идек әле, —
Тукай белән без бит гасырдаш.

Кая илтә мине язмыш юлы? —
Тирә-юньдә юк дус, юк таныш...
Авыр сулап, кемдер әйтеп куйды:
«Килеп җиттек. Соңгы тукталыш».

*

## КИЧКЕ КОЯШ

Күзе кызарган Кояшның —
Йокысы килә бугай.
Түшәк җәеп көтә аны
Болында яшел тугай.
Ләкин күкләр улы Кояш
Безнең янга төшәрме?!
Алтыннан аның сарае,
Ак болыттан — түшәге.

*

## БОРЫНГЫ БОЛГАРДА

Болгар җире, Бөек Болгар иле...
Тарихка мин саклыйм зур үпкә.
Бабамнарның мәгърур җаны кебек
Күтәрелә тургай биеккә.
Басу буйлап берәү җырлап килә,
Чал тарихтан килә диярсең.
Барысы да мең ел элеккедәй...
Аргамаклар чаба иярсез.
Барысы да мең ел элеккедәй:
Ай-кояшы, зәңгәр күге дә...
Бөек илдән чүлмәк ватыклары
Бүләк булып калган бүгенгә.
Бөтен нәрсә монда якын миңа,
Әйтерсең мин әнкәм куйнында.
Бөтен нәрсә монда Болгарымның
Оныклары кебек тоела.
Хәрабәләр, ташлар арасында
Башын иеп тора кылганнар...
Бабайларның сүзен сөйләр өчен
Тик кылганнар гына калганнар.
...Болгар иле — бабамнарның иле,
Тургай моңы — минем моңнарым.
Мин тургайны түгел, бүген гүя
Бабамнарның җырын тыңладым.

*

## КАЗАН ВОКЗАЛЫ

Ниләр уйлый Мәскәү бу көннәрдә?
Ниләр уйлый Казан вокзалы?
Хәнҗәр кебек яткан рельсларның
Йөрәгемдә очы, азагы.
Ашкын хисләр ыргый поезд булып,
Әверелә сагыш ярсуга,
Сагынуым ташый урамнарга, —
Минем өчен Мәскәү тар сыман.
Ак кирмәнең һаман акмы, Казан?
Шулай киңме һаман Иделең?

Син бит миңа — туу, сөю, тормыш,
Шатлык, кайгы, яшәү һәм үлем...
Мәскәүдә без — көтеп алган кунак,
Көтеп алган хуҗа — Казанда.
«Без килмешәк түгел бу җирдә...» — дип,
Каным белән әзер язарга.
Мин Мәскәүдә. Һәр көн саен Казан
Каршы алыр өчен юл чыга...
...Офыкларга кадәр сузылган юл —
Кочакларга сузган кул сыман.

*

## САГЫНУ

Таныш ярлар, якын ярлар, туган җир —
Уйна да көл, шатлан, сөен, җырлап йөр.
Качкан күптән моннан дошман яулары.
Шуңа горур, шуңа мәгърур таулары.
Туган җирдә безгә һәрчак кадер бар...
Адым саен монда таныш каберләр.
Үткәннәрдән калган сагыш — истәлек.
Бу сагышлар тормасачы өстәлеп.
Җылырак шул туган якның кояшы.
Монда безнең юл азагы, юл башы.
Чакыра тик ерак чүлләр, себерләр...
Тимер булды эштән безнең сеңерләр.
Җылынды күк хәтта себер кояшы.
Тик туган як — һаман хәтер юлдашы.
Гөлгә күмдек ач даланы, чүлләрне.
Безнең тирдән тозланды ил күлләре.
Җылытсак та салкын себер җилләрен,
Кошлар монда мәңгегә дип килмәде.
Хушлашканда әйтте безгә гел алар:
Көтә, диеп, безне анда оялар.
Дәртләнеп, без тагын эшкә тотындык.
Колак тыңлый ил хәбәрен, йотылып.
Кайтырбыз без, салкын себер гөл булгач...
Сагышыңнан үлә күрмә, сандугач.
Ә хәзергә ташка тамсын кайнар тир...
Түз, егет бул, «Туган як» дип җырлап йөр.

*

# УТЛЫ ХӘТЕР

*(Реквием)*

### 1. КЫРЫК БЕРЕНЧЕ ЕЛ САБАНТУЕ

Соңгы тапкыр кичә көлде дөнья,
Соңгы тапкыр кояш балкыды.
Таң атмады бүген, таң атмады, —
Алды җирне сугыш ялкыны.
Алды ялкын ил һәм дәүләтләрне,
Алды ялкын кыш һәм җәйләрне...
Туган якның данлы сабантуе
Канлы сабантуйга әйләнде.
Томырылды атта яшь егетләр...
Гомер буе көтәр чын ярлар.
Янса янар, әмма Берлингача,

Берлингача атлар чабарлар.
Европада — канлы сабан туе,
Җирдә бүген — ялкын, көл исе.
Җиңү байрагыдай янып калды
Сабантуйның биек сөлгесе.

*

## 2. ХАТЛАР ЯЗАМ

Әнкәем, хат язам:
Ничек соң хәлләрең?
Юрама яманга,
Килмәсә хәбәрем.
Әбкәем, хат язам
Сугышның эченнән.
Әйтерсең тәмугы
Бу җиргә күченгән.
Дусларым, хат язам:
Сез кайсы якларда?
Үлсәк тә, без тиеш
Дуслыкны сакларга.
Сөйгәнем, хат язам
Сугышның үзеннән...
Тик шәүләм сүнмәсен,
Китмәсен күзеңнән.
Әткәем, хат язам:
Юк башым игәнем,
Һәрвакыт хәтердә
«Сынатма!» дигәнең.

*

## 3. СУГЫШ ИКМӘГЕ

Чайкала арышлар, чайкала бодайлар,
Чайкалып куялар хатыннар.
Хәле юк, көче юк, дошманга үче бар,
Ватанга биргән зур анты бар.
Чайкала арышлар, чайкала бодайлар...
Айкала җаннары сагыштан.
Ашыга, каршыда ирләре көткәндәй...
Алар бит шушында табышкан, кавышкан.
Чайкала арышлар, чайкала бодайлар...
Кем әйтер, алар, дип, сугышка китмәде?!
Хатыннар сөюе, сагышы сеңгәнгә
Татлы ул, ачы ул сугышның икмәге.

*

## 4. МӘХӘББӘТ ҺӘМ НӘФРӘТ

Сугыш килде безгә сорамыйча,
Шакымыйча керде ишектән.
Кабатладык шулчак тешне кысып:
«Без җиңәргә тиеш ничек тә!»
Туп тавышы аяз күкне түгел,
Күңелләрне ыграк тетрәтте.
Ник уяттың, сугыш, вәхшилекне,
Ник уяттың кеше нәфрәтен?
Ни эшлисең, сугыш, илләр буйлап? —

Син кермәгән өйләр калмады.
Тик берәү дә сине колач җәеп,
Кунак итеп каршы алмады.
Туган җирнең азатлыгын тою,
Җир җылысын тою мең рәхәт! —
Дошманнарга нәфрәт арткан саен,
Туган җиргә артты мәхәббәт.

*

## 5. ЕГЕРМЕ МИЛЛИОН

Балалар уйныйлар «сугышлы» уены,
Сугыш ул — аларга тик уен.
Ә минем уемда кайтмыйча калганнар —
Егерме миллион, егерме миллион.
Тол килеш картайды, агарды чәчләре,
Ишләрен тапмады күп куен.
Куенга алыр да терелтер идем мин...
Егерме миллион, егерме миллион.
Яз килгәч шыталар кан төсле чәчәкләр,
Котлыйлар Җиңүне — ил туен.
Мәйданда ут яна, мәйданда — чәчәкләр...
Егерме миллион, егерме миллион.
Карыйм да кояшка, эндәшәм дөньяга:
Тынычмы күңелең, ни гамең, ни уең?
Мин түгел, мин түгел, эндәшә дөньяга
Егерме миллион, егерме миллион...

*

## ТОРМЫШ АРИФМЕТИКАСЫ

Әткәй кайтты. Сугыштан соң тудым.
Саннар тапкырларга өйрәндем.
Һәр җан җирдә бары тик бердәнбер.
Кушканнар да безне, бүлгәннәр дә...
Җир тарихын яттан өйрәндем.
Санап бетә алмыйм — җирдә күпме кабер.
Бәхетлегә саннар кирәк түгел.
Бурычым күп. Кайчан түләрмен?!
Кемгә — кабер илдә, кемгә — хөрмәт-кадер.
Ике давыл арасында яшим.
Мин бер генә тапкыр үләрмен...
Бер кат яшим җирдә, бары тик бер!
Гомер? Гомер!

*

## ЯЗГЫ БУРАН

Тышта буран, яз бураны —
Тузгый йолдыз тузаны.
Сизәм: язгы буран кебек
Дулап гомер узганны.
Язгы буран, назлы буран —
Мәхәббәт бураннары.
Мине никтер читләп үтте,
Җаныма уралмады.
Тынды буран. Буран белән
Бар дөнья сүнгән, тынган...

Кем җылытыр күңелемне?
Алда — яз, ә мин туңам.

*

## КАЙТАБЫЗ

Иң зур рәхәте дөньяның —
Очып төшүләр таудан!
Бу карлар болыттан түгел,
Йолдыздан, ахры, яуган.
Егылсаң, кереп чумасың, —
Ак кар әйтерсең күбек,
Иге дә юк, чиге дә юк, —
Безнең хыяллар кебек.
Бар кайгылар онытылган, —
Уйныйбыз җилләр кочып,
Гүя ерак балачакка
Кайтабыз кабат очып.

*

## КЫЗ СУРӘТЕ

Ул йончыган, талган, хәлсез калган
Һәм караган алга, ымсынып...
Хәрәкәтсез килеш басып тора,
Үз-үзенә куйган сын кебек.
Сүз башлавын көттем. Тик бер кабат
Төште миңа аның карашы:
Яман уйга катгый нокта кебек —
Күзләренең янган карасы.

*

## ТИК МИНЕКЕ

Җилләрдән мин сафлык таләп иттем,
Болытлардан аклык сорадым.
Хаклык эзләп, пакьлек эзләп җирдә
Тирәнәйде маңгай сырларым.
Күңелемә кайгы-сагыш төшсә,
Ак чәчәкләр җирдә эзләдем.
Офыкларга карап көтә торгач,
Офыкларга мандым күзләрем.
Аклык эзләп гомер иткәнгәме, —
Ап-ак булды чигә чәчләрем.
Шатлыгымны җилгә сибеп йөрдем,
Тик кайгымны җиргә чәчмәдем.
Моннан ары күзне күккә төбәп,
Буш хыяллар белән йөрмәмен.
Минем бәхет тик минеке булыр, —
Туктамасын гына йөрәгем.

*

## ЯШЕНЛЕ ЯҢГЫР

Күктә — яшен,
Җирдә — давыл,
Өйләр манма
Утыра.
Дөньяга

Ачуы бардай, —
Бөтен җиһан
Котыра.
Агачлар
Шакый тәрәзә,
Яфраклары
Шыбырдый.
Менә очып
Китәр төсле, —
Өй түбәсе
Шыгырдый.
Калтырый йорт,
Дөберди күк...
Сөенә чәчәк-үлән.
Болын бүген
Күкне эчә
Зәңгәр күзләре белән.

*

## КӨЗ ОФЫГЫ

Көз әле алтынсу биләүдә —
Мин инде җәйләрне сагынам.
Сагышның мәйданы киңәя —
Офыклар киңәйгән чагында.
Соңгы кат сөенеп калыйм дип,
Каеннар таң белән торганнар.
Күңелгә көз моңын иңдереп,
Каңгылдый һавада торналар.
Яңгырый хушлашу авазы
Күкләрдән, таулардан — бар яктан;
...Йөрәгең өзелер бер мәлдә —
Агачтан өзелгән яфрактай.
Тик һаман кошларга ияреп
Талпына күңелем югары.
Бәхетнең үзенә илтә күк
Күктәге кошларның юллары.

*

## ЕГЕТ БУЛДЫМ

Малай идем,
— Бу Җир шары
нигә әйләнә? — дип,
янып бәхәсләшә белә идем.
Кояш көлгәндә дә,
көлмәгәндә дә
көлә идем.
Ә нигә син
теге кичне
минем малайлыкны тартып алдың?
Алдадың...
Хәзер егет булдым —
мәхәббәттән куркам.
Кабат малайлыкка кайтыр идем,
тагын алданырмын да,
ирең булырмын дип куркам.

*

## ТЕАТР

Әйләнә карусель, әйләнә...
Карусель корылган хәйләгә.

*Мостай Кәрим*

Әйләнә дөньялар, кешеләр, —
Кышларым язларга әйләнә.
Шаккатып, онытып торам мин
Йөрәгем ярасын бәйләргә.
Әйләнә авыллар, шәһәрләр,
Кайгылар шатлыкка әйләнә.
Чуалган, таралган уйларым
Тезелә шул вакыт сәйләнгә.
Сәхнәгә чыгуга һәрвакыт
Нигәдер телләрем бәйләнә.
Әйтерсең язмышым шушында
Түгәрәк бәхеткә әйләнә.
Бу залга керүгә, бар кеше
Иң яхшы кешегә әйләнә, —
Кайгысын калдырып урамда,
Кергән күк илаһи бәйрәмгә.
Патефон табасы шикелле,
Театр сәхнәсе әйләнә.
Елата, җырлата, юата, —
Театр корылган хәйләгә.

*

## КҮКЕ АВАЗЫ

Озын юллар узган көннәремнең
Офыктадыр инде бер башы.
Таң шәфәгы сүнде, төш тә узды...
Баш күтәреп эзлим кояшны.
Талган йөрәк,
Чык суларын эчеп,
Кояш нурын җыеп туяр да
Пешкән җимеш сыман ашыгыр ул
Җылы җиргә башын куярга.
Туган җирем, йөзең алсуланган...
Яңа таңнар сине уяткан.
...Төзәтелгән иске сәгать сыман,
Күке тавышы китми колактан.
Мин ышанмыйм хәзер күкеләргә.
Санамыйм да күпме калганын.
Начарлыклар юрап куркытты да,
Яз һәм сөю биреп алдады.
Ерак түгел, җирем, бәйрәм көнең,
Бүләк итим сиңа ни генә?!
Йортлар салмыйм, текмим киемнәр дә
Һәм үстермим кырда игеннәр.
Тик хезмәтнең беләм чын бәясен,
Тормыш серен аңлыйм, төшенәм.
Бу киемне, йортны, ипине дә
Бүләк итте миңа кешеләр.
Ә мин, җирем, син еласаң — елыйм,
Син шатланган чакта — гел көләм...

Ил алдында олы бурычымны
Түләрмен мин шигырь, җыр белән.

*

## ТУГАН КӨНДӘ

Сорамагыз аның яшен бүген,
Юрамагызниләр көтәсен.
Тәрәзәдән ташып аксын шатлык,
Көлүеннән кайгы үртәлсен.
Көнләшүдән күзен чекерәйтеп,
Тәрәзәдән йолдыз карасын.
Шундый кичләр якынайта бугай
«Бүген» белән «Бәхет» арасын.
Очар кошлар көздән качып китте,
Чәчәкләр дә бетте бит сулып.
Ә ул һаман яз гөлләре төсле,
Тамчы да юк анда моңсулык.
Ул беләдер дус һәм туганнарның
Бар афәттән аны йоласын.
Көз аенда туган кеше өчен
Көзге яңгыр әнә еласын.
Илнең генә түгел, Җир шарының
Аңлый алган уен, бар гамен...
Ул кояшы төсле шушы йортның,
Ул — шатлыгы шушы дөньяның.
Сорамагыз аның яшен бүген,
Юрамагыз ниләр көтәсен.
Бөтен дөнья бүген, бәхет теләп,
Күккә кадәр аны күтәрсен!

*

## ОЧРАШУ

Уйга чумып торам. Уйларымда
Чистарына Болак, тазара.
Уйларымны бүлдең, әй, кара кыз...
...Кайтып килә идең базардан.
Уйларымны бүлеп китеп бардың.
Уйлар китте синең артыңнан.
Ә йөрәгем хисләр җәясендә
Соң чигенә кадәр тартылган.
Язмышыңнан китеп булмый ла ул,
Ник җиде кат күккә качмыйсың...
Моңсуландым, битләремә тамды
Күз яшедәй яңгыр тамчысы.
Синең белән шундый якын идем —
Икебезгә уртак бер урам...
Югалтудан куркып хыялымны,
Урам уртасында тик торам.
Күзләремдә Болак яшеллеге,
Оча иде җаным язларда...
Син аердың мине хыялымнан,
Кайтып килгән чакта базардан.

*

## КАЙТАВАЗ

Урамга чыгып кычкырдым:
— Әй, кайтаваз!
Син кайда-ау?
Ишеттем бары бер аваз:
— Һау-һау, һау-һау,
Һау-һау-һау.
Көтү көткәндә кычкырдым:
— Син кайда?
Хәбәр җибәр!
Ишеттем бары бер аваз:
— Бә-бә, бә-бә,
Бә-бә-бә.
Урманга барып кычкырдым,
Җавабын озак көттем.
Яңгырады моңлы аваз:
— Күк-кү, күк-кү,
Күк-кү-кү.
Төнлә төшемдә сорадым:
— Әйт, кайтаваз!
Син кайда?
Бик ерактан аваз килде:
— А-а-а-а-а-айда-а-а...

*

## ТАТАР КЫЗЫНА

*(Бабичка ияреп)*

Чәчкәйләрең синең гүя иректә җил,
Күзкәйләрең — зәңгәр сулы ике чишмә,
Тешкәйләрең — шул чишмәнең ак ташлары,
Сүзкәйләрең челтер-челтер агып төшә.
Муенкаең җилне, суны күктә тота,
Иңкәйләрең кояш кебек көләч, ачык,
Йөрәккәең — мәңге сүнмәс кайнар вулкан,
Күкрәкләрең — вулкан аткан ике таучык.
Төшәм, төшәм, мактый-мактый һаман төшәм...
Аякларың... Сүз табалмыйм, сүзем бетә.
Тукталам да тагын күккә менеп китәм...
Җилләр, таулар мактап гомерем үтә.

*

***

Карахмәтләр кирәк булса цирк өчен,
Газинурлар кирәк безгә ирек өчен.

*

## БӨЕКЛӘР ТУРЫНДА УЙЛАНУ

*(Җитди шаяру)*

Утыз җиде яшьтә Пушкин үлгән,
Егерме җиде яшьтә — Лермонтов.
Күпме калды безнең яшьтәшләргә? —
Һич тә булмый шуны онытып...
Егерме җиде яшьтә Тукай киткән,
Ә унҗиде яшьтә — Фидаи...
Шагыйрьләрнең гомере кыска, диләр...

Шул турыда әле уйладым.
Ә Җамбуллар? Гёте? Безнең Хәким?
Арслан һәм Нәкый Исәнбәт?
Пушкин Пегасларын йөгәнләгән
Аксакаллар, шөкер, исән бит!
Бөекләрнең кайсы бөегерәк?
Кайсысына охшыйм?.. Уф Аллам...
Чир кагылса, Тукай искә төшә,
Тәнем таза чакта — Туфаннар.

*

**МОҢСУ ШАЯРУ**

Мин күмәч тә пешермәдем,
Күккә акча чөймәдем,
Кемгәдер баш та имәдем...
Мин бары җыр көйләдем.
Сату-алуны белмәдем.
Егермедә өйләндем.
Дошманнар гайбәт сөйләде...
Мин бары җыр көйләдем.
Пегаска да атланмадым,
Парнаска да менмәдем.
Йөрәкләрне дә ватмадым...
Мин бары җыр көйләдем.
Алар бергә учак якты,
Мин ялгызым көйрәдем.
Хорда җырлап булмас, ахры...
Мин ялгыз җыр көйләрмен.

*

***

Минем турыда шигырь язмыйсың, дип,
Үпкәләгән әле хатыным.
Бүген тагын ашы тозлы булган.
Кабартмыйча җәйгән ястыгын.
Төннәр буе күздән кичеп ятам
Идән белән түшәм арасын...
Тозлы ашын, ястыкларын ташлап,
Балачакка килә кайтасым.
Үткәннәрне күпме сагынып була?
Яз, ди, чынны, яз, ди, бүгенне,
Йолдызлар да гел ай күңелендә...
Җир соң әллә матур түгелме?
Барын beләм, барын күрәм, иркәм:
Шигырь белән бөтен җир тулы.
Нишлим? — Бүген карбыз кискән чакта,
Ай турында тагын җыр туды.

*

**КӨЛҮ**

Күршедә сөенеч
Сыймаса өйләргә,
Сагышны онытып,
Без тиеш көләргә.
Юл ярып барганда

Бәхетле көннәргә,
Кайгыны таратып,
Без тиеш көләргә.
Табигать шатлыгы
Әйләнсә гөлләргә,
Гөлләргә кушылып
Без тиеш көләргә.
Җырласа кешеләр
Шатлыклы көйләргә,
Җир-ана үзе дә
Әзер күк көләргә.
Без барда, бу дөнья
Әйләнмәс көлләргә!
Ил өчен без әзер
Елмаеп үләргә.

*

## ВАТАНЫМ

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Инде мин ничәнче мәртәбә
Гасырлар китабын актардым.
Күпме яу, сугышлар аркылы
Син җиңеп чыккансың, Ватаным.
Кушымта:
— Сез кайсы халыктан? — дисәләр,
Батырлар исемен атадым.
Батырлар утларга керделәр,
Тик исән булсын, дип, Ватаным.
Илемнең хуҗасы булганга,
Мин җиргә нык басып атладым.
Кешеләр күтәрде Ватанны,
Кешене күтәрде Ватаным.
Кушымта.
Мин күрдем, төннәрне таратып,
Дөньяда алсу таң атканын.
Яктыра, аллана җир йөзе...
Таң булып нур сибә Ватаным.
Кушымта:
— Сез кайсы халыктан? — дисәләр,
Батырлар исемен атадым.
Батырлар утларга керделәр,
Тик исән булсын, дип, Ватаным.

*

## ТАТАРСТАН

*Мирсәет Яруллин музыкасы*

Яшьлекнең таңында мин күпме
Хыялый сарайлар кормадым!
Хыялны канатлы кош итте,
Туган җир, тик синең җырларың.
Кушымта:
Без — дусларга ак күгәрчен,
Дошманнарга — арыслан.
Безгә шундый иман бирдең,
Көч бирдең, Татарстан.
Янымда син булган чагында

Ялгыз да, ятим дә булмамын!
Мәңгелек көч алам Иделдән,
Җаныма коя күк Чулманың.
Кушымта.
Безгә бит бергәләп кичәсе
Дөньяның давыллы елларын...
Тик бәхет ягына илтсеннәр,
Илтсеннәр Ватаным юллары!
Кушымта:
Без — дусларга ак күгәрчен,
Дошманнарга — арыслан.
Безгә шундый иман бирдең,
Көч бирдең, Татарстан.

*

## ҖИРЕБЕЗНЕҢ ШӘФКАТЬ ТУТАШЫ

*Фасил Әхмәтов музыкасы*

Ил күгенә кара болыт килде,
Җир белән күк бергә тоташты.
Җан өләшеп йөрде кешеләргә
Авыр елның шәфкать туташы.
Кушымта:
Көннәр уза, айлар, еллар уза...
Һаман саф һәм һаман пакь алар.
Җир җылысын йөртә йөрәгендә
Әниләр һәм кызлар, апалар.
Кайгы килсә, бергә күтәреште,
Шатлык килсә, бергә котлашты.
Мәхәббәтне исән алып калды
Гүзәллекнең шәфкать туташы.
Кушымта.
Җиребезне гөлгә, нурга күмде,
Йолдызларга кадәр ул ашты.
Кешелекне саклый яманлыктан
Җиребезнең шәфкать туташы.
Кушымта:
Көннәр уза, айлар, еллар уза...
Һаман саф һәм һаман пакь алар.
Җир җылысын йөртә йөрәгендә
Әниләр һәм кызлар, апалар.

*

## КОЯШЛЫ ҖЫР

*Мәсгудә Шәмсетдинова музыкасы*

Елмаеп карыйлар, —
Ал, зәңгәр үзләре...
Җирдәге чәчәкләр —
Кояшның күзләре.
Йөргәнмен ишетми
Мин аны элгәре...
Сандугач теледер —
Кояшның телләре.
Манды ул алтынга
Җәйләрне, көзләрне.
Урманда, кырларда —
Кояшның эзләре.

Кояшның үзе күк
Хыяллар югары.
Кояшлы булсын гел
Балачак юллары.

*

## КАЙТЧЫ, ӘТКӘЙ!

*Илгиз Мәҗитов музыкасы*

Зәңгәр күктә кошлар очкан чакта,
Укыйм, әткәй, соңгы хатыңны...
Яз аенда, дошманнарны җиңеп,
Кошлар булып әллә кайттыңмы?
Зәңгәр күктә йолдызларга карыйм,
Йолдызлы төн бигрәк тиз уза.
Йолдызларның күзе миндә генә...
Әйләндеңме әллә йолдызга?
Күңелемне һаман сагыш баса,
Аяз күкне баса ак болыт.
Болытларны куып кайтчы, әткәй,
Йолдыз булып яки кош булып.

*

## РАМАЗАН

*Мәсгудә Шәмсетдинова музыкасы*

Дөнья буйлап җырлап киләм,
Җанга мең өмет сыйган.
Җырларыма якты моң бир,
Бир, Ходай, безгә иман.
Кушымта:
Рамазан, Рамазан,
Ишетелә бер азан.
Рамазан, Рамазан
Кайтты безгә яңадан.
Туган яктан гүзәл җир юк,
Илен кем сөеп туйган.
Ватаныма иминлек бир,
Бир, Ходай, безгә иман.
Кушымта.
Таңнар атты, ай да батты,
Уян син, халкым, уян!
Халкыма тел, хөррият бир,
Бир, Ходай, безгә иман.
Кушымта:
Рамазан, Рамазан,
Ишетелә бер азан.
Рамазан, Рамазан
Кайтты безгә яңадан.

*

## БӘХЕТЕМ БАШКАЛАСЫ

*Илгиз Закиров музыкасы*

Кайчакларда килә минем
Иңнәреңә баш саласым.
И Казаным, син бит минем
Сагышым башкаласы.
Кушымта:

Яктырак яна Казан утлары,
Чакыра безне үзенә һаман.
Кайтабыз сиңа, кайтабыз, Казан,
Учак янына җыелган сыман.
Сөенечем, шатлыгымны
Сәгатьләрең гел санасын.
И Казаным, син бит минем
Хыялым башкаласы.
Кушымта.
Йөрәкләргә утлар салып,
Без китәбез, син каласың.
И Казаным, син бит минем
Бәхетем башкаласы.
Кушымта:
Яктырак яна Казан утлары,
Чакыра безне үзенә һаман.
Кайтабыз сиңа, кайтабыз, Казан,
Учак янына җыелган сыман.

*

**ИДЕЛЕМ АКЧАРЛАГЫ**

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Акчарлак канат кага,
Идел тын гына ага.
Акчарлактай ак шәһәрем
Карый елгага.
Үткән еллар, гасырлар.
Кагылган усал чорлар,
Акчарлаклар елавыдай
Ул җырлар.
Кушымта:
Җырлыйм борынгы җырлар,
Җырымның юк азагы.
Ул җырларда гасырларның
Газабы.
Кышны куып илемнән,
Кош китерә язларны,
Син — Иделем акчарлагы,
Казаным!
Акчарлак канат кага,
Иделем ярсып ага.
Акчарлактай ак шәһәрем
Керә җырларга.
Аклыгын ул, сафлыгын
Алды яуларда даулап.
Иделемдә уйнап оча
Акчарлак.
Кушымта:
Җырлыйм борынгы җырлар,
Җырымның юк азагы.
Ул җырларда гасырларның
Газабы.
Кышны куып илемнән,
Кош китерә язларны,
Син — Иделем акчарлагы,
Казаным!

## ҖИҢҮЧЕГӘ

*Фасил Әхмәтов музыкасы*

Җилне узып чаба егет!
Дулкынлана кыр өсте.
Үзе үстергән игеннәр
Аңа булыша төсле.
Кушымта:
Сабантуйда сынала
Батыр егетләр көче.
Колга башындагы сөлге —
Беренче килгән егет өчен!
Тоягың җиргә тимәсен, —
Җилдер тизрәк, әй, юрга!
Авыл башында егетне
Бар халык көтеп тора.
Кушымта:
Сабантуйда сынала
Батыр егетләр көче.
Былбыл телле тальян гармун —
Беренче килгән егет өчен!
Ат тупырдавын уздырып,
Егет йөрәге кага,
Кайсы кыз гына сокланып
Карамый бүген аңа!
Кушымта:
Сабантуйда сынала
Батыр егетләр көче.
Иң сылу кызның йөрәге —
Беренче килгән егет өчен!

*

## ИДЕЛ СУЫ

*Татар халык көе*

Карурманнар сирәгәйде, —
Үтәм хәзер җәяү дә.
Чәчеп печән үстерәбез
Ташу киткәч, җәйләүдә.
Кушымта:
Әл-лә-лә, ил-лә-лә,
Өч куян бар урманда...
Бер төлке дә күргәннәр, ди,
Былтыр иген урганда.
Идел суы майлы да ул, —
Коймак пешереп булмый...
Көне-төне нефть ага,
Ярлары һаман тулмый.
Үткән җәйне бер балыкчы
Тоткан шыртлака балык.
Шушы балыкны күрергә
Җыелган бөтен халык.
Кушымта.
Елга буйларында болын,
Болын түре — әрәмә...
Болыннарны суга күмдек,
Ятмасын дип, әрәмгә.
Кушымта:

Әл-лә-лә, ил-лә-лә,
Өч куян бар урманда...
Бер төлке дә күргәннәр, ди,
Былтыр иген урганда.
Идел суы майлы да ул, —
Коймак пешереп булмый...
Көне-төне нефть ага,
Ярлары һаман тулмый.

## БЕР АЛМАНЫ БИШКӘ БҮЛӘЕК

*Татар халык көе*

Бакчалардан былбыл качса,
Көзләр тисә алмагачка,
Кайгы төшсә безнең башка, —
Бер кайгыны бишкә, әй, бүләек.
Кыш аклыгы гөлгә күчсә,
Алмагачлар кояш эчсә,
Күңелләргә шатлык күчсә, —
Бер шатлыкны бишкә, әй, бүләек.
Шатлык килде, кайгы төште...
Бәхетләр соң кем өлеше!
Бәхет булып алма пеште, —
Бер алманы бишкә, әй, бүләек.

*

## ТАҢ ҖЫРЫ

*Татар халык көе*

Уңда юллар, сулда юллар...
Юлларга кемнәр чыгар.
Таңда егет җырлап узса,
Кыз күңеле ничек чыдар.
Егет китәр еракларга,
Эзләрен яңгыр юар.
Кыз, көн саен чиләк асып,
Авыл башына чыгар.
— Көтмә, — дип үртәр кызлары —
Аның күңеле чуар.
Яңгыр түгел, күз яшьләре
Кызның иренен юар.
Уңда юллар, сулда юллар...
Кайтмыйча ничек чыдар?
Таңда егет җырлап кайтыр,
Кыз йөгереп каршы чыгар.

*

## ДУЛКЫН

*Татар халык көе*

Чем-кара карлыгачлары,
Гөнаһсыз иде яры.
Ник шунда гына калмады,
Ник дулкын китте ары?
Тарсынып язмыш ярларын,
Ул диңгезгә юл алды.
Тау дулкыннар арасына
Кереп күздән югалды.
Күз яшьле акчарлаклары...
Күренми инде яры...

Зәңгәр күк һәм зәңгәр диңгез,
Йолдызлар монда бары.
Бар иде гөлләр, таллары...
Ник китте икән ары?
Елга ярын сагынып елый
Диңгезнең дулкыннары.

*

## ЯДКАРЬ

*Фасил Әхмәтов музыкасы*

Күптән инде, күптән очрашкан юк,
Хәтерлимсез бергә чакларны?
Күңелләрдә йөргән татлы сагыш —
Шул чакларның моңлы ядкаре.
Уртак иде хисләр, айлы кичләр, —
Без кертмәдек анда ятларны.
Күңелләрдә йөргән дуслык хисе —
Шул чакларның моңлы ядкаре.
Бергә откан өмет тулы җырны
Йөрәк инде мең кат ятлады.
Үткәннәрдән бары шул җыр калды, —
Ул җыр безгә яшьлек ядкаре.

*

## ЮЛЛАРЫМ

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Юлларым, юлларым, юлларым,
Юлларым уралган буранга.
Уйларым, уйларым, уйларым...
Кагылма ярама, сорама.
Кырларым, кырларым, кырларым,
Кырларым шатлыгы — тургайлы!
Урманым, урманым, урманым...
Ул миңа гел бәхет юрады.
Инешем, ак чишмәм, тауларым,
Талларым, кырларым, кошларым!
Мин сездә күпме җәй җәйләдем,
Мин сездә күпме кыш кышладым.
Мин киттем. Калдыгыз, калдыгыз...
Юлларым, иң якын дусларым!
Ә хәзер йортым да, юлым да —
Җырларым, җырларым, җырларым.

*

## ЧАПТАРЫМ

***«Ташкыннар» телевизион спектакленнән***

*Фуат Әбүбәкеров музыкасы*

Нинди язмыш безне көтә икән?
Кая чаба икән чаптарым?
Аргамагым эзләп чаба төсле
Бер кайгысыз колын чакларын.
Аргамагым чаба, һаман чаба, —
Тирә-юньдә бары ут кына...
Берәүләргә алтын, алтын яңгыр ява,
Алтын ирләр яуда, яуда ятып кала...
Юллар илтә безне упкынга.

Аргамагым, күпме чапсаң да син,
Әйләнмәссең кабат колынга.
Икебезнең язмыш бер үк төсле —
Икебез дә җирдә кол гына.
Безнең өйгә бәхет килер микән?
Булыр микән бәйсез чакларым?
Кан коюлар безгә, безгә кирәк түгел,
Ирек даулап ярсый, ярсый безнең күңел, —
Ярсып чаба минем чаптарым.
Аргамагым илләр буйлап чаба,
Ирек даулап керә яуларга.
Кара көннәр, янып, артта кала,
Таңнар ата, офык аллана.
Ирләр белән бергә илләр чаба,
Эзләп чаба бәйсез чакларын...
Батыр ирләр, илләр яуда бәхет таба...
Бәхет эзләп һаман, һаман алга чаба
Ялкын яллы кызыл чаптарым!

*

## КЫЗЛАР ҖЫРЛЫЙ

*Мирсәет Яруллин музыкасы*

Кызлар җырлый, кызлар җырлый.
Кызлар җыры — сагышлы;
Кызлар җырына җыелган
Язмышларның ялгышы.
Кушымта:
Кызлар җырын тыңлаганда,
Җан җылылары алам.
Җир үзенең сөенечен,
Бәхетен һәм көенечен
Кызлар җырына салган.
Кызлар җырлый, кызлар җырлый.
Кызлар җыры — канатлы.
Кызлар җыры күңелдәге
Сагышларны таратты.
Кушымта.
Кызлар җырлый, кызлар җырлый.
Кызлар җыры — кояшлы.
Кызлар җырында — шатлыгым,
Сагышларымның башы.
Кушымта:
Кызлар җырын тыңлаганда,
Җан җылылары алам.
Җир үзенең сөенечен,
Бәхетен һәм көенечен
Кызлар җырына салган.

*

## САГЫНАМ

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Су буенда үскән өянкеләр
Синең кебек ак шәл ябынган.
Синең чәчең төсле ак җил тузгый, —
Мин кышларда сине сагынам.
Карашыңдай җылы, аяз көннәр,

Җилләр исә синең ягыңнан.
Гөрләвекләр булып кайтыр идем...
Мин язларда сине сагынам.
Бөтен дөнья бүген шау чәчәктә,
Арынган җир хәсрәт-кайгыдан.
Шатлык төяп кайтып килер идем...
Мин җәйләрдә сине сагынам.
Синең сагыш әллә күчкән инде? —
Урманнарга сары кабынган.
Күзләремдә яшьме, яңгырмы ул? —
Мин көзләрдә сине сагынам.
Офыкларга карап, һәр көн саен
Сине уйлыйм, сиңа табынам.
Бөтенләйгә тиздән кайтырмын күк, —
Сине, әнкәй, сине сагынам.

*

## ЛӘЙСӘН

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Ләйсән яңгырлар яуганда,
Бар кешеләр көлешә.
Җирдә бөтен кешегә дә
Көлү шундый килешә.
Кушымта:
Яу, яңгырым, яу, Ләйсән!
Дөнья язга әйләнсен!
Дөнья язга әйләнсен.
Җырлар җырга бәйләнсен!
Ләйсән яңгыр бар дөньяга
Бәхет-шатлык өләшә.
Җиргә, илгә, кешеләргә
Бәхет шундый килешә.
Кушымта:
Яу, яңгырым, яу, Ләйсән!
Дөнья язга әйләнсен!
Дөнья язга әйләнсен.
Җырлар җырга бәйләнсен!

*

## НИГӘ, ӘНИ, НИГӘ КАРТАЯСЫҢ?

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Нигә, әни, нигә картаясың, —
Уйлыйсыңмы дөнья афәтен?
Күчсен, әйдә, безнең йөрәкләргә
Бар уйларың, бөтен хәсрәтең.
Нигә, әни, нигә картаясың?
Дөнья шундый матур чагында.
Күрәсеңме, әнә, күзләреңдә
Безнең шатлык, бәхет чагыла.
Нигә, әни, нигә картаясың,
Моңланасың һаман, әй, нигә?
Әй, син картлык, кермә безнең өйгә,
Әй, син картлык, тимә әнигә!

*

## ЯВА КАРЛАР

*Заһид Хәбибуллин музыкасы*

Ак канатлы кошлар кебек
Болыт агылды.
Сибелде кырлар өстенә
Аккош мамыгы.
Агарды күк, агарды җир,
Агарды дөнья.
Тик чыршылар гына яшел,
Чыршылар уйда.
Яшел чыршы өнсез калган,
Күреп кыш ямен.
Кыш иңенә сала аның
Бәйрәм күлмәген.
Ява карлар, мамык карлар,
Явар талганчы...
Кошлар кайтып, каурыйларын
Җыеп алганчы.

*

## НАСРЕТДИН

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Авыр юлда бер ялгызың барганда,
Уйларыңны кара кайгы сарганда,
Ашыкма син бар дөньяны каргарга,
Ул таратыр бөтен кайгы-хәсрәтең...
Кушымта:
Насретдин, Насретдин, Насретдин,
Хуҗа Насретдин.
Еллар буе еламасаң, көлмәсәң,
Мәхәббәтнең ни икәнен белмәсәң,
Төннәр буе матур сүзләр эзләсәң,
Төшләреңдә тылсымлы сүз өйрәтер...
Кушымта:
Насретдин, Насретдин, Насретдин,
Хуҗа Насретдин.
Әгәр дөнья йөртсә сине «өф» итеп,
Уйлый күрмә, килде тоташ бәхет, дип.
Уйла аны тик өч көнлек тәхет, дип,
Бу турыда сиңа һәрчак искәртер...
Кушымта:
Насретдин, Насретдин, Насретдин,
Хуҗа Насретдин.

*

## КОЯШ КЕМГӘ ЕЛМАЯ?

*(Шаян җыр)*

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Елмаеп тик бер карадым —
Иделдә акты бозлар.
Күз карашым җылысында
Кызынды сылу кызлар.
Елмаюым ошамаган
Мин сөеп йөргән кызга.
Ут янып торган йөрәге
Әйләнде салкын бозга.

Кушымта:
Кояш елмая көн дә,
Кояш елмая кемгә?
Кояш төсле булам, диеп,
Елмайдым әле мин дә.

Елмайдым мин дошманыма,
Яратмыйм үзен юкса.
Бер мизгелдә кан дошманым
Әйләнде-калды дуска.
Елмаюым ошамаган
Минем иң якын дуска —
Ул дошманыма әйләнде...
Елмайдым гына юкса.

Кушымта:
Кояш елмая көн дә,
Кояш елмая кемгә?
Кояш төсле булам, диеп,
Елмайдым әле мин дә.

Еллар буе йөрдем шулай
Елмаеп-көлеп кенә.
Инде хәзер бөтен кеше
Минем үземнән көлә.
Кояш белән Ай кавышты,
Тәрәзәләр ут алды.
Гел елмаеп йөри торгач,
Бөтен дөньям буталды.
Кушымта:
Кояш елмая көн дә,
Кояш елмая кемгә?
Кояш төсле булам, диеп,
Елмайдым әле мин дә.

*

## ЗӘҢГӘР КӨЙМӘ

*Илдус Якупов музыкасы*

Зәңгәр көймә алга бара,
Дулкыннар яра.
Актарыла ак дулкыннар...
Болытлар кара.
Зәңгәр көймә алга бара,
Туктамый ярга.
Идел өстендә — дулкыннар,
Күңелдә — яра.
Зәңгәр көймә алга бара,
Дулкыннар яра.
Инде менә ничәнче ел
Төзәлми яра.
Зәңгәр көймә алга бара,
Туктамый ярга.
Идел өстен, томан түгел,
Сагышлар сара.
Зәңгәр көймә алга бара,
Дулкыннар яра.
Инде хәзер синең белән
Бик ерак ара.

Зәңгәр көймә алга бара,
Туктамый ярга...
Минем сагыш күчте инде
Акчарлакларга.

*

## МӘХӘББӘТ СУРӘТЕ

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Язларда эзлим, эзлим гел сине,
Эзлим гөл арасыннан.
Юлларга карыйм, яз җиткәч юллар
Яныңа илтә сыман.
Язларда мин барам гел урманга, урманга.
Адашам мин яшел җил-буранда анда.
Урманнарда чәчәк юрган,
Күңелдә буран,
Күңелдә язгы буран.
Язларда языла мәхәббәт сүрәсе,
Язларга охшаган мәхәббәт сурәте.
Язларга охшаган мәхәббәт сурәте,
Язларда языла мәхәббәт сүрәсе.
Язларда эзлим, эзлим гел сине,
Дөньяда — язлар назы.
Кайларда икән, кайларда икән
Мәхәббәт-сөю язы?
Язларда мин карыйм гел һавага, һавага.
Һавада гел ак болытлар ага, ага.
Һаваларда — ак болытлар,
Күңелемдә — янар утлар.
Күңелдә — утлар,
Күңелдә — язгы утлар.
Язларда языла мәхәббәт сүрәсе,
Язларга охшаган мәхәббәт сурәте.
Язларга охшаган мәхәббәт сурәте,
Язларда языла мәхәббәт сүрәсе.

*

## ҮЗЕҢ КИЛЧЕ...

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Чакырма, килмим синең яныңа, мәхәббәтем,
Кайгы да салмам тыныч җаныңа, диеп әйттем.
Кыю бул, иркәм, дисең.
Йосыф булган кыю да... —
Ташлаганнар коега.
Кушымта:
Минем янга, иркәм, син үзең килче.
Йә булмаса җибәр син димче.
Мин көтәрмен, еллар буе түзәрмен,
Юлла сөю сүзләрең.
Мине кемдер яратырга тиеш, кемдер тиеш,
Үлеп яратырга шушы килеш, шушы килеш.
Таһир Зөһрәне тапкан,
Ә соңыннан үзе дә
Сандыкта суда аккан.
Кушымта.
Кирәк түгел сөю кайгылары, кайгылары,

Килсен кояшлысы, айлылары, айлылары.
Мәҗнүн сөйгән, яраткан,
Кара кайгыга баткан,
Аннан башын югалткан.
Кушымта:
Минем янга, иркәм, син үзең килче.
Йә булмаса җибәр син димче.
Мин көтәрмен, еллар буе түзәрмен,
Юлла сөю сүзләрең.

*

## СИНЕ КҮРСӘМ

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Сине күрсәм, сине күрсәм,
Сагышларым уяна.
Сине күрсәм, сине күрсәм,
Сагышларым уяна да,
Йөрәгем утта яна.
Сине күрсәм, сине күрсәм,
Күңелне моңнар сара.
Сине күрсәм, сине күрсәм,
Моңнар сара, әрни башлый
Йөрәгемдәге яра.
Сине күрсәм, сине күрсәм,
Җир әйләнә кирегә.
Сине күрсәм, сине күрсәм,
Җирләр әйләнә кирегә,
Син киләсең бирегә.

*

## СӨЙЛӘМӘ МӘХӘББӘТ ТУРЫНДА

*Луиза Хәйретдинова музыкасы*

Сөйләмә син миңа мәхәббәт турында,
Ышандыр иң элек талларны.
Ә миңа тал сөйләр, тал сөйләр аннары,
Ышандыр иң элек талларны.
Сөйләмә син миңа мәхәббәт турында,
Сереңне ач башта тирәккә.
Тирәкләр дәшәрләр, дәшәрләр йөрәккә,
Сереңне ач башта тирәккә.
Сөйләмә син миңа мәхәббәт турында,
Ышандыр иң элек үзеңне.
Моң бассын сагышсыз, сагышсыз күзеңне,
Ышандыр иң элек үзеңне.

*

## КОЯШТАЙ ЕЛМАЙ

*Илгиз Закиров музыкасы*

Айның язмышы
Төнгә бәйләнгән.
Кояш тирәли
Мәңге әйләнгән.
Толымы төннең
Чем-кара икән.
Күлмәген дә төн
Карадан теккән.

Кушымта:
Кояш тирәли
Ай гел әйләнгән...
Минем язмышым
Сиңа бәйләнгән...
Йолдызлар биек,
Моңсу һаман Ай...
Таратып төнне,
Кояштай елмай.
Минем язмышым
Сиңа бәйләнгән...
Көннәрем шуңа
Төнгә әйләнгән.
Күзләре төннең
Зәңгәрдән икән,
Такыясын төн
Йолдыздан чиккән.
Кушымта:
Кояш тирәли
Ай гел әйләнгән...
Минем язмышым
Сиңа бәйләнгән...
Йолдызлар биек,
Моңсу һаман Ай...
Таратып төнне,
Кояштай елмай.

## ҮПКӘЛӘМӘ

*Алмаз Хәмзин музыкасы*

Үпкәләмә миңа, үпкәләмә,
Үпкәлә син көзге җилләргә.
Миңа кала бары сагышлысы, —
Уйларымны җилләр җилгәрә.
Үпкәлә син соры болытларга —
Түбәнәйтте алар күгемне.
Тәбәнәк тә, тар да хәзер дөнья —
Сыйдыралмыйм анда күңелне.
Үпкәлә син аннан мәхәббәткә...
Нигә мине читләп уза ул?
Нигә килми?! Йөрәк ачык тора —
Алынган бит биге, йозагы.
Минем мондый җырлар җырлавыма
Ачы җилле көзгә үпкәлә.
Шул җилләрдән аралыйсың килсә,
Син мине дә кайчак үпкәлә...

*

## КАЙТ СИН МИҢА

*Рөстәм Яхин музыкасы*

Өмет кебек ап-ак көймәләрне
Гөрләвектә бергә агыздык.
Язлар килсә, чыгам урамнарга, —
Гөрләвектә ага ялгызлык.
Йөрәкләрдән уртак ялкын алып,
Учакларны бергә кабыздык.
Учак булып янды безнең сөю,
Көле булып калды ялгызлык.

Шатлыклар да күрдем, кайгылар да,
Күрмәдем тик синнән явызлык.
Ә нигә соң каргыйм үткәннәрне? —
Явызлыкмы әллә ялгызлык?
Синең күзләр төсле сагышлы төн,
Синең шәүләң кебек ялгызлык.
Кайт син миңа. Уртак ялгызлыкны
Гөрләвектә бергә агызыйк.

*

## ТӨСЛЕ ҖЫР

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Нигә күк һәрвакыт зәп-зәңгәр, гел зәңгәр?
Сагышлы зәңгәрлек сибелә күзләрдән.
Сөйсәң син әгәр дә, —
Сагыш бар зәңгәрдә.
Зәңгәр күк, зәңгәр күз, зәңгәр моң...
Мәхәббәт сагыштан тора ул.
Нигә таң көн саен алсу гел, гел алсу?
Таңнарда нигә соң һәрвакыт ямансу?
Сөйсәң син әгәр дә, —
Таң — алтын мәгарә.
Алсу күк, алсу йөз, алсу моң...
Мәхәббәт шатлыктан тора ул.
Зәңгәр күк, алсу таң, якты көн, кара төн...
Син мине, ахрысы, мәңгегә караттың.
Төсләрне тараттың...
Мин сине яраттым.
Сөюем — бәхеткә илткән юл...
Сагышлы шатлыктан тора ул.

*

## КӨТӘМ

*Оскар Усманов музыкасы*

Буран булып, урам тулып
Очты күңел кошым.
Яуды карлар, синсез яуды,
Синсез узды кышым.
Кушымта:
Ә мин һаман җанда йөртәм
«Сөям» дигән сүзең.
Көтәм сине җәен, кышын,
Көтәм язын, көзен.
Сулды инде умырзая,
Тынды моңлы сазым.
Ташып акты ярсу хисләр,
Синсез узды язым.
Кушымта.
Сине көтеп, юлларыңа
Чәчәк җәймә җәйдем.
Ялгыз уздым болын буйлап,
Ялгыз узды җәем.
Кушымта.
Уза еллар, уза гомер,
Юлда һаман күзем.
Сине көтеп, алмагачым

Чәчәк атты көзен.
Кушымта:
Ә мин һаман җанда йөртәм
«Сөям» дигән сүзең.
Көтәм сине җәен, кышын,
Көтәм язын, көзен.

## ЙӨРӘК ДӘШӘ

*Резедә Әхиярова музыкасы*

Икәү бергә йолдыз санадык без,
Каршы алдык бергә таңнарны.
Оныт, дисең, аңла мине, дисең...
Мин аңлармын... Йөрәк аңлармы?..
Көйгә салып, бергә җырладык без
Күңелдәге уртак моңнарны.
Башка җырлар хәзер җырла, дисең...
Мин җырлармын... Йөрәк җырлармы?
Мин әле дә гашыйк йолдызларга, —
Тик син генә кинәт үзгәрдең.
Юкка янма, юкка көймә, дисең...
Мин түзәрмен... Йөрәк түзәрме?
Мин ышанмыйм синең сүзләреңә, —
Күзләреңдә ялкын күрәмен.
Мәхәббәтне яклап, соңгы кабат
Йөрәгеңә дәшә йөрәгем.

*

## ЧАБА ПОЕЗД, ЧАБА

*Резедә Әхиярова музыкасы*

Чаба поезд, чаба
Туган якка таба, —
Каршы ала горур имәннәр.
Бозып яшьлек антын,
Туган якка кайта
«Хуш мәңгегә, сау бул!» дигәннәр.
Чаба поезд, чаба
Туган якка таба, —
Түземнәрем узды чамадан.
Авылыма кайтсам,
Дусларымны тапсам,
Яши башлармын күк яңадан.
Чаба поезд, чаба
Туган якка таба, —
Йөрәк ярсый, хыял ашыга.
Әйтерсең лә бүген,
Ак каеннар түгел,
Балачагым чыккан каршыма.

*

## ИҢ ЯКТЫ ЙОЛДЫЗ

*Гали Ильясов музыкасы*

Син еракта, әллә кайда
Биектә идең.
Арабызга болыт керде,
Йолдызым минем.
Йолдыз төсле күзләрең...
Нигә моңсу йөзләрең?

Күктә йолдыз атылганда,
Ничек түзәрмен?
Кулларымны күккә сузган
Җир улы идем.
Ә син мәңге минем янга
Төшалмам, дидең.
Йолдыз төсле күзләрең...
Нигә моңсу йөзләрең?
Күктә йолдыз атылганда,
Ничек түзәрмен?
Күзен кыса күпме йолдыз...
Мин һаман ялгыз.
Миңа карап яна күктә
Иң якты йолдыз.
Йолдыз төсле күзләрең...
Нигә моңсу йөзләрең?
Күктә йолдыз атылганда,
Ничек түзәрмен?

*

## КАР КЫЗЫ

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Ява карлар, ява талгын гына, —
Ак өметләр ява сыман.
Эзләп йөрим бүген бәхетемне
Ак бураннар арасыннан.
Кушымта:
Әй, Кар кызы, әйтмә салкын сүзләр,
Буран булып чыкма юлларыма.
Алып бар син мине үзең белән
Гел язлардан торган елларыма.
Ява карлар, ява. Ак ялкыннар
Күңелемне ала сыман...
Ак бәхетләр теләп, иңнәреңә
Туй күлмәге сала сыман.
Кушымта.
Ява карлар, ява кайнар карлар,
Ява йөрәк ярасына.
Мәхәббәтем бүген табармын күк
Кайнар карлар арасыннан.
Кушымта:
Әй, Кар кызы, әйтмә салкын сүзләр,
Буран булып чыкма юлларыма.
Алып бар син мине үзең белән
Гел язлардан торган елларыма.

*

## ЗИНҺАР ӨЧЕН, КЕРМӘ ТӨШЛӘРЕМӘ...

*Резедә Әхиярова музыкасы*

Зинһар өчен, кермә төшләремә...
Мин бит сине күптән оныттым,
Җәй җилләре күптән агарттылар,
Тараттылар сагыш болытын.
Зинһар өчен, кермә төшләремә...
Уянам да никтер боегам.
Әйтерсең лә су алмакчы булам

Күптән кипкән сусыз коедан.
Зинһар өчен, кермә төшләремә...
Таң атуга төшләр өзелә.
Көннәремне, елларымны алдың,
Төннәремне калдыр үземә.
Зинһар өчен, кермә төшләремә...
Үртәмәче, көлмә ерактан.
Сине түгел, мин бит яшьлегемне
Шулай сагынам, шулай яратам.
Зинһар өчен, кермә төшләремә...
Минем хәлгә кемнәр төшенә? —
Сөям хәзер бары хыялымда,
Яшим хәзер бары төшемдә.

*

## ТАШЛЫК АВЫЛЫ ҖЫРЫ

*Алмаз Хәмзин музыкасы*

Урманнарга барган идем
Каршы алды имәннәр.
Урман кебек шаулап яши
Туган ягын сөйгәннәр.
Кушымта:
Туган аулым Ташлык —
Минем җаныма башлык.
Ташлап китмәм ташкалага,
Мин бит Ташлыкка гашыйк.
Зәй буена төшкән идем
Колач җәеп йөзәргә,
Безнең яктан матур җир юк, —
Ышан минем сүзләргә.
Кушымта.
Кайнар тауга менгән идем,
Аякларны пешерә.
Җаннары таш булмаганнар
Безне искә төшерә.
Кушымта:
Туган аулым Ташлык —
Минем җаныма башлык.
Ташлап китмәм ташкалага,
Мин бит Ташлыкка гашыйк.

*

## АКБҮЗ АТ

*Рәшит Кәлимуллин музыкасы*

Туй күлмәге кигән таллар,
Бизәнгән урамнары.
Кочагына алды безне
Мәхәббәт бураннары.
Кушымта:
Акбүз ат, акбүз ат, акбүз ат, акбүз ат...
Кыш аеның аклыгын ал,
Салкынын язга озат.
Ак канатлы акбүз атны
Гашыйклар көтте озак.
Ак бәхетләр юрый-юрый,
Кышлар безгә ашыккан.

Ак юллардан үтә бүген
Җирдә бөтен гашыйклар.
Кушымта:
Акбүз ат, акбүз ат, акбүз ат, акбүз ат...
Кыш аеның аклыгын ал,
Салкынын язга озат.
Ак канатлы акбүз атны
Гашыйклар көтте озак.

*

**ҖИТЕННӘР**

*Фасил Әхмәтов музыкасы*

Гел кояштан торган юллар безне
Офыкларга таба илттеләр.
Гел бәхеттән,
Гел бәхеттән торган сүзләремне
Ишеттеләр,
Ишеттеләр бары җитеннәр,
Ишеттеләр бары зәңгәр күзле җитеннәр.
Син югалдың офык томанында,
Гел сагышлы көннәр җиттеләр.
Хәзер инде,
Хәзер инде тәүге мәхәббәттән —
Хыялымда,
Хыялымда бары җитеннәр.
Хыялымда калды зәңгәр күзле җитеннәр.
Эзләп йөрдем җитен чәчәкләрен,
Эзләп йөрдем җирнең читеннән.
Көтмәгәндә,
Көтмәгәндә үзе очрады ул, —
Чәчләренә,
Чәчләренә кадәр җитеннән.
Чәчләре дә хыялдагы ап-ак җитеннән.

*

**УРМАН ЧИШМӘСЕ**

*Шамил Тимербулатов музыкасы*

Урман юлында чыктың каршыма,
Такыя үреп кидең башыңа.
Кара урманда көндез адаштым,
Калды урманда моңлы карашым.
Кушымта:
Челтер-челтер ага урман чишмәсе.
Челтер-челтер суга ятлар төшмәсен.
Челтер-челтер килә синең сүзләрең лә...
Челтер-челтер көлә гүзәлем, гүзәлем, гүзәлем лә.
Зифа каендай синең буйларың.
Карадым сиңа, карап туймадым.
Чишмә суыдай акты чәчләрең,
Чишмә суыдай җанга чәчрәдең.
Кушымта.
Урман яктырды безне күрүгә.
Чакырдың мине урман түренә.
Урман чишмәсе, сиңа мең рәхмәт!
Чишмәдәй чиста безнең мәхәббәт.
Кушымта:

Челтер-челтер ага урман чишмәсе.
Челтер-челтер суга ятлар төшмәсен.
Челтер-челтер килә синең сүзләрең лә...
Челтер-челтер көлә гүзәлем, гүзәлем, гүзәлем лә.

*

## АК ПАРОХОД

*Сәгыйт Абдуллин музыкасы*

Идел буйлап ак пароход килә.
Иркәм, миңа ак бәхетләр телә.
Ак пароход ялгызларны табыштыра,
Ак пароход йөрәкләрне кавыштыра.
Шатлык төяп, ак пароход килә.
Бөтен дөнья бүген уйный-көлә.
Ак пароход сагышларны тараттыра,
Ак пароход мәңгелеккә яраттыра.
Талгын гына ак пароход килә.
Акчарлаклар җырлый безнең көйгә.
Ак пароход дәшә ерак ил гизәргә,
Ак пароход алып бара диңгезләргә.
Дулкын ярып ак пароход килә.
Серләреңне дулкыннарга сөйлә.
Ак пароход ак хыяллар бүләк итә,
Ак пароход ак бәхеткә алып китә.

*

## АЙ БАТКАНДА, ТАҢ АТКАНДА

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Ай батканда, таң атканда
Уздым җырлап урамнардан.
Ай батканда, таң атканда,
Кемнәр язмыш юрамаган?!
Кушымта:
Бара идек таңда урманнарга,
Кошлар моңын бергә тыңларга.
Синең өчен былбыл сайрый анда,
Минем өчен кәккүк моңлана.
Ай батканда, таң атканда
Кайтып киләм туйларыңнан.
Төн карасы, җан ярасы
Китми минем уйларымнан.
Кушымта.
Ай батканда, таң атканда
Җырлыйм да күк, җылыйм да күк.
Мең шатлыклар телим сиңа...
Туктамыйча сана, кәккүк!
Кушымта:
Бара идек таңда урманнарга,
Кошлар моңын бергә тыңларга.
Синең өчен былбыл сайрый анда,
Минем өчен кәккүк моңлана.

*

## БИШЕК ҖЫРЫ

*Шамил Тимербулатов музыкасы*

Әлли-бәлли: йом син күзең,

Әлли-бәлли — татлы сүзем.
Йоклый инде бөтен бәбиләр дә,
Йоклый инде хәтта әбиләр дә.
Әлли-бәлли, йом син күзең,
Әлли-бәлли, татлы сүзем.
Әлли-бәлли итәр балам,
Әлли-бәлли, алтын алмам.
Йоклый инде бөтен малайлар да,
Йоклый инде хәтта бабайлар да.
Әлли-бәлли итәр балам,
Әлли-бәлли, алтын алмам.
Әлли-бәлли, йоклап китәр,
Әлли-бәлли, үсеп җитәр.
Йоклый җиһан бәллүр бишегендә,
Йоклый алмый әни кеше генә.
Әлли-бәлли, йом син күзең,
Әлли-бәлли... Бетте сүзем.

*

## ҖЫРЛЫЙК ӘЛЕ

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Дулкыннары белән Идел
Кагылды җанга.
Мин мәңгегә монда, диде,
Агалмам анда.
Кушымта:
Туган якның бар моңнары
Безнең күңелдә.
Җырлыйк әле, җырлыйк мәңге,
Җырлыйк бүген дә!
Сөембикә манарасын
Дәштек без юлга.
Ләкин безнең белән юлга
Чыкмады ул да.
Кушымта.
Чакырдык без шомыртларны,
Миләш, баланны.
Тик алар да безнең белән
Килә алмады.
Кушымта:
Туган якның бар моңнары
Безнең күңелдә.
Җырлыйк әле, җырлыйк мәңге,
Җырлыйк бүген дә!

*

## «ТАТАРСТАН» ПОЕЗДЫ

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Саубуллашып кул болгадым,
Янды йөрәк ярасы.
Сагышларны оныттырды
Казан — Мәскәү арасы.
Кушымта:
Дөнья буйлап, сине уйлап
Инде күпме юл уздым.
Бәхетемә илтә кебек

«Татарстан» поезды.
Төн шикелле моңсу иде
Күзләреңнең карасы.
Табыштырды, кавыштырды
Мәскәү — Казан арасы.
Кушымта.
Поезд кебек үтә гомер...
Күпме калды барасы?
Җыр шикелле кыска икән
Мәскәү — Казан арасы.
Кушымта:
Дөнья буйлап, сине уйлап
Инде күпме юл уздым.
Бәхетемә илтә кебек
«Татарстан» поезды.

*

## КАЙЛАРДА БӘХЕТЛЕ ИЛЛӘР?

*Луиза Батыр-Болгари музыкасы*

Ник чыга кояш,
Ник ата таңнар,
Нигә сагышлы
Хыялый җаннар?
Ник ява яңгыр,
Ник исә җилләр?
Кайларда икән
Бәхетле илләр,
Кайларда бәхетле илләр?
Ник үсә гөлләр,
Ник шаулый урман,
Минем хыялның тамыры корган.
Ник яши кеше,
Ник дәшми илем?
Мин бу дөньяга
Нигә дип килдем?
Мин бу дөньяга нигә килдем?

*

## МОҢЛАНМА

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Моңланма, җаным, моңланма,
Авыр миңа болай да.
Синең янга килгән саен,
Моң өстәлә моңнарга.
Зарланма, җаным, зарланма,
Гүя минем зарым юк.
Зарым да син, парым да син, —
Минем башка ярым юк.
Көнләшмә, җаным, көнләшмә,
Инде бик күп көнләдең...
Синең белән уртак инде
Көннәрем һәм төннәрем.
Елама, җаным, елама,
Нигә юкка еларга?
Яңгыр түгел, бәхет яусын
Без барасы юлларга.

*

## ӘЛИФБА

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Әлифбам — тормышта
Беренче баскычым.
Син — белем дөньясын
Ачучы ачкычым.
Кушымта:
Әлифба, Әлифба,
Син минем юл башым.
Дәфтәргә төшердең
Күктәге кояшым.
Өйрәттең син мине
Хәрефләр тезәргә.
Тылсымлы хәрефләр
Әйләнде сүзләргә.
Кушымта.
Каләмем йөгерә
Мин бер сүз әйтүгә.
Дәфтәрдә бар хәзер
Әни дә, эти дә.
Кушымта.
Өйрәттең син миңа
Ватанны сөяргә.
Рөхсәт ит, зур рәхмәт,
Мең рәхмәт — дияргә!
Кушымта:
Әлифба, Әлифба,
Син минем юл башым.
Дәфтәргә төшердең
Күктәге кояшым.

## САУ БУЛ, ҖӘЙ!

*Әнвәр Бакиров музыкасы*

Сау бул, җәй!
Хушыгыз, елгалар!
Хушыгыз, болыннар, кырларым!
Мин сездә туйганчы уйнадым,
Иң матур җырларны җырладым.
Сау бул, җәй!
Хушыгыз, урманнар,
Күкләргә үрләгән учаклар!
Учаклар шикелле яктырып
Хәтердә сакланыр ул чаклар.
Сау бул, җәй!
Хушыгыз, юлларым!
Юллардан инде күп атладым.
Күрдем күп илләрне, җирләрне,
Батырлар исемен ятладым.
Сау бул, җәй!
Чакыра мәктәбем.
Алтыннан — сентябрь юллары.
Барасы юлларым — бик ерак,
Хыялым кояшы — югары.

*

## СИРАТ КҮПЕРЕ

*Шамил Тимербулатов музыкасы*

Син һаман көләсең,
Җанымны теләсең...
Ә минем күңелем моңлана.
Мәхәббәт янәшә,
Йөрәккә ул дәшә,
Читләрне, ятларны тыңлама.
Кушымта:
Ялгыз җырлар җырлый-җырлый
Инде күп йөрдем.
Әйдә, китик, бергә үтик
Сират күперен!
Әйдә, китик, бергә үтик
Гомер юлларын,
Икәү бергә җырлыйк әйдә
Сөю җырларын.
Син — сылу су кызы,
Мин — гади җир улы,
Тик гади түгел шул мәхәббәт.
Таратты сагышны,
Йөрәкләр кавышты...
Җанымда — мең ләззәт, мең рәхәт.
Кушымта:
Ялгыз җырлар җырлый-җырлый
Инде күп йөрдем.
Әйдә, китик, бергә үтик
Сират күперен!
Әйдә, китик, бергә үтик
Гомер юлларын,
Икәү бергә җырлыйк әйдә
Сөю җырларын.

*

## БЕЗНЕҢ ҖЫР

*Илгиз Закиров музыкасы*

Һавада каурый болытлар
Аккош каурые сыман.
Безнең җырга туган якның
Бар матурлыгы сыйган.
Кушымта:
Язларны ләйсән китерә,
Ләйсән — кояшлы яңгыр.
Безнең җырлар күңелләргә
Ләйсән яңгырдай явар.
Елгада — шәһәр шәүләсе
Йөзә аккошлар сыман.
Безнең җырга туган якның
Бар сөенече сыйган.
Кушымта.
Офыкта — шәһәр утлары,
Таң шуннан ата сыман.
Безнең җырга туган якның
Бар батырлыгы сыйган.
Кушымта:
Язларны ләйсән китерә,

Ләйсән — кояшлы яңгыр.
Безнең җырлар күңелләргә
Ләйсән яңгырдай явар.

*

## СӘГАТЬ СУГА

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Әйдә, искә алыйк әле
Борынгы гадәтләрне...
Бер минутка тынып торыйк,
Онытып сәгатьләрне.
Без бит җирдә һәммәбез дә
Табигать сәнгатьләре...
Җир-анага саулык бирсен
Яңа ел сәгатьләре.
Иске елда калсын әле
Кайгының сәбәпләре.
Кавыштырсын гашыйкларны
Яңа ел сәгатьләре.
Ташып торсын туган илнең
Шатлык-сәгадәтләре...
Сәгать суга, сәгать суга, —
Яңа ел сәгатьләре.

*

## ҺАЙ, ДУСЛАР

*Татар халык көе*

Елга ага, елга ага,
Ярлар озатып кала.
Бәхетен эзләп, елганың
Зәңгәр күзләре тала.
Кушымта:
Һай, дуслар!
Чит җирләрдә
Бәхет эзли
Елгалар, җилләр генә,
Елгалар, җилләр генә.
Җилләр исә, җилләр исә,
Җилләр исә шәрекъка.
Бәхетен таба алмыйча,
Җилнең гомере үтә.
Кушымта.
Бәхет эзләп талган картлар
Карый иленә таба...
Ир-егетләр үз бәхетен
Туган җирендә таба.
Кушымта:
Һай, дуслар!
Чит җирләрдә
Бәхет эзли
Елгалар, җилләр генә,
Елгалар, җилләр генә.

*

## КӨЗГЕ ШАТЛЫК

*(Вальс)*

*Илдус Якупов музыкасы*

Әйләнә җирем яктыга,
Син дә бер очып әйлән!
Уйна, бие, җырлар җырла, —
Авылда бүген бәйрәм!
Түгәрәк ипи шикелле,
Тулган Ай йөзә күктә.
Көз аенда дөнья — муллык,
Яшьләр кавышу көтә.
Кушымта:
Күз иярми игенченең
Аяк басуларына.
Җитезлеккә өйрәнгәндер
Иген басуларында.
Кояш төсле көләч йөзле,
Арып кайтса да эштән, —
Игенченең күңеленә
Кырлар шатлыгы күчкән.
Көз аенда кияү килә,
Йортларга төшә килен.
Игенчеләр арасыннан
Батырлар сайлый илем.
Кушымта:
Күз иярми биюченең
Аяк басуларына.
Батырлыкка өйрәнгәндер
Иген басуларында.

*

## СОҢГЫ ЧӘЧӘК

*Луиза Батыр-Болгари музыкасы*

Мин килдем кояшлы дөньяга,
Мин — җирнең иң соңгы чәчәге.
Күзләрдә иртәнге чык түгел,
Тапталган мәхәббәт яшьләре.
Мин көлмим кешеләр көлгәндә,
Еламыйм, кешеләр еласа...
Мин инде бәхеттән ваз кичтем,
Таңнарда җанымны моң баса.
Мин килдем кояшлы дөньяга,
Мин — җирнең иң соңгы бер гөле.
Кем табар миңа бер җылы сүз?
Кем ачар сагышлы күңелне?

*

## СИН ГЕНӘ

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Үтә айлар, еллар,
Туа яңа җырлар.
Минем җырым һаман үзгәрми.
Кем соң минем иркәм?
Йөрәгемдә йөртәм
Аңа дигән сөю сүзләрен.
Кушымта:
Син генә ул ямьле язым,

Син генә ул моңлы сазым,
Син генә ул якты хыялым.
Син генә ул минем ярым.
Син генә ул минем парым,
Син генә, син генә...
Яшь гомерем үтә,
Багып зәңгәр күккә...
Күзләремдә якты төс уңды.
Көн дә карыйм Айга, —
Сөйгән ярым кайда?
Ишетәме минем җырымны?
Кушымта.
Ялгыз чыгам юлга,
Ялгыз микән ул да...
Ялгызлыкка күңел түзәрме?
Исемен дә белмим,
Үзен һаман эзлим
Һәм кабатлыйм бер үк сүзләрне.
Кушымта:
Син генә ул ямьле язым,
Син генә ул моңлы сазым,
Син генә ул якты хыялым.
Син генә ул минем ярым.
Син генә ул минем парым,
Син генә, син генә...

## ЕЛМАЙСЫН САБЫЙЛАР

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Агара, чалара әнием чәчләре...
Агармый тик кайгы карасы.
Мәйданда, мәйданда мәңгелек ут яна,
Ул — минем йөрәгем ярасы.
Кушымта:
Сабыйлар, сабыйлар елмайган чагында,
Кайгының юллары ябыла.
Кешеләр, кешеләр кайгысын таратып,
Елмайсын сабыйлар тагын да!
Мин беләм, мин беләм: бары тик бер адым
Кайгылар, бәхетләр арасы.
Менә шул, менә шул мәңгелек арада
Сулкылдый йөрәгем ярасы.
Кушымта.
Бәхетләр, бәхетләр ягына юл тотып,
Безгә бит әле күп барасы.
Сабыйлар, сабыйлар елмайса дөньяда,
Төзәлер йөрәгем ярасы.
Кушымта:
Сабыйлар, сабыйлар елмайган чагында,
Кайгының юллары ябыла.
Кешеләр, кешеләр кайгысын таратып,
Елмайсын сабыйлар тагын да!

*

## ЯЗГЫ НАЗ

*Шамил Тимербулатов музыкасы*

Янган йөрәк, ярсу күңел
Ашкына язга.

Язлар килә җиргә бик азга.
Кояш төсле син дә мине
Иркәлә, назла.
Сөю назы була тик язда.
Илдә яз, җирдә яз,
Бар дөньяда яз,
Дәртле яз, назлы яз.
Очар идем бүген йолдызга кадәр,
«Сөям» диеп әйтсәң син әгәр.
Туган җиргә, туган илгә
Тагын язлар килә.
Минем белән бергә җырлый дөнья,
Минем белән бергә көлә.
Яңгыр ява, ләйсән яңгыр,
Шатлыклар ява.
Хисләр ташый, йөрәк ут яна.
Ашкын җаннар мәхәббәтен
Язларда таба.
Шуңа, ахры, гашыйк мин язга.

*

## САУМЫ, КАЗАН!

*Рәшит Кәлимуллин музыкасы*

Туган калам син!
Казан, сиңа мин гел табындым.
Чакырганда син
Кош булып канат, әй, кагындым.
Сагындым мин гел,
Ашкындым сиңа, и Казаным!
Җаным синдә гел,
Синдә — юл башым, юл азагым.
Кушымта:
Саумы, Казан,
Саумы, Казан!
Туган калам!
Саумы, Казан!
Синдә минем
Җаным калган.
Без мәңге бергә, Казан!
Синең ташыңа язмышым язам.
Туган калам син!
Сиңа илтсеннәр бар юлларым.
Уйлап сине гел
Җир йөзен күпме, әй, урадым.
Синдә — якын дус,
Синдәдер минем чын язларым.
Синдә — сөйгән яр.
Бәхетем синдә, и Казаным!
Кушымта:
Саумы, Казан,
Саумы, Казан!
Туган калам!
Саумы, Казан!
Синдә минем
Җаным калган.
Без мәңге бергә, Казан!

Синең ташыңа язмышым язам.

## ЖЫР ЧАКЫРА

*Котдус Хөснуллин музыкасы*

Ничәнче ел илләр имин тора,
Ничәнче ел туплар ярылмый.
Туплар тынсын өчен утка керде,
Яуга керде Фәрит Яруллин.
Тургай булып күккә ашкан чакта,
Җир үзенә алды җыр улын.
Җиңү җырын җырлый бүген тургай, —
Җырлый гүя Фәрит Яруллин.
Афәт килсә илгә, мин тау булыйм!
Туфан килсә, биек яр булыйм!
Ватан өчен җанны кызганмаска
Өйрәтте бит Фәрит Яруллин.
Кая барсам, дуслар каршы алыр,
Бәхетләргә илтер бар юлым.
Җыр чакыра яңа җиңүләргә, —
Җыр башлаучы Фәрит Яруллин.

*

## И МАШИНА, МАШИНА...

*Луиза Батыр-Болгари музыкасы*

И машина, машина,
Үсми агач башында.
Кемгә булыр машинам, дип,
Бабай, башың кашыма.
Кушымта:
И машина, машина,
Җитте минем башыма.
И машина, машина,
Чыктым юлның башына.
Машиналарга утырып,
Бәхет килә каршыма.
Кушымта:
И машина, машина,
Җитте минем башыма.
И машина, машина,
Минем янга ашыга.
Елыйм да мин, көләм дә мин,
Сөенәм дә мин шуңа.
Кушымта:
И машина, машина,
Җитте минем башыма.
И машина, машина,
Җитте минем башыма.
«Машинага кызыкма» дип
Яздым кабер ташына.
Кушымта:
И машина, машина,
Җитте минем башыма.

## БАЛАЧАК ЯЛКЫНЫ

*Фасил Әхмәтов музыкасы*

Һәрвакыт уяумы, әзерме?
Чакыра балачак быргысы.
Безгә бит бу чорны төзисе,

Заманның җырларын җырлыйсы.
Кушымта:
Без уяу, без әзер,
Йөрәкләр һәрвакыт ялкынлы.
Җәлилләр, Алишлар ялкыны
Мәңгелек ут булып балкыды.
Әйләнеп карасаң үткәнгә,
Күренә янгыннар яктысы.
Безгә бит илләрне, җирләрне
Яманлык күзеннән саклыйсы.
Кушымта.
Бәхеткә юл ярып барганда,
Юлдаш бул һәрвакыт халкыңа!
Яшь калсын йөрәкләр мәңгегә,
Сүнмәсен балачак ялкыны!
Кушымта:
Без уяу, без әзер,
Йөрәкләр һәрвакыт ялкынлы.
Җәлилләр, Алишлар ялкыны
Мәңгелек ут булып балкыды.

*

## БАЛАЧАКНЫ САГЫНУ

*Ренат Ибраһимов музыкасы*

Балачак, әй, шат чак,
Гел сүнмәс учак.
Шушы учак ялкыны җанда
Мәңге, мәңге яначак.
Моңланам мин җыр җырлап,
Юанам сине уйлап.
Балачакка кайтып барам
Гомерем кыры буйлап.
Балачак, әй, шат чак,
Гел сулмас чәчәк.
Чәчәк тотып, төшемә минем
Балачагым керәчәк.
Моңланам мин җыр җырлап,
Юанам сине уйлап.
Балачакка кайтып барам
Гомерем кыры буйлап.

*

## АЛМА САТАМ, ЧИЯ САТАМ...

*Луиза Батыр-Болгари музыкасы*

Алма сатам, алма сатам,
Алмасыз калма тагы.
Алма кебек ярлар белән
Каршылыйк әле таңны.
Хөрмә сатам, хөрмә сатам,
Хөрмәсез кала күрмә.
Хөрмә кебек чибәрләрнең
Урыны була түрдә.
Чия сатам, чия сатам,
Чиясез кермә өйгә.
Күңелләрем чияләнмәс
Җырласаң безнең көйгә.

Алма сатам, хөрмә сатам,
Хисләрем кушып сатам.
Минем өчен җанын биргән
Бер чибәрне яратам.

*

## ДУСЛЫК УЧАГЫ

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Дуслар белән учак яктык
Төнге елга ярында.
Төн дә якты була икән
Янда дуслар барында.
Кушымта:
Казан — Уфа, Уфа — Казан —
Дуслык учагы.
Учак кебек кайнар икән
Дуслар кочагы.
Таңга кадәр җырладык без
Төнге елга ярында.
Җырлар дәртле була икән
Янда дуслар барында.
Кушымта:
Казан — Уфа, Уфа — Казан —
Дуслык учагы.
Учак кебек кайнар икән
Дуслар кочагы.
Кошлар җырын җырладык без
Тып-тын елга ярында.
Һәркем былбыл була икән
Янда дуслар барында.
Кушымта:
Казан — Уфа, Уфа — Казан —
Дуслык учагы.
Учак кебек кайнар икән
Дуслар кочагы.

*

## «ӘЙДӘ БАРЫЙК, КЫЗЛАР КАРЫЙК»

*музыкаль комедиясеннән җырлар*

*Луиза Батыр-Болгари музыкасы*

### МИН БЕР ГЕНӘ ТАПКЫР ЯРАТТЫМ

Синнән башка беркем кирәк түгел,
Син бит минем якты йолдызым.
Сине эзләп ничә утка кердем,
Сине эзләп күпме юл уздым.
Кушымта:
Кояш булып чыктың юлларыма,
Төннәремне куып тараттың.
Мин бер генә тапкыр тудым җиргә,
Мин бер генә тапкыр яраттым.
Йөрәгемне сузып кулларымда,
Бу дөньяны мең кат буйладым.
Чибәрләргә күзем төшкәндә дә,
Синдә иде минем уйларым.

Кушымта:
Кояш булып чыктың юлларыма,
Төннәремне куып тараттың.
Мин бер генә тапкыр тудым җиргә,
Мин бер генә тапкыр яраттым.

*

## ТУАЧАК КЫЗЫМА, УЛЫМА

Бәхетең мөлдерәп торганда,
Очраса мең бәхет юлыңда,
Онытма бәхетләр кирәген
Туачак кызыңа, улыңа.
Кушымта:
Гашыйклар күрдисәм юлымда,
Күңелем көнләшә, кызыга.
Бар булган байлыгым — хисләрем —
Туачак улыма, кызыма.
Аңласа әгәр ул җанымны,
Күтәреп йөртермен кулымда.
Җанымны урталай бүләрмен
Туачак кызыма, улыма.
Кушымта:
Гомернең иң матур мизгеле
Яр белән бергәләп узыла.
Ник яшим дөньяда, булмаса
Туачак улым да, кызым да?!

*

## МОҢЛАНУ

Синең җырың минем җырым иде,
Синең язмыш — минем язмышым.
Ул җырларны хәзер ялгыз җырлыйм...
Мин ялгыштым, ахры, мин ялгыштым.
Мин ялгыштым, ахры, ялгыштым.
Сине күрми торган чакларымда,
Офыкларда иде карашым.
Көпә-көндез бүген кояш батты...
Мин адаштым, ахры, мин адаштым.
Мин адаштым, ахры, адаштым.
Ялгызларны бәхет читләп үтә...
Үз-үземне ничек юатыйм?
Сине түгел бүген, мәхәббәтне
Мин югалттым, ахры, мин югалттым,
Мин югалттым, ахры, югалттым.

*

## САНА, КӘККҮК, САНА ТАҢНАРЫМНЫ

Айлы иде кичләр,
Якты иде көннәр.
Кемнәр назлый хәзер,
Сөя сине кемнәр?
Шатлык тулы иде
Безнең уртак таңнар.
Минем хәлне аңлар
Сагышлы җаннар.

Кушымта:
Сана, кәккүк, кәккүк, сана таңнарымны,
Сана, кәккүк, кәккүк, сана төннәремне.
Көннәремә салдың кәккүкләрнең моңын,
Кочагыңа алдың хәзер кемнәрне?
Уртак иде еллар,
Уртак иде айлар.
Минем йөрәк әле
Һаман ярсу, кайнар.
Уртак иде язлар,
Уртак иде көзләр.
Синнән башка йөрәк
Ничек соң түзәр?
Кушымта:
Сана, кәккүк, кәккүк, сана таңнарымны,
Сана, кәккүк, кәккүк, сана төннәремне.
Көннәремә салдың кәккүкләрнең моңын,
Кочагыңа алдың хәзер кемнәрне?

*

## ЯШЬЛЕГЕМ КАНАТЫНДА

*(Вальс)*

Язлар белән син килерсең төсле,
Мин язларга шундый ышанам.
Язлар җитсә, ташый мәхәббәтем,
Минем күңел язга охшаган.
Кушымта:
Очып килдем синең янга
Яшьлегем пар канатында,
Сагышларны таратырга,
Мәңгегә яратырга,
Мәңгегә яратырга.
Язлар үтәр, сүнмәс безнең хисләр,
Мин бит сиңа шундый ышанам.
Ялгыз җанда көз җилләре исә,
Ялгыз җаннар көзгә охшаган.
Кушымта:
Очып килдем синең янга
Яшьлегем пар канатында,
Сагышларны таратырга,
Мәңгегә яратырга,
Мәңгегә яратырга.

*

## КЫШКЫ УЧАК

*(Вальс)*

Тагын бер ел иңләп узды
Язмышым урамнарын.
Кайгыларны адаштыра
Яңа ел бураннары.
Кушымта:
Ява карлар, яңа карлар,
Яңа елның кары ява.
Кар өстендә, учак булып,
Яшьлек елларым яна.

Тагын бер ел шаулап узды,
Туздырып ап-ак карны.
Ак кар булып, уйнап оча
Яңа ел шатлыклары.
Кушымта.
Тагын бер ел иңрәп узды,
Тик хәтер булып калды.
Аклык булып җанга иңә
Яңа ел болытлары.
Кушымта:
Ява карлар, яңа карлар,
Яңа елның кары ява.
Кар өстендә, учак булып,
Яшьлек елларым яна.

*

**ХАТЛАР КӨТӘМ АВЫЛДАН**

Җырлар оттым авылымда
Чишмәләр тавышыннан.
Кайда минем көмеш чишмәм,
Очрашып кавышырга?
Кушымта:
Таңнар атса, кичләр җитсә,
Чишмәләрне сагынам.
Сагышларым басылыр күк,
Хатлар килсә авылдан.
Кайда минем урманнарым,
Кайда соң болыннарым?
Нинди җилләр тарый икән
Талларның толымнарын?
Кушымта.
Ала алмыйм күзләремне
Авылым якларыннан.
Хатлар көтәм, сәлам көтәм
Бәхетле чакларымнан.
Кушымта:
Таңнар атса, кичләр җитсә,
Чишмәләрне сагынам.
Сагышларым басылыр күк,
Хатлар килсә авылдан.

*

**МӘХӘББӘТ ДАРУЛАРЫ**

Янам инде, көям инде
Мәхәббәт учагында.
Нигә мине юатмыйсың
Тылсымлы кочагыңда?
Кушымта:
Ничек кенә басыйм икән
Йөрәгем януларын?
Кайдан гына табыйм икән
Мәхәббәт даруларын?
Сагышланам таңнар белән,
Моңаям кичләр белән.
Нигә мине терелтмисең
Тылсымлы хисләр белән?

Кушымта.
Ала алмыйм күзләремне
Кояшлы күзләреңнән.
Нигә мине назламыйсың
Тылсымлы сүзләр белән?
Кушымта:
Ничек кенә басыйм икән
Йөрәгем януларын?
Кайдан гына табыйм икән
Мәхәббәт даруларын?

*

**БӘХЕТЕМ АЧКЫЧЫ**

*(Миләүшә һәм Рамил җыры)*

Ашкына йөрәгем,
Юлларның юк очы,
Кемнәрнең кулында
Бәхетем ачкычы?
Кушымта:
Кем мине назлады,
Кем сөйде, кем кочты?
Кемнәрнең кулында
Мәхәббәт ачкычы?
Хисләрем ник ташты,
Йөрәгем кем ачты,
Кемнәрнең кулында
Бәхетем ачкычы?
Кушымта:
Кем мине назлады,
Кем сөйде, кем кочты?
Кемнәрнең кулында
Мәхәббәт ачкычы?

*

**БУРАНЛЫ КӨННӘРДӘ АДАШТЫМ**

Ялгызым урамнар урадым,
Ятларга серләрем сөйләдем.
Күңелем хис тулы булса да,
Мин әле беркемне сөймәдем.
Кушымта:
Буранлы төннәрдә адашып,
Ялгызым урамнар урадым.
Әгәр мин моңайган кешене очратсам,
Сөйгәнем килә дип уйладым.
Мин һаман ышанам язмышка,
Син миңа барыбер очрарсың.
Син минем канатка пар булып,
Мәхәббәт иленә очарсың.
Кушымта:
Буранлы төннәрдә адашып,
Ялгызым урамнар урадым.
Әгәр мин моңайган кешене очратсам,
Сөйгәнем килә дип уйладым.

*

## КАРТ ӨЯНКЕ

*Шамил Тимербулатов музыкасы*

Уза гомер, ага сулар,
Яр буенда карт өянке.
Өянкедә сайрый кошлар,
Сайрый өзеп, аһ, йөрәкне.
Кушымта:
Чая инеш читкә агар,
Карт өянке ялгыз янар...
Карт өянке күзләреннән,
Инеш булып, яшьләр тамар.
Яр буенда карт өянке.
Ботакларын җил каерган.
Карт өянке төпләрендә,
Сине уйлап, мин кайгырам.
Кушымта.
Җирдә ялгыз яшәп булмый,
Инеш кибә, тал да корый.
Кайт син миңа, яшьлек ярым,
Инеш кебек урый-урый.
Кушымта:
Чая инеш читкә агар,
Карт өянке ялгыз янар...
Карт өянке күзләреннән,
Инеш булып, яшьләр тамар.

*

## БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТ УРАМЫ

*С.Солтанов музыкасы*

Чакыра язмышым авазы...
Кайларга илтәсез, юлларым?
Ашкына ал кояш артыннан
Бәхеткә сусаган елларым.
Кушымта:
Ияреп хыялым артыннан
Дөньяны мең кабат урадым.
Күрмичә, сизмичә узганмын
Беренче мәхәббәт урамын.
Очрады бәхетле юлдашлар,
Ишеттем вәгъдәләр, ялганнар.
Хисләрем, йолдызлы кичләрем
Мәңгегә авылда калганнар.
Кушымта.
Чакыра язмышым авазы...
Дөньяны мең кабат урадым.
Кабул ит, мин кайтам яңадан,
Беренче мәхәббәт урамым!
Кушымта:
Ияреп хыялым артыннан
Дөньяны мең кабат урадым.
Кабул ит, мин кайтам яңадан,
Беренче мәхәббәт урамым!

*

## ТУГАН ТЕЛДӘ ДӘШСӘМ ГЕНӘ...

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Каршы ала туган якта
Тургай тавышы.
Бары тургай аңлый бугай
Минем сагышны.
Сайра, тургай, мәңге сайра, —
Аңлыйм телеңне.
Син сайрасаң, дөнья ямьле,
Яшәү күңелле.
Кушымта:
Туган телдә җырлый чишмә,
Туган телдә шаулый таллар.
Туган телдә дәшсәм генә,
Туган җирем мине аңлар.
Сайрый тургай туган җирдә,
Шатлык түгелә.
Тургай җыры, тургай моңы
Минем күңелдә.
Җырлый бүген бөтен дөнья
Тургай телендә.
Мин кушылып җырлыйм аңа
Туган телемдә.
Кушымта:
Туган телдә җырлый чишмә,
Туган телдә шаулый таллар.
Туган телдә дәшсәм генә,
Туган халкым мине аңлар.

*

## ОНЫТ ИНДЕ

*Резедә Әхиярова музыкасы*

Оныт мине, зинһар, оныт инде —
Утка яктым синең хатларны,
Утка яктым ялган вәгъдәләрне,
Утка яктым бергә чакларны.
Оныт мине, зинһар, оныт инде...
Җил тарата учак көлләрен.
Җилгә очты бөтен хыялларым,
Утта янды гашыйк көннәрем.
Оныт мине, зинһар, оныт инде,
Салма мине утлы күмергә.
Кайтып булмый узган мәхәббәткә,
Кайтып булмый узган гомергә.

*

## ИНЕШ

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Төштем инеш буена,
Суда таллар коена.
Син дә бүген тал янына
Килерсең күк тоела.
Кушымта:
Аһ, инеш, инеш, инеш,
Хәлемне минем белеш.
Син диңгезең кочагында,
Мин талдай ялгыз килеш.
Моңлы инеш агышы,

Талда сөю сагышы.
Таллы инеш буйларында
Күпме ярлар кавышты.
Кушымта:
Аh, инеш, инеш, инеш,
Хәлемне минем белеш.
Син диңгезең кочагында,
Мин талдай ялгыз килеш.
Инеш буе тал гына,
Кочагыңа ал гына...
Таллар кала, инеш ага,
Ага диңгез ягына.
Кушымта:
Аh, инеш, инеш, инеш,
Хәлемне минем белеш.
Син диңгезең кочагында,
Мин талдай ялгыз килеш.

## ЕЛГАЛАР САЕККАН ЧАГЫНДА

*Чулпан Зиннәтуллина музыкасы*

Ике яр кушылыр шикелле,
Елгалар саеккан чагында.
Көймәгә утырып юл чыктык,
Шәүләбез дулкында чагыла.
Яшәсәң иде бу дөньяда
Бил бирми хәсрәткә, кайгыга.
Мең шатлык койса да күңелгә,
Бәхетем елгасы саега.
Чайкала язмышым көймәсе,
Син бүген көймәнең түрендә.
Күңелдә бик ерак диңгезнең
Давыллы дулкыны күренә.
Хисләрем, шифалы яңгырдай,
Сусаган җаннарны сугара...
Мәңгегә килгән күк дөньяга
Салганмын елларны суларга.
Ярларны күп күрде бу көймә,
Дулкыннар иркендә чайкалды...
Тик бүген беренче мәртәбә
Күңелем давыллап айкалды.
Гомернең уртасы, челләсе...
Җанымны ачыйм соң кемнәргә? —
Гомерем елгасы саегып,
Ярлары кавышкан көннәрдә...
Елгалар саеккан чагында,
Утырдың көймәмнең түренә...
Хисләрем рәшәсе эчендә
Мәхәббәт диңгезе күренә.

## МИН БИТ СИНСЕЗ ТОРАЛМАМ

*Чыңгыз Абызов музыкасы*

Саубуллашмый китеп бардың,
Югалдың рәшәләрдә.
Телсез калдым, белмәдем мин
Ни диеп дәшәргә дә.
Кушымта:
Син югалган юлга карап,
Сагышларга уралам.

Сагышларыма уралам,
Мин бит синсез торалмам.
Син үпкәләп китеп бардың,
Юатырга соңардым.
Соңарганнар, минем кебек,
Югалтадыр сыңарын.
Кушымта.
Еламыйча китеп бардың.
Синсез ничек яшәрмен?
Минем күңелләргә тулган
Синең дә күз яшьләрең.
Кушымта.
Саубуллашмый китеп бардың,
Кайтып кер исәнләшеп.
Мин бит бары сине көтеп,
Җан асрыйм, исән яшим.
Кушымта:
Син югалган юлга карап,
Сагышларга уралам.
Сагышларыма уралам,
Мин бит синсез торалмам.

## ИЛҺАМ

*Луиза Батыр-Болгари музыкасы*

Ил кайгырса, илдә Илһам җылый,
Ил сөенсә, илдә Илһам көлә;
Бәгырьләрне безнең телә-телә,
Чорлар аша узып бер моң килә.
Кушымта:
Һай, дусларым минем, туганнарым,
Кайгылардан сезне ничек йолыйм?!
Онытыгыз бөтен кайгыларны, —
Сезнең өчен бүген үзем җылыйм,
Сезнең өчен бүген үзем җырлыйм.
Туар көннән якты бәхет көтеп,
Төште инде сары сагыш йөзгә.
Гел кояшлы көн сорамыйм, Ходам,
Илһамлы көн бир син бүген безгә.
Кушымта.
Илһамлы сүз — бары туган җирдә,
Иң татлы моң — бары туган телдә...
Шатлыгым да, хәсрәтем дә минем,
Бәхетем дә бары туган илдә.
Кушымта:
Һай, дусларым минем, туганнарым,
Кайгылардан сезне ничек йолыйм?!
Онытыгыз бөтен кайгыларны, —
Сезнең өчен бүген үзем җылыйм,
Сезнең өчен бүген үзем җырлыйм.

*

## КАЙТАМ ИНДЕ ДӨНЬЯ УРАП

*Чулпан Зиннәтуллина музыкасы*

Кайтам инде дөнья урап,
Туган як болынына.
Болыннарда атлар чаба,
Мин анда колын гына.

Кушымта:
Чит илләрдә, чит җирләрдә
Газиз гомерләр үткән.
Диңгез суы нигә тозлы? —
Әллә күз яше микән?
Кайтам инде дөнья урап,
Адашам урманымда.
Минем язмыш туры килде
Юлларның уравына.
Кушымта.
Кайтам инде дөнья урап,
Туган як кырларына.
Йөрәккәем түзәр микән
Тургайлар җырлавына?!
Кушымта.
Кайтам инде дөнья урап,
Шәл япкан талларыма.
Әнкәй үзе, шәл ябынып,
Чыгар күк алларыма.
Кушымта:
Чит илләрдә, чит җирләрдә
Газиз гомерләр үткән.
Диңгез суы нигә тозлы? —
Әллә күз яше микән?

## ХӨРРИЯТ

*Резедә Әхиярова музыкасы*

Каршы ала таңда мине Идел,
Идел куенында ак томан.
Кояш булып балкый өмет нуры,
Ватанымның күге яктырган.
Таңда чыгам иркен басуларга,
Басу өсләрендә мең тургай.
Ирек канатында очкан кошлар
Безнең шатлык, безнең моң бугай.
Кушымта:
Илгә якты бирер өчен,
Янып яшәргә кирәк.
Күңелләргә ялкын салып,
Алга дәшә хөррият.
Таңнар аткач, йөрим бакчаларда,
Төнне куып офык аллана.
Судан алып утка салды безне
Давыллардан торган замана.
Җырлап керәм таңда урманнарга,
Җавап бирә иңрәп карурман.
Карурмандай шаулап яшик әле, —
Без барыбыз уртак тамырдан.
Кушымта.
Бәхет эзләп чыгам таңда юлга,
Юллар урау, юллар тузанлы.
Тузан булып илгә сибелсәк тә,
Безнең гомер зая узмады.
Кушымта:
Илгә якты бирер өчен,
Янып яшәргә кирәк.
Күңелләргә ялкын салып,

Алга дәшә хөррият.

## МӘХӘББӘТНЕ ҖИРГӘ ЯЗ КИТЕРГӘН

*Резедә Әхиярова музыкасы*

Мәхәббәтне җиргә яз китергән,
Мәхәббәтне язлар саклаган.
Язлар кебек янып яшим җирдә,
Язлар кебек мәңге саф калам.
Мәхәббәтне җәйләр гөлгә күмгән,
Мин җәйләрдән һәрчак көнләшәм.
Җәй кояшы кебек көлеп яшим,
Җәйләр кебек җылы өләшәм.
Мәхәббәтне көзләр моңсу иткән,
Мәхәббәтне көзләр елаткан.
Көзләр кебек мин дә моңсуланам,
Көзләр кебек сөям ерактан.
Мәхәббәтне кышлар адаштырган,
Кышлар аңа бәхет юраган.
Мин мәңгегә чыга алмам инде
«Сөю» дигән кайнар бураннан.

*

## БӘХЕТ НИГӘ ЕРАК?

*Оскар Усманов музыкасы*

Уза гомер, уза
Искән җил кебек.
Язлар килгән саен
Куям җилкенеп.
Кушымта:
Төнем нигә кара,
Йолдыз ник дәшә?
Бәхет нигә ерак,
Кайгы янәшә?
Уза гомер синсез,
Уза язларым.
Җанны телә һаман
Сөю газабы.
Кушымта:
Төнем нигә кара,
Йолдыз ник дәшә?
Бәхет нигә ерак,
Кайгы янәшә?
Уза гомер, уза, —
Җитәр көзләрем.
Гомер буе, ахры,
Сине эзләрмен.
Кушымта:
Төнем нигә кара,
Йолдыз ник дәшә?
Бәхет нигә ерак,
Кайгы янәшә?

## СӨЕМБИКӘ

*Резедә Әхиярова музыкасы*

Казаныма төннәр иңсә,
Сине эзләп карыйм күккә.
Зәңгәр күктә Ай моңлана,
Моңлана күк Сөембикә.

Кушымта:
Ай моңлана зәңгәр күктә,
Казан һаман сине көтә.
Язмышыма хуҗа булып
Кайтчы, зинһар, Сөембикә.
Сине уйлап үтә язлар,
Сине уйлап көзләр җитә.
Яңгыр булып көз еламый,
Син елыйсың, Сөембикә.
Кушымта:
Ай моңлана зәңгәр күктә,
Казан һаман сине көтә.
Язмышыма хуҗа булып
Кайтчы, зинһар, Сөембикә.
Сагышларны сүтә-сүтә,
Айлар үтә, еллар үтә.
Безнең язмыш синең белән
Мәңге бергә, Сөембикә.
Кушымта:
Ай моңлана зәңгәр күктә,
Казан һаман сине көтә.
Язмышыма хуҗа булып
Кайтчы, зинһар, Сөембикә!

*

## СОҢГЫ МӘХӘББӘТ

*Фәрит Хатыйпов музыкасы*

Мәхәббәттән өмет өзгән чакта,
Синең белән нигә кавыштым?
Сау бул инде! Шушы кавышуым
Булса иде соңгы ялгышым.
Кавыштырмый икән уртак кайгы,
Кирәк икән уртак хыяллар.
Сау бул инде! Сөю бакчасында
Бар агачлар яфрак койганнар.
Кешеләргә бәхет биргән сөю
Миңа бирде көзләр сагышын.
...Сау бул инде, соңгы мәхәббәтем,
Сау бул инде, соңгы ялгышым!

*

## СӘЙДӘШ МОҢЫ

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Карлар ява Казан урамына,
Моңнар иңә талган күңелгә,
Әйтерсең лә бүген бөтен дөнья
Сәйдәш моңы белән күмелә.
Кушымта:
Ул халкымның бәхет кошы сыман,
Ул халкымның ачы күз яше.
Син, татарның җанын аңлыйм дисәң,
Утыр да бер тыңла Сәйдәшне.
Казан күген кара болыт сарган,
Сәмруг кошлар канат кагына.
Ирек даулап ярсый Сәйдәш җаны,
Барып чыга Әдрән ягына.

Кушымта.
Сәйдәш моңы өйдән өйгә йөри,
Җанын телә һәрбер татарның.
Илдән илгә сөйләп йөри Сәйдәш
Татарының таңы атарын.
Кушымта:
Ул халкымның бәхет кошы сыман,
Ул — халкымның ачы күз яше.
Син, татарның җанын аңлыйм дисәң,
Утыр да бер тыңла Сәйдәшне.

*

## КҮКТӘН ИҢГӘН БӘХЕТ

*Луиза Батыр-Болгари музыкасы*

Кайда йөрдең, бәхет?
Көттем сине күптән.
Җирдән көткән бәхет
Иңде миңа күктән.
Бәхет, шатлык эзләп
Юлга чыкмам бүтән.
Мин тапмаган бәхет
Иңде үзе күктән.
Эшләп талды куллар,
Юкка гомер үткән...
Эштән көткән бәхет
Төште бүген күктән.
Бөтен кеше сине
Илдән, җирдән көткән.
Миңа дигән бәхет
Иңде бүген күктән.

*

## КАБАН КҮЛЕ СЫМАН

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Кабан күле сыман
Моңсу кайчак күңел,
Сүзләр белән генә,
Юатырлык түгел.
Кушымта:
Салды безне еллар
Язмыш учагына...
Кабан күле мәңге
Казан кочагында.
Кабан күле сыман
Ярсый кайчак җаным.
Күмелгәндер тарих
Төпләрендә аның.
Кушымта.
Кабан күле якты,
Халкым йөзе сыман.
Кабан ярларына
Безнең язмыш сыйган.
Кушымта:
Салды безне еллар
Язмыш учагына...
Кабан күле мәңге

Казан кочагында.

*

## БАЛАЧАГЫМ

*Рәшит Кәлимуллин музыкасы*

Ага чишмә җырлап,
Белми талачагын...
Чишмә җыры төсле
Булсын балачагым.

Кушымта:
Әйдә, җырлыйк бергә, —
Күңел моңга тулган.
Һәммә кеше җирдә
Элек бала булган.

Беләм җанда мәңге
Әни калачагын.
Әти-әни белән
Узсын балачагым.

Кушымта:
Әйдә, җырлыйк бергә, —
Күңел моңга тулган.
Һәммә кеше җирдә
Элек бала булган.

Янып яшим җирдә,
Минем янар чагым.
Кояш сыман көләч
Булсын балачагым.

Кушымта:
Әйдә, җырлыйк бергә, —
Күңел моңга тулган.
Һәммә кеше җирдә
Элек бала булган.

Беләм бәхет эзләп
Юллар салачагым...
Ватан куенында
Узсын балачагым.

Кушымта:
Әйдә, җырлыйк бергә, —
Күңел моңга тулган.
Һәммә кеше җирдә
Элек бала булган.

## СЫКТАУ

*Шамил Тимербулатов музыкасы*

Ак күлмәкле ялгыз каен! —
Сөйлим сиңа олы кайгым.
Мин бит, каен, әтиемне, әниемне югалттым.
Әйтче, каен, ничек итеп күңелемне юатыйм?
Су буенда үскән талым! —
Кайгымны мин суга салыйм.
Мин бит, талым, әтиемне, әниемне югалттым.
Әйтче, талым, ничек итеп күңелемне юатыйм?
Басудагы ялгыз нарат! —

Зинһар, минем кайгым тарат.
Мин бит, нарат, әтиемне, әниемне югалттым.
Әйтче, нарат, ничек итеп күңелемне юатыйм?
Кочагыңа алчы, тирәк! —
Миңа бүген сердәш кирәк.
Мин бит, тирәк, әтиемне, әниемне югалттым.
Әйтче, тирәк, ничек итеп күңелемне юатыйм?

*

## МИН ҺАМАН ЯЛГЫЗ

*Шамил Тимербулатов музыкасы*

Нигә сөйдем мин,
Нигә көйдем мин?
Көлмәче, кызый,
Йөрәгем сызлый,
Сызлый-сызлана.
Күкләргә очты
Хыялым кошы,
Очты хыялым кошы.
Ә син соң кайда, —
Менденме айга?
Ә син соң кайда?
Булмый онытып,
Йөрим ут йотып.
Йөрәктә яра,
Килче, кил, кара.
Йөрәк яралы, —
Төшләрдә күрәм,
Куйныңа керәм,
Керәм утларга, керәм.
Ялгызым иртән
Уянып китәм, —
Мин һаман ялгыз икән...

*

## ТӨНГЕ УЧАК

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Яр буенда бергә йөргән идек,
Яккан идек бергә учаклар.
Төнге учак кебек дәшеп тора
Ай нурында йөзгән ул чаклар.
Кушымта:
Таң атуга учак сүнде,
Әйләнде ул күмергә.
Төнге учак булып калдың
Син мәңгегә күңелдә.
Төннәргә дә бергә кергән идек,
Каршылаган идек таңнарны.
Иреннәрдә һаман янып тора
Мәхәббәтнең сүнмәс кайнары.
Кушымта.
Яр буенда тагын учак яктым.
Син, ахрысы, аны күрмәдең.
Чын мәхәббәт әллә шушы микән? —
Учак булып яна йөрәгем.
Кушымта:

Таң атуга учак сүнде,
Әйләнде ул күмергә.
Төнге учак булып калдың
Син мәңгегә күңелдә.

*

## СӨЙГӘНЕМ КАЙДА?

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Мин сине эзләп күпме ил гиздем,
Сорадым Айдан: «Сөйгәнем кайда?»
Минем кайгыдан каралды төннәр,
Минем сагыштан саргайды Ай да.
Мин сине көтеп күпме яшь түктем,
Сине уйласам, күкләргә ашам.
«Сөйгәнем кайда? Юл күрсәт!» — диеп
Сорадым көн дә якты Кояштан.
Гашыйклар әллә кавыша микән
Ай белән Кояш кавышкан чакта?
Мәхәббәт сүзен кушып сөйлиләр
Күктә йолдызлар — ул безнең хакта.

*

## БЕРГӘ УЗЫЙК КАЗАН УРАМЫН

*Резедә Әхиярова музыкасы*

Мин сагынам назлы язларыңны...
Язларда мин хыял корамын.
Язларда мин, мәхәббәтем эзләп,
Мең урадым Казан урамын.
Кушымта:
Мин Казанда сине эзләп таптым,
Мин Казанда бәхет юрадым.
Бергә узыйк язмыш урамнарын,
Бергә узыйк Казан урамын!
Мин сагынам озын кышларыңны...
Күңелемә күчә бураның.
Бураннарда, сине эзли-эзли,
Мең урадым Казан урамын.
Кушымта.
Мин яратам җылы җәйләреңне...
Мин җәйләрдән яңгыр сорадым.
Сагышларым яңгыр юмасмы, дип,
Мең урадым Казан урамын.
Кушымта.
Мин яратам моңлы көзләреңне...
Көзләрдән мин бәхет сорадым.
Икебезгә уртак бәхет эзләп,
Мең урадым Казан урамын.
Кушымта:
Мин Казанда сине эзләп таптым,
Мин Казанда бәхет юрадым.
Бергә узыйк язмыш урамнарын,
Бергә узыйк Казан урамын!

## ЯҢА ЕЛ БУРАННАРЫ

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Ак биләүгә төргән мине
Яңа ел бураннары.

Хәтеремдә әниемнең
Ак бәхет юраганы.

Кушымта:
Булды инде көннәремнең
Агы да, карасы да...
Әверелде җан сөйгәннәр
Йөрәгем ярасына.

Кайчагында язмыш юлым
Упкынга бара сыман...
Җаннарыма дәва табам
Дусларым арасында.

Кушымта.

Кайчагында күктән йолдыз
Үрелеп алам сыман.
Кайгы килсә — бабай сыман,
Сөенсәм, малай сыман.

Кушымта.

Күңелемә аклык алам
Ак карлар яктысыннан.
Ак төс — минем иманым күк,
Мәңгелек антым сыман.

Кушымта.

Бүген тагын охшап калдым
Яңа ел буранына...
Карлар ява, бәхет ява
Язмышым урамына.

Кушымта:
Булды инде көннәремнең
Агы да, карасы да...
Әверелде җан сөйгәннәр
Йөрәгем ярасына.

*

## МИН БИТ СЕЗНЕ САЙЛАДЫМ

*Алмаз Хәмзин музыкасы*

Ялгыз узып булмый гомерне,
Ялгыз корып булмый язмышны.
Кайгыларны дуслар бүлеште,
Бәхетемне дуслар табышты.
Кушымта:
Туган якта, сездән башка
Ялгыз яши алмамын...
Мәңге бергә булу өчен
Мин бит сезне сайладым…
Әйләнәм дә кайтам яңадан
Сезнең белән бергә чакларга.

Монда — дуслар, монда — туганнар,
Бәхетле мин туган якларда.
Кушымта:
Туган якта, сездән башка
Ялгыз яши алмамын...
Мәңге бергә булу өчен
Мин бит сезне сайладым...
Үтсә иде сезнең арада
Иң бәхетле көннәр, айларым!
Сезнең белән уртак язмышым,
Мәңгелеккә сезне сайладым.
Кушымта:
Туган якта, сездән башка
Ялгыз яши алмамын...
Мәңге бергә булу өчен
Мин бит сезне сайладым...

*

## КАЙТ, АККОШ, КҮЛЕҢӘ

*Рәшит Абдуллин музыкасы*

Күл буе камышы
Уятты сагышны
Тын гына яшәгән чагымда.
Кайт, аккош, күлеңә,
Кайт минем күңелгә,
Кайт минем бәхетле чагыма.
Күлләрдә төнбоек
Саргая моң җыеп,
Ул ялгыз аккошын сагына.
Кайт, аккош, күлеңә,
Кайт минем күңелгә,
Кайт минем бәхетле чагыма,
Күл өсте тып-тыныч,
Ә миңа куркыныч...
Күлләрдә ялгыз ай чагыла,
Кайт, аккош, күлеңә,
Кайт минем күңелгә,
Кайт минем бәхетле чагыма.

*

## БӘХЕТ БЕЛӘН ТУЛГАН КӨН

*Мирсәет Яруллин музыкасы*

Таңда туган кояш баласы син,
Таң нурлары булып иңгәнсең...
Таң шикелле балкып елмаясың,
Кайгыларны куып көләсең.
Кушымта:
Җырлата да туган көн,
Елата да туган көн.
Бөтен дөнья шатлык белән,
Бәхет белән тулган көн.
Ага еллар, ярсу елга сыман,
Син каршыга йөзеп киләсең.
Җил-давыллар күпме сынагандыр
Дәрьядагы язмыш көймәсен.
Кушымта.

Таңда туган таң баласы бит син...
Таңга кадәр бергә җырлашыйк.
Мәңгелеккә җиргә килмәсәк тә,
Бу дөньяга мәңге без гашыйк.
Кушымта:
Җырлата да туган көн,
Елата да туган көн.
Бөтен дөнья сагыш белән,
Бәхет белән тулган көн.

*

## ТАҢ АТКАНДА ТӘРӘЗ АЧТЫМ

*Шамил Шәрифуллин музыкасы*

Таң атканда тәрәз ачтым,
Көн яктысы керсен диеп,
Күңелемнең моңсу гөле
Таң шәфаген күрсен диеп.
Таң атканда тәрәз ачтым,
Җанга шатлык тулсын диеп,
Сагыш сеңгән җырларыма
Кояш нуры кунсын диеп.
Таң атканда тәрәз ачтым,
Назлы җилләр кочсын диеп,
Хыялларым, канатланып,
Синең янга очсын диеп.
Таң атканда тәрәз ачтым...
Аны җилләр ябар инде.
Мин югалткан мәхәббәтне
Җырым эзләп табар инде.

*

## НИ ӨЧЕН?

Барысын беләм:
Кыш — чана шуар өчен,
Җәй — бәбкә куар өчен,
Яз — көймә ясар өчен,
Көз — алма ашар өчен,
Су — тәнне пакьләр өчен,
Ай — җирне саклар өчен...
Тагын, тагын әллә ниләр
Әллә нәрсәләр өчен...
«Дүрт»ле белән «биш»ле алу
Әни яратсын өчен.
Белмим менә «ике»леләр
Һәм «бер»леләр ни өчен?

*

## УЕНЧЫКЛАР

Уенчыклар алып кайтты
Әти миңа кибеттән.
Хәзер инде урам буйлап
Машина белән үтәм.

Болыннарга чыгыйм дисәм,
Ярсу чаптар атым бар.

Бар малайлар яланаяк
Минем арттан чапсыннар.

Кеп-кечкенә өстәлем бар,
Бар минем урындыгым...
Почмактагы шкафыма
Тутырам барын-югын.

Машинама бар гаражым,
Ансын үзем ясаган.
Гараж кырыена терәп,
Шакмаклардан йорт салам.

Әти әйтә: «Уйна, улым,
Әле, — ди, — уйнар чагың...
Ләкин син бит егет кеше,
Кара, — ди, — үсү ягын.

Үскәч, булыр зур машинаң,
Аннан олы гаражың...
Онытылыр уенчыклар,
Уйчанланыр карашың...»

Инде күптән хыялланам
Әти кебек үсәргә.
Зурайсын иде йодрыклар
Йөри торгач кесәдә.

Үзем белән үссен иде
Күлмәгем, чалбарым да.
Үсеп узып китәр идем
Дусларымның барын да.

Ир-егет булып җитешсен,
Үссен дә малай чагым...
Үзем белән бергә үссен
Бар булган уенчыгым.

## ХЫЯЛЫЙ МИЯУБИКӘ

Хыяллана Мияубикә —
Төннәр йокысыз үтә.
Өйдә тамак туймый хәзер...
Ашар нәрсә тик күктә:
Төн җиткәч, йөзеп чыгалар
Күккә маймыч-йолдызлар.
Күзләре күктә песинең...
«Таң атып эшне бозар...»
Авыздан суны китерә
Бер йомарлам сары май:
Күктәге Айны ашарга
Ничек табарга соң җай?
Түбәгә үк менеп баса,
Тик буй һаман җитми шул...
Тешләр — пычак, тәпиләрен
Кармак кебек итмеш ул.
Тау буена болыт булып
Агыла сөт елгасы.
Барыр иде — маэмайлар күп,
Ятасы да еласы.
Җиргә кире төшә песи,
Бүген тагын тамак ач.

Нигә ул май һәм маймычлар —
Күккә баскыч булмагач?

*

## ЕЛАУДАН ҮЗЕ ТУКТАДЫ

Будильник та уянмаган,
Йоклый әле кояш та.
Ә ул елап уяна да
Бөтен өйне уята.
Әби торып сөя көн дә,
Әкият сөйләп юата.
Аның әкиятен тыңлап,
Көлә-көлә таң ата.
Ә ул елый, һаман елый,
Һәр кич елый, һәр иртә.
Шулай итеп озын көннәр,
Айлар һәм еллар үтә?
Мәңге көләч булмас, ахры,
Бу, диләр, Көлмәсбикә.
Көлдерә торган даруны
Врачлар бирмәс микән?
Дару да ярдәм итмәде,
Конфеттан да юк файда.
Елаудан үзе туктады...
Әйтимме сере кайда?
Ул бит хәзер апа булды,
Толымы иңгә җитә.
Хәзер үзе сеңлесенә
Әкият сөйли һәр кичтә.

*

## САНАРГА ӨЙРӘНГӘНДӘ

Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...
Ун бармак миндә бары.
Бабай ничек саный икән? —
Юк аның бармаклары.
Әни сөйли: «Аның да, — ди, —
Бар иде бармаклары.
Кулсыз калдырган бабаңны
Снаряд ярчыклары.
Исәбенә чыгарлыкмы
Ул алган һәм кушканның?!
Ничә шәһәрне алган ул,
Кырган күпме дошманны.
Шартлаткан ничә танкны,
Җимергән ничә дзот?!
Куып барган дошманнарны,
Күп тау, елгалар узып.
Саный китсә, бабаңның, — ди, —
Санар нәрсәләре күп...
Ике кулыннан язса да,
Утырмый ул яшь түгеп.
Көрәшкән ул, җирдә тормыш
Булсын өчен түгәрәк.
Шуңа аның урыны да
Безнекеннән түрдәрәк».

Берәү, икәү... Миңа биш яшь...
Санар нәрсә җирдә күп...
Җитмеш яшь тула бабайга...
Киләм саннар өйрәнеп.
Бармакларым унау минем.
Ун саны бит түгәрәк.
Бабай җиңгән дошманнарны
Саныйк әйдә бергәләп.

## БАРЫСЫН ДА ЯРАТАМ

Кинога барган чакта,
Әтиемне яратам.
Тәмләп-тәмләп ашаганда,
Әниемне яратам.
Абыемны ачуланса,
Мин апамны яратам.
Дәрес хәзерләгән чакта,
Абыемны яратам.
Күрше малае кыйнаса,
Әбиемне яратам.
Әкият сөйләгән чагында,
Мин бабамны яратам.
Өйгә озак кайтмый торсам,
Барысын да яратам.

*

## ЙОКЛА, ЭНЕМ!

Йокла инде, энем, йокла инде,
Син йокласын диеп, кояш сүнде.
Йокла, энем, йокла инде...
Озын юллар үтеп, йокы килде.
Йокла, энем, йокла, күзләрең йом,
Йокы бит ул шундый кызык уен —
Йолдыз керер төшләреңә,
Күзләрең йом, тик ят, дәшмә генә.
Йокла, энем, таңга кадәр йокла,
Кайгырма син урам өчен юкка.
Төне буе явар ак кар,
Урамыңны Кар бабаең саклар.

*

## ХУШ, ИСКЕ ЕЛ!

Иң зур рәхәте дөньяның —
Очып төшүләр таудан!
Бу карлар болыттан түгел,
Йолдыздан, ахры, яуган.
Егылсаң, кереп чумасың:
Ак кар әйтерсең күбек.
Иге дә юк, чиге дә юк —
Безнең хыяллар кебек.
Бу карлар бит иске елның
Яңа елга бүләге.
Иске елның ак карында
Шуып калыйк, кил әле!

*

## ТАБИГАТЬ БАЛАЛАРЫ

Җилкәдә — поход биштәре,
Күңелдә — серле уйлар.
Безнең хыял, шатлык эзләп,
Дөньяны мең кат буйлар.
Без — табигать балалары,
Безнең бәхетле чаклар...
Җир өстеннән төнне куып,
Дөрләп янар учаклар.
Каршылар безне урманнар,
Озатып калыр кырлар.
Юлдаш булыр мәктәпләрдә
Өйрәнгән дәртле җырлар.

*

## ЯЗГЫ УРМАН

Җил зәңгәре сеңгән карга —
Күк үзе көнләшерлек!
Ак каеннарның күзенә
Күренә тик яшеллек.
Бар агачлар караганнар
Көзгедәй күлләвеккә.
Алтын кояш нур җибәрүдән
Аларга көлмәк тегә.

*

## КЫЯРГА КЫРАУ ТӨШӘ

Уҗымнарны кар капласа,
Өшеми, диде, бабай.
Кырау төшә, дип, кыярга
Бүген әни белән әти
Гел арлы-бирле чаба.
Инде җәй буе ашадык,
Кыяр сирәгеп сирәк...
Тик шулай да кызганыч шул,
Саклап калырга кирәк —
Өшемәслек калын итеп,
Кар яусын иде тизрәк.

*

## БЕЗ — КОЯШ БАЛАЛАРЫ

Туган якта куәт җыйгач,
Китәрбез әле ары.
Күзләр күктә: әйтерсең без
Очар кош балалары.
Күңелләр — ярсу дулкындай,
Күренми хәтта яры.
Диңгезгә җитми тынмабыз,
Без — Идел балалары.
Җирдә туып үссәк тә без,
Хыяллар гел югары.
Алсу битләр — ал кояштай,
Без — кояш балалары!

*

## МАЙ КОЯШЫ

Май кояшы күктән көлеп карый,
Май кояшы нигә сөенгән?!
Агачлар да, бәйрәм көткән кебек,
Яшел киеменә киенгән.
Җырлый кебек хәтта тургайлар да:
«Бәхетле, дип, безнең замана».
Күктән кояш үзе ява төсле
Яңгыр тамчылары тамганда.
Июнь булып, хәтта июнь ае
Май аена карап көнләшә.
...Май кояшы, һәр өй саен кереп,
Кешеләргә шатлык өләшә.
Май кояшы күктән көлеп карый,
Май кояшы бүген сөенә.
Урамнарда бүген шатлык кына,
Күңелләрдә дәртле көй генә.

*

## СОҢГЫ КЫҢГЫРАУ

Алда безне күпме юллар көтә...
Бәхетләргә, диләр, юл урау.
Шул турыда искә төшергәндәй,
Яңгырады соңгы кыңгырау.
Бәхет кайда? Китаплардан укып
Бу сорауга җавап тапмадык.
Бәхет эзләп илләр, җирләр кичтек
Хыял тулпарына атланып.
Бөтенесен искә төшерде күк
Кыңгырауның моңлы тавышы...
Шушы мәктәп, шушы класс безгә
Күпме якын дуслар табышты.
...Малайлар да бүген әллә ничек —
Сүз әйтсәң дә оялып кызара...
Сагынырлар, хат юлларлар әле
Чәч толымын тарткан кызларга.
Кызлары да әллә нишләгәннәр —
Менә-менә тора еларга...
Укытучы гына елмая гел,
Гаҗәпләнеп үткән елларга.
«Болары да олы юлга чыга,
Җан җылысы күчкән аларга...»
Һәр кыңгырау саен яшәрә күк,
Тик нигәдер чәче агара...
Очар вакыт җиткән. Кошлар да бит
Утырмыйлар мәңге ояда...
...Аннан безгә җан җылысы күчсә,
Бездән күчсен җылы — дөньяга!
Алда безне олы юллар көтә...
Бәхетләргә, диләр, юл урау.
Урау юллар турыланыр әле —
Алга дәшә соңгы кыңгырау!

## КЫШ

Чаналар чаба тауларда.
Сизелми көн үтүе.
Баш очында болыт йөзә —

Әйтерсең каз көтүе.
Җир өстендә — каз өмәсе,
Оча көн-төн мамыгы.
Күкнең зәңгәр болынында
Казларның үсә агы.
Дөнья көләч. Тик яз җиткәч
Елар ул яшен түгеп.
Ә бүген, кырларга чыгып,
Бары җил елый кебек.

*

## ЯШӘ, КӨМЕШ КЫҢГЫРАУ!

Үз итте безне елгалар,
Эшкә дәште басулар.
Ил гизсәк тә, йөрәкләрдә
Басылмады ярсулар.
Чәчәк җыйдык, гөмбә җыйдык,
Ял иткәндә урманда,
Булыштык без абыйларга,
Җәен иген урганда.
Вакыт таптык уенга да,
Яндык кояш нурында.
Тизрәк барып мәктәпләргә,
Сөйлик шулар турында.
Каршы алыр укытучы,
Каршылар классташлар.
Көмеш авазлы кыңгырау
Тәүге дәресне башлар.
Гел елмаер безгә кояш,
Баш тыгып тәрәзәдән.
Китәрбез белем иленә —
Таныш түгел эзләрдән.

*

## УРМАНДА

Җәйге урман — гөлләр иле,
Чәчәкләр патшалыгы.
Кызыл җиләк булып пешә
Урманның һәр шатлыгы.
Усал булсаң, ул да усал:
Һәрбер ботагы — камчы.
Ә дус булсаң, кочак ача
Урманның һәр агачы.

*

## ТУГАН ЯГЫМ

Ашкын җилләр юлга дәшә,
Ялы тузгый колынның.
Тал кызлары, ярга ятып,
Юа яшел толымын.
«Хуш киләсез!» — дигән кебек,
Тиен җиргә сикерә.
...Мин бәхетле, туган ягым,
Сине сөйгәнгә күрә.

*

## КОШЛАР КАЙТА

Яшьле күзен мөлдерәтеп,
Кыш карап тора.
Уйный-көлә язлар килә
Кош канатында.
Бар тереклек кулын суза
Кояшка таба.
Җир әйләнә яшел кошка, —
Җир канатлана.

*

## ЯРАТА ИКӘН ӘНИ

Әниләр уйлый һәрвакыт,
Балам яхшы булсын, дип.
Ничек яхшы булырга соң? —
Йөрим әле ымсынып.
Акыллы бул, яхшы укы,
Олыла икән дәүне.
Үз халкыңа дан китерсәң,
Ярата икән әни.

*

## ЯҢГЫРАСЫН БӨТЕН ИЛГӘ

Шөлдерләрен чылтыратып,
Инеш алга йөгерә.
Озатып кала чәчәкләр...
Инеш китә гомергә.
Шөлдер чыңын тыңлый кырлар,
Син дә чык басуларга!
Ватанга бир бар көчеңне
Йөрәктә ярсу барда.
Чыгып бас син буразнага,
Карама усал җилгә.
Шөлдер чыңыдай тавышың
Яңгырасын бөтен илгә.

*

## КЫШКЫ ЙОКЫ

Урман белән йөнтәс аю,
Күрәсең, игез балалар:
Озын кышны уздырырга
Бергә йокыга талалар.
Урман кышны төшендә дә
Аягүрә каршы ала.
Аю тын гына үрмәли
Җып-җылы өненә таба.
Көзге кояшның нурлары
Уйнаса да бакчаларда,
Ерганаклардагы сулар
Элеккечә аксалар да, —
Үз вакытын белеп, агачлар
Берәм-берәм яфрак коя.
Йокы алдыннан аю да
Ялкау гына иснәп куя.

*

## МАКСАТ

Җир гизәрсең,
Йөрәгеңдә саклап
Илгә биргән антың.
Кабызырсың
Домна мичләрендә,
Мартеннарда ялкын.
Зәңгәр күктә,
Гел үзенә дәшеп,
Якты йолдыз балкыр.
Ракеталар
Алып китәр сине —
Сызылып калыр ялкын.
Киләчәктә,
Түрдән урын биреп,
Данга күмәр халкың.
Күңелеңдә
Булса
Ил кабызган
Мәңге сүнмәс ялкын.

*

## МӘҢГЕЛЕК ЯЗ

Шатлыгыннан бүген апрель көлә,
Көлү тавышы — һәрбер инештә.
Карлар түгел, җирнең җаны эри —
Апрель аңа шундый килешкән!
Апрель белән килгән җырчы кошлар:
«Бигрәк матур сездә җәйләр!» — ди.
Тәүге кошны күргән малай кебек,
Зәңгәр күктә Кояш тәгәри.
Апрель белән җиргә шатлык килә,
Яз уяна һәрбер күңелдә.
Күзен ача агач бөреләре,
Чәчәкләргә илем күмелә.

*

## ГӨРЛӘВЕК

Язын кайда уйнасаң да,
Гөрләвек очрап тора.
Аяклар да әллә нишләп
Шул якка таба бора.
Ничә тапкыр вәгъдә бирдем,
Бүтән, дип, шапшак булмам.
Шапшак булмам,
Гөрләвекне
Алсагыз әгәр юлдан.

*

## БЕЗНЕҢ ДИҢГЕЗ

Эштән кайткач,
Әти әйткән:
«Каян килде
Бу диңгез?
Моңа кадәр

Коры җирдә
Тора иде
Өебез.
Су эчендә
Өстәл, диван,
Зур шкаф утрау кебек.
Монда давыл
Булган, ахры,
Бөтен җирдә
Ак күбек».
Әни күп уйлап тормаган,
Елмаеп болай дигән:
«Диңгез түгел,
Бу, әтисе,
Кызыбыз
Юган идән».

*

## ҮПКӘЛӘГӘН

— Ник елыйсың,
Әйтче, Алмаз?
Күп еласаң,
Яшең калмас.
Күрсә, көләр
Кешеләр дә, —
Әниең бит
Күршеләрдә.
— Бәләкәй дип
Алдадылар,
Кунакка да
Алмадылар.
Зурмы әллә
Безнең өстәл?
Тулмагандыр
Әле өч тә.
Урындык та
Шунда китте.
Аңа әле
Бары ике...
Калды бары
Иске диван.
...Безнең күрше
Кунак җыйган.
Әнкәй әйтте:
«Аны дәшмик...»
Юкса миңа
Алты яшь бит.

*

## МИНЕМ СЕҢЛЕМ

Аша, дисәң, ашамый,
Кашыгын атып бәрә.
Ачулансаң, тыңламый,
Тагын елап җибәрә.
Утыр, дисәң, утырмый,
Эшлә, дисәң, эшләми,

Урын җыймый, бит юмый,
Чистартмый ул тешләрен.
Ләкин аның турында
Чыгара күрмә гайбәт.
Көндез генә начар ул,
Йоклаганда бик әйбәт.

*

## КОЯШ КЕБЕК

Тышта суык,
Яңгыр ява.
Бабай әйтә:
«Начар һава».
Күктә Ай да,
Йолдыз да юк.
Барыбызның
Күңел боек.
Сеңелем дә
Йөзен чытты.
Шулчак кинәт
Кояш чыкты.
Әниебез
Кайтты көлеп.
Аның йөзе
Кояш кебек.

*

## КУРЫКМЫЙМ

Сыртына капчыклап
Маймыллар төягән, —
Шулай да барыбер
Курыкмыйм дөядән.
Курыкмыйм жирафтан,
Курыкмыйм филләрдән.
Фил борын күтәрсә,
Мин көлеп җибәрәм.
Әнием шаярта:
«Әгәр, — ди, — карышсаң,
Тотар да йотар, — ди, —
Менә бу арыслан».
Тамчы да курыкмыйм!
Әйтегез, кем курка?
Бергәләп барырбыз
Иртәгә циркка.

*

## ТЕГЕРМӘН

Әбинең туган көненә
Бүләк иттек тегермән.
«Хәзер кофе тарттырырга
Кибеткә барып йөрмәм, —
Дип сөенә әбиебез, —
Мәшәкатьтән котылдым».
Әби күршегә кергәч,
Тегермәнгә тотындым.

Әй тарттырам чикләвекне
Кабыгы-ние белән.
Әйләнеп тора тегермән,
Мин шатлыгымнан көләм.
Тарттырдым мин бәрәңге дә,
Тарттырдым кишер, кыяр.
Мин тарттырган нәрсәләрне
Ашаса, фил дә туяр.
Тарттырдым мин борыч, суган,
Тарттырдым мин алманы.
Өебездә тарттырмаган
Бер нәрсә дә калмады.
— Син тарттыңмы? — диеп, әби,
Аһ-уһ килде, шаккаты...
...Әйе, әйе, үзем тарттым,
Колакны әби тартты.

*

## ТӘРБИЯЛЕ МАЛАЙ

Урам буйлап сыер кайта,
Юаш та кебек үзе...
Сыер усал булмаса да,
Усал кебек мөгезе.
Әй ашыга, му да му, ди,
Әйтә бугай: «Сөтем му-ул.
Кемнең сөт эчәсе килә —
Тизрәк бирсен миңа юл».
Юл бирмәсәң, уйлап тормас, —
Ай-һай очлы мөгезе.
Юлны иңләп сыер кайта,
Юаш та кебек үзе.
Сөте тәмле, мае тәмле,
Тел йотарлык каймагы.
Мөгезеннән куркып, Азат
Менде-китте коймага.
Кызлар көлде.
Ул кычкырды:
«Мин куркак түгел алай.
Мин бит сыерга юл бирдем,
Мин — тәрбияле малай».

*

## ТИЗРӘК КИЛ

Тизрәк кил безгә, җылы яз,
Тизрәк, тизрәк кил!
Куяннар туңып беткәндер,
Иссен җылы җил.
Урманда бит
Җылы өй дә,
Җылы мич тә юк.
Куяннарның әбиләре
Бәйләми оек.
Тизрәк кил безгә, җылы яз,
Тизрәк, тизрәк кил!
Чыпчыкларга җырлар өйрәт,
Уйна, сайра, көл.

Урманда бит
Пешермиләр
Түгәрәк калач.
Песнәкләрнең туннары юк,
Тамаклары ач.
Тизрәк кил безгә, җылы яз,
Тизрәк, тизрәк кил!
Балыкларны коткар берүк, —
Боз астында күл.
Чәчәкләр белән күмелсен
Без яшәгән ил.
Тизрәк кил безгә, җылы яз,
Тизрәк, тизрәк кил!

*

**ҖИЛ**

Җил шаяра, җил котыра,
Күгәрчен кебек гөрли, —
Орчык алып утыра да
Көн буе җебен эрли.
Кабасына болыт элгән,
Эрли дә эрли шуны.
Ак булсын, ди, пакь булсын, ди,
Кыш бабасының туны.

*

**КЫСЛА**

Безнең буа кысласы
Күлмәк тегү остасы.
Бар балыклар шуңа йөри, —
Оста инде, кыскасы.
Балыкларның күлмәге
Көмештән дә алтыннан.
Миңа шундый күлмәк тек, дип,
Күпме йөрдем артыннан.
Күчмәс микән ательега,
Әллә инде кыстасы?
Балыкларны ташлап китмәс —
Ул бит буа кысласы.

*

**МИНЕКЕ**

Кычкыралар, сугышалар —
Әйтерсең мәхшәр купты.
Ике малай бүлә алмый
Түп-түгәрәк бер тупны.
Берсе әйтә: «Минеке!» — ди,
Икенчесе: «Минеке!»
Шулай тарткалаша торгач,
Ярты көннәре үтте.
Әтиләре чыккан иде —
Әтәчлекләре очты.
«Минеке» дә «минеке» дип,
Тарталар хәзер пычкы.

*

## САЕСКАН

Саесканның күлмәгендә
Туксан тугыз ямаулык.
Саескан кунак чакырган —
Менә сезгә яңалык.
Сүз белән сыйлап чыгарды —
Утырдык без ис китеп...
Менә сиңа — яңалык...
Нинди яңалык булсын бу? —
Бу бит чеп-чи искелек.

*

## ӨЧ РӘСЕМ

Кулга буяу алдым да
Кәгазь куйдым алдыма.
Ясадым мин сары баш,
Юк, баш түгел лә — кояш.
Урап алды кояшны
Чәчәк-үлән, кош-кортлар,
Үсеп чыкты урманнар,
Үсеп чыкты зур йортлар.
Кулга буяу алдым да
Кәгазь куйдым алдыма.
Ясадым алтын кояш,
Кояш түгел лә, ул — баш.
Ясадым аннан күзләр,
Ике кул, авыз-борын.
Ясап куйдым комбайн,
Ясадым басу-кырын.
Аны күрү белән үк
Урап алды кешеләр,
Күбәләкләр, тургайлар,
Таудай биек көшелләр.
Кулга буяу алдым да
Кәгазь куйдым алдыма.
Ясадым тау. (Тау түгел,
Кырын ятучы ялкау.)
Кояш инде көлмәде,
Беркем якын килмәде.

*

## ПЕСИ ТӨШ КҮРГӘН

Мич башында йоклаганда,
Песи гаҗәп төш күргән.
Төшендә ул Африкада
Арыслан булып йөргән.
Теләсә кемнең өенә
Шакымый гына кергән.
Кемгә керсә дә, урынны
Биргәннәр аңа түрдән.
Арыслан караватында
Кичен йокларга яткан.
Төшендә ул мич башына
Кире әйләнеп кайткан.
Шул чагында песиебез
Куркып уянып киткән.

Песиме ул, арысланмы —
Әле дә белми икән.

*

## ХАТ

Күрше малае Әхәт
Язган миңа шундый хат:
«Җиләттем, — дип, — абзарны,
Карап кайттым базарны,
Су буена алып төштем
Үрдәкләрне, казларны».
Их, Әхәт, Әхәт, Әхәт,
Яшисеңдер син рәхәт.
Шушындый хат яза диме
Малай кеше кызларга?
Миңа түгел, син бу хатны
Яздың мәллә казларга?

*

## СӘГАТЬ

Яз аеның бар серләрен
Тамчылар гына белә.
Бал кортларыниләр сөйли? —
Сорармын әле гөлдән.
Ни әйтергә тели икән? —
Чишмә көн-төн чылтырый.
Чишмә, ахры, кешеләргә
Бәхетле язмыш юрый.
Их, беләсем килә минем
Урманның ни уйлавын.
Җитмеш ел гомер юрады
Күке тавышы тагын.
Җитмеш ел! — Минем киләчәк
Гомерем шундый озын!
Димәк, җитмеш җәй, кыш һәм көз,
Димәк, бар җитмеш язым.
Вакыт әйтте: «Гомер узар,
Көннәр бит тормый туктап».
Ашык, ашык!
Вакыт сүзен
Кабатлый сәгать:
— Тик-так.

*

## КАРГА БЕЛӘН КӘҖӘ

*(Мәсәл)*

Шулай көннәрдән бер көн
Әтәч кураен тарткач,
Кызарып кояш баткач,
Авыл йокларга яткач,
Безнең ишегалдына
Бер әмер килеп җиткән —
Җирдәге бар җан иясе
Укырга тиеш икән:
Бәтиләр дә,

Әтиләр дә,
Җәйрәннәр дә,
Сыерлар да,
Сарыклар да,
Симезләр һәм
Арыклар да,
Мөгезлеләр,
Мөгезсезләр,
Бәләкәй һәм
Зур күзлеләр,
Канатсызлар,
Канатлылар, —
Бөтенесе
Тезелешеп,
Әй атлыйлар,
Әй атлыйлар,
Эчтән генә
Кабатлыйлар,
Уйнамыйлар,
Тик ятмыйлар,
Ятлыйлар да
Гел ятлыйлар.

Иң акыллы кош Карга,
Җыелып беткәч бар да,
Рәт-рәт итеп бер-бер артлы
Утыртып куйган карга.
Сыер тотынган күшәргә,
Бозау бозны яларга,
Ә бәрәннәр дер калтырый —
Суык икән аларга.

Укытучы — Ала карга
Кычкыра бит:
— Кар да кар.
Мондый мәктәп,
Әйтегезче,
Тагын кайсы җирдә бар?
Бүгеннән сез буйсынасыз
Бары миңа — Каргага.
Әлифбаны белүчеләр
Бармы сезнең арада?
Сүзләрнең барын ятлагыз,
Минем арттан кабатлагыз:
— Ар-ар-ар,
Кар-кар-кар,
Тар-тар-тар, —
Мондый мәктәп,
Әйтегезче,
Тагын кайсы җирдә бар?
Тотынган болар ятларга,
Әлифбаны кабатларга:

— Кыт-кыт! — килә бер Тавык,
— Мә-мә! — ди Кара сарык,
— Иһа-һа! — ди Алаша.

Менә сиңа тамаша —
«Гъ»ны дөрес әйтмисең, дип,
Ата казлар талаша.

Кычкырып куйгач Карга,
Тынычланганнар бар да,

Куян кишер кимергән,
Мәче сөтне ялаган —
Дәрес шулай үтеп киткән,
Башлаганнар яңадан.

Карга дәшкән кабаттан:
— Кайсыгыз белә яттан.
Әйтегез минем арттан:
— Ар-ар-ар,
— Кар-кар-кар,
— Тар-тар-тар.
Укый-яза белә торган
Арагызда кем соң бар?
Бахбай чәчен тараган,
Маэмай җиргә караган.
Шул чагында, керт-керт басып,
Кәҗә чыккан арадан:
— Ми-и-ин! — диеп аваз салган,
Барчасы өнсез калган.

Әй сөенгән соң Карга
Телен аңлаучы барга.

Сөенгән Сыер-Сарык,
Үрдәк-Казлар һәм Колын, —
Аларга хәреф түгел,
Кирәк печәнле болын.

Шул көннән бирле менә,
Ялгышмыйча бер көн дә,
Карга — агач башында,
Кәҗә — аның каршында,
Хәрефләр кабатлыйлар,
Әлифбаны ятлыйлар:
— Ар-ар-ар.
— Кар-кар-кар.
— Тар-тар-тар...
— Мин-и-ин!
Укымышлылык ягыннан
Җирдә кем бар
Миңа тиң?
— Ми-ми-мин! Ми-ин! Ми-ин!

Әле хәзер дә Карга
Кәҗә белән чын әшнә.
Бары өч хәреф өйрәнгән —
Җитсә дә йөз ун яшькә.

Инде шактый сөйләдем,
Тукталып торыйк, ярый...

Кәҗә хәленә килгәндә...
Һаман сакаллы сабый.

*

## ӘТӘЧ

Йоклый әле бөтен кеше,
Тәмле-татлы төш күреп...
Безнең әтәч уянган да:
— Кикрикүк тә кикрикүк!
Койма өстенә кунган ул,
Бар көченә кычкыра.
Әйтерсең мине уята,
Әйтерсең зур эш кыра.
Кикрикүк, ди, тиз кир-рәк, ди,
Укуга, ди, соңлама,
Белми
Минем укыганны
Икенче сменада.

*

## МӘҖЛЕС

Әтәч коймага кунган,
Мәҗлес җыймакчы булган.
Утыра кунак көтеп,
Тәлинкәдә — бер бөртек.
Җыелганнар тавыклар,
Караганнар савытка.
Ә савытта — бер ярма.
Кикрикләре кабара.
Тавык явы башлана,
Әтәч алга ташлана.
Узып унбиш өтекне,
Чукып ала бөртекне.
Үзе шундый сөенә,
Җырлый «Сарман» көенә.
Тәлинкәсе бушын буш,
Тик чыкмады, ди, сугыш.

*

## ГӨЛҖИМЕШ

Яшел яфрак арасында
Ут төсле кызыл җимеш.
Иң беренче үзем күрдем —
Бу җимеш — минем өлеш.
Кулым гына сузган идем —
Тешләп алды гөлҗимеш.
Аны утыртучы гына
Өзәргә хаклы, имеш.
Бигрәк усал гөлҗимеш.

*

## МУЗЕЙДА ЯНГЫН

Яна музей Казан үзәгендә,
Яна таңда Дәүләт музее.
Яна кебек гүя бабам йорты,

Яна кебек минем үз өем.
Ут эчендә — энҗе, асылташлар,
Кулъязмалар, нәсел башыбыз...
Гасырларны салып җилкәләргә,
Подвалларга китап ташыйбыз.
Бу китаплар инде ничәнче кат
Исән чыккан яудан, янгыннан.
Гасырларның кара табы булып
Битләренә корым ягылган.
Тәрәзләрдән ургый кара төтен,
Шомга салып якын-тирәне.
Яна музей; әйтерсең лә яна
Халкыбызның соңгы кирмәне.
Үрли ялкын, гасырларга үрли,
Үткәннәрдән күчә бүгенгә.
Күчә ялкын ил һәм халыкларга,
Күчә ялкын безнең күңелгә.
Безнең тарих, ничә тапкыр янып,
Күтәрелгән көлдән, күмердән.
Патшалардан чыккан янгыннарны
Утка кереп, халык сүндергән.
Янәшәдә — Җәлил. Кул — богаулы,
Күзләрендә — халкым газабы,
Богауларны өзеп ташланыр күк...
Саклар өчен уттан Казанны.
...Янды музей. Ә без һаман исән.
Исән чыктык тагын янгыннан.
Подвалларда бүген безнең тарих...
Тарих биктә... Музей ябылган.

**ҮЗГӘРЕРГӘ!**

Җанны талкый һаман заман уе,
Төште инде сагыш йөзләремә...
Яшәп булмый элек яшәгәнчә, —
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә!
Яшәп булмый элек яшәгәнчә.
Таң шәфәгы минем күзләремдә.
Нур өстисем килә туар көнгә...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.
Нур өстисем килә туар көнгә,
Нур саласым килә сүзләремә.
Итәгемнән тарта үткән төннәр...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.
Итәгемнән тарта кара төннәр...
Ышаналмыйм кайчак түзәремә.
Яңа көнгә яңа кеше кирәк...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.
Яңа көнгә яңа кеше кирәк...
Басмак булам заман эзләренә.
Алдан бара әйдәп фидаилар...
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә.
Алдан бара әйдәп фидаилар.
Ияртерләр микән үзләренә?
Җанны талкый һаман заман уе:
Кирәк безгә, кирәк үзгәрергә!

*

## ЧИРАТ

Җиңү көне. Мин урамда йөрим,
Уйлап йөрим шигырь язарга.
Рифма эзләп шактый изалангач,
Кагыласы иттем базарга.
Кайный базар, гүя рейхстаг.
Түбәсендә — Җиңү байрагы.
...Ит чабучы, сабыр палач кебек,
Озак итеп балта кайрады.
Чапкан саен башлар оча тора,
Ит чабучы ярсып кизәнә.
Бу базарда сатып булыр кебек
Намусны да салып бизмәнгә.
Һәрнәрсәгә аның үз бәясе,
Исе китми шигырь-мазарга.
Ите — кыйммәт, ә баш — очсызрак...
Баш бәясе арзан базарда.
Кем чираты?
Базар палачының
Күтәрелә канлы балтасы...
Стенадан көлеп карап тора
Халыкларның үги атасы.
Аны күргәч, кинәт ирексездән
Әрнегәндәй булды муеным.
Ит чабучы. Чират. Тәгәри баш.
Ул елмаеп сыйпый мыегын.
Кем чираты?
Дәште салкын аваз,
Авыр аваз, гүя кургашын.
Күрдем кебек базар чиратында
Горур башын Фәтхи Бурнашның.
Кем чираты?
Мыек асларыннан
Саркып чыга зәһәр усаллык.
Диварларны җимермәкче булып,
Башын бәрә Шамил Усманов.
Кем чираты?
Дөньяларның бүген
Сугым базарына тиң чоры.
«Исән булса башлар, кайтырбыз!» — дип
Саубуллаша Кәрим Тинчурин.
Кем чираты?
Бар кешеләр өнсез:
Юк шаярган, көлгән, уфтанган.
Аваз килә: «Мә, партия, мине!» —
Соңгы бүләк аңа Туфаннан.
Кем чираты?
Оча миллион башлар...
Ил атасы гүя котырган...
Кем чираты?
...Күзләремне ачсам,
Базар чиратында мин торам.
Тирә-юньдә кабер салкынлыгы.
Мин ашыгып чыгам базардан.
Урамда — яз. Илдә — Җиңү язы!
Аермасын язмыш язлардан.

*

## АГЫЙДЕЛДӘ БОЗ КИТӘ

Уфа күрә, ул Тукайны күрә,
Күрә аны еллар үтәли.
Татар-башкорт бәгыренә үтеп,
Ишетелә Тукай ютәле.
Ил афәттә чакта, шагыйрь — корбан,
Ил чирләсә, шагыйрь ютәлли, —
Ачы язмыш гел шагыйрьгә насыйп...
Ник сайламый язмыш бүтәнне?!
Язлар аңа назлар китермәде, —
Бер кызны юк хәтта үпкәне...
Рәсәй буйлап Тукай җылы эзли,
Эзли Тукай... Ярты үпкәле.
Ул Уфага килә, белә чөнки
Гафурие анда көткәнне.
...Агыйделдә иңрәп бозлар китә, —
Әйтерсең лә Тукай ютәлли.
Язларны ул бездән алдан күрә,
Күрә Тукай еллар үтәли.
Татар-башкорт! Тукай-Гафуридай
Мәңгелеккә бергә үт әле!

*

# КАБУЛ ӨСТЕНДӘ ДАВЫЛ

*(Юлъязма)*

## 1. ЮЛ ДОГАСЫ

Белерсең бөтен уемны, —
Җанга бер генә кагыл.
Сагышларым юлга дәште...
Кабул кыл мине, Кабул!
Өч мең чакрым ераклыкта
Кабулдан безнең авыл.
Картлар теләк теләгәндә
Әйтәләр: «Булсын кабул!»
Озатканда егетләрне:
«Исән кайт, — диләр, — сау бул!»
Әниләрнең теләкләре
Булсачы мәңге кабул.
Кара шәлле хатыннарның
Өмете шушы, Кабул:
Син, илдәге генә түгел,
Җирдәге соңгы яу бул!
Авылымны иңләп узды
Кабулдан килгән давыл.
Безнең җаннар туганлашты...
Кабул кыл мине, Кабул!

*Мәскәү*
*«Ширәмәт-2» аэропорты*
*1985*

*

## 2. ТЫЙНАКЛЫК

Әфганстан — горур таулар иле...

Мин — Иделдән, иркен үзәннән.
Күзләремне ала алмый тордым
Ак пәрәнҗә япкан гүзәлдән.
Безнең кызлар хәзер ярымшәрә,
Шәрә йөрү бездә «дәрәҗә».
Каплый алмас безнең гөнаһларны,
Яшерә алмас бары пәрәнҗә.
Сезгә килгәч, калдым тыйнакланып,
Чистарды җан, уйлар үзгәрде.
Пәрәнҗәңнең бер почмагын гына
Күтәрсәңче, әфган гүзәле!
Башка берни кирәк түгел миңа,
Тик бер елмай, әгәр яраса...
Шәрә кызлар тыйнакланыр хәтта,
Күзләреңне сирпеп карасаң.
Серле булган саен арта икән
Гүзәллеге хатын-кызларның.
Еллар буе җуйган хисләремне
Монда табып, бүген кызардым.
Яхшыгамы, әллә ямангамы? —
Бер гасырда күпме үзгәрдек!
Пәрәнҗәсе сагындырмый аның...
Сагындыра тыйнак гүзәллек.
Йөрәк менә нигә каккан икән,
Менә нигә җаным сызлаган...
Күзләремне ала алмый тордым
Таулар кебек горур кызлардан.

*Кабул*
*1985 июнь*

## 3. ЙОЛДЫЗЛАР БЕЛӘН ЯНӘШӘ

*Хәрби очучы В.Гайнетдинов истәлегенә*

Елыйсы да килә бүген,
Килә күк көләсе дә...
Карап барам... ак чалмалы
Һиндекуш түбәсенә.
Соры таулар, ак кыялар...
Күңел сыктый яшелгә.
Әй, Һиндекуш, кочагыңда
Яманлыкны яшермә!
Хәнҗәр кебек очлы кыяң
Җан ярама кагыла.
Кыялар да иминлекне,
Хөрриятне сагына.
Янәшәмдә — ак болытлар...
Кара төс юк биектә.
Тик агармый кара кайгы
Ак болытка тиеп тә.
Биекләргә менгән саен,
Офык ягы яктыра.
Очам кебек йолдызларга
Хыялым канатында.
Сүнәр тиздән ай-йолдызлар,
Төн үтәр, сагыш узар.
...Кабыныр шулчак күңелдә
Зираттагы йолдызлар.

*Әфганстан күге,*

*хәрби самолет*
*1985*

## 4. БАТЫРЛЫККА МӘДХИЯ

Ил кайгысы урам иңләп йөри...
Ничек каласың, дип, бер читтә?
Әфган генералын озатканда,
Җыелышып бардык мәчеткә.
Без — Алласыз. Тик имансыз түгел, —
Изгелеккә күңел ышана.
...Карт генерал, солых тәкъдим итеп,
Берьялгызы барган дошманга.
Башын иеп яшь солдатлар кергәч,
Ил кайгысын салып иңнәргә,
Мәчет халкы кинәт өнсез калды,
Аваз чыкты охшап иңрәүгә.
Баш очына басты ил картлары,
Орденнары — яшел мендәрдә...
«Аның җаны әзер иде һәрчак
Халкы өчен күккә менәргә».
Ясин чыккач, мәрхүм генералны
Күтәрделәр тагын иңнәргә.
...Уртак кайгы берләштерде безне,
Уртак хыял тиеш җиңәргә!
Кайгыларны кысып учларына
Таралдылар мәчет картлары...
Генералның «башсыз батырлыгы»
Алар белән бергә атлады.
Басып калдым мәчет почмагында...
Шикләнмәгез... Исән иманым.
Батырлыкның иман булуына,
Беренче кат күреп инандым.

*Кабул, 1985*

## 5. АДАШТЫМ МИН КАБУЛ УРАМЫНДА

Адаштым мин Кабул урамында...
Тел белмәгәч, дәшмим, сорамыйм.
Өмет өзеп, җан талкынган мәлдә,
Кемдер дәште: «Сәлам, шурави!»
Нәрсә өчен җирдә яшибез соң?
Нәрсә өчен җирдә туабыз?
Мең сорауга җавап бирде кебек
Кинәт яңгыраган бу аваз.
 Япь-яшь солдат нидер сөйли миңа,
Кабалана, ымлый, ашыга...
Һәм аннары... чәчәк кадап куя
Мылтык көпшәсенең башына.
Күрсәтә ул аннан ал кояшка,
Күрсәтә ул таулар ягына.
...Беләм, дустым, берсүзсез дә аңлыйм:
Тынычлыкны җаның сагына.
Юлны өйрәт. Адаштым мин бүген...
Мин генәме? — Илләр адаша.
Тамашачы булып калып булмый,
Җирдә барса сугыш-тамаша.
Кырык бердә киткән ирләр кайтмый,
Алар әле һаман яуларда...
Шул елларның ачы кайтавазы

Ишетелә сезнең тауларда.
Тәмуг сыман кайнар урамнарның
Баса-баса утлы ташына,
Солдат белән җитәкләшеп чыктык
Мин югалткан юлның башына.
Борылды да аннан китеп барды,
Кул болгады: «Сәлам, шурави!»
Кочагына алып кысты аны,
Йотты аны Кабул урамы.

Шул солдатның кырыс елмаюы
Төшләремә мең кат керәчәк.
...Баш очында яна уртак кояш,
Мылтык көпшәсендә — ал чәчәк.

*Кабул—Казан*
*1985—1988*

*

## 6. МИН ҖӘЛИЛНЕ УКЫДЫМ

Тау битендә, хәрби частьта...
Качкан чагы йокының.
Палаткада солдатларга
Мин Җәлилне укыдым.
Сөйләп бирдем язмышын да, —
Сүзгә-сүз дим, бәйләнсен.
Җирдә муллык арткан чакта,
Артсын шигырь бәясе!
Тирә-юнь тын. Шомлы тынлык,
Килми сүзсез ятасы.
Күктәге ай, әйтерсең лә,
Гильотина балтасы.
Укы, диләр, тагын укы,
Күңел моңга сусаган!
...Эчте алар таңга кадәр
Шигырь тулы тустаган.
Җәлил нинди булган? — диләр, —
Чын шагыйрьме? Усалмы?
...Нәрсә әйтим? Мин үзем дә
Бүген ачтым Мусаны.
Шагыйрьләрнең язмышлары
Уртак, ахры, күрәсең...
Моабитка охшаттым мин
Пули-Чархи төрмәсенз.
Ил буена шигырьләрнең
Төшкән чакта тиражы...
Шигырь укып таң аттырдык,
Өнемме бу, миражмы?

Бәясе арта шагыйрьнең
Афәт килгәндә илгә...
Солдат булып атакага
Барды бүген Җәлил дә.
Тау битендә, хәрби частьта
Укыдым мин Мусаны...
Шушы төнне минем өчен
Бар кеше намусланды.

*

## 7. СОЛДАТ ҖЫРЫ

«Ватан» сүзе аларда да
Бездәгечә «ватан» икән.
Мине уйлап, әнкәй һаман
Төн йокламый ята микән?
«Ватан» сүзе аларда да
Бездәгечә «ватан» икән.
Дошман нигә көне-төне
Туктамыйча ата икән?
«Ватан» сүзе аларда да
Бездәгечә «ватан» икән.
Мин юллаган сәламнәрне
Кошлар алып кайта микән?
«Ватан» сүзе аларда да
Бездәгечә «ватан» икән.
Мин кайтмасам, ватанымда
Аяз таңнар атар микән?

*Кабул*
*«Ариана» кунакханәсе, 1985*

*

***

Күздә моң, күңелдә торгынлык,
Җанымны тилмертә яманат.
Кайда син, кай кабер ташында
Бабамнар калдырган әманәт?!
Телләрен өйрәндем җилләрнең...
Җил безнең ботакны каерган.
Чыклардан сорадым, әйттеләр:
Болыттан сора син, яңгырдан.
Куерган болыттан сорадым —
Ул яшен телендә сөйләде.
Иң олы юаныч — киләчәк
Колакка пышылдый: «Түз, яме!»
Сораулар, өндәүләр эчендә
Юл тапмый тилмерәм, каңгырам.
Торам да урамга йөгерәм,
Зеңгелди башласа кыңгырау.
Безнең җыр басынкы, безнең чор —
Тарихның минутлык тынлыгы...
Чормада моңаеп тик ята
Бабамның җәясе һәм угы.
Каеннар аклыгын күрә дә
Хәтерем каядыр ашыга.
Нинди сүз, әманәт язылган
Бабамның кабере ташына?!

*

## УРМАН ҖЫРЫ

Башкортстан шагыйрьләре
Мостай Кәрим белән Муса Галигә

Мин — дөньяны, дөнья мине куып,
Алҗытылган, хәтсез арылган.

Сафка тезеп чыршы егетләрен,
Каршы алды мине карурман.

Сүз башласам, сискәнерләр сыман, —
Бар агачлар уйда оеган.
Кышкы урман илтә мәңгелеккә,
Юлларына йолдыз коелган.

Ак шәлләре җиргә шуып төшкән...
Ник каралган икән ак каен?
Язлар белән кайтмый калмас, диеп,
Ул сагына бугай Мостаен.

«Шыгырдавык агач озак яшәр...»
Искә алды кемдер Мусаны.
Кая барсам, милләттәшем кебек,
Каршы алды әрсез усагы.

Исән чыкты күпме давыллардан, —
Бу агачлар башын имәде...
Чөнки алар — Туфан наратлары,
Чөнки алар — Тукай имәне.

Безнең җырлар — кара урман җыры...
Бергә җырлап күпме барылган!
Иделләрдә, Уралларда шаулый
Кол Галидән калган карурман.

Шул урманны ташлап китәбез дә
Шул урманны сагынып кайтабыз.
Монда безне һәрбер агач аңлый,
Җавап бирә, күкрәп, кайтаваз.

...Бу дөньяның көйсез көен көйләп
Ялыктырган, хәтсез арылган.
Сал да мине ап-ак биләвеңә,
Бишек җырын җырла, карурман!

## ОЛЫЛАРГА БЕР СҮЗ

*Энекәш авызыннан*

Безнең күңел бик нык дыңгычланган,
Безне сүгеп күпләр тынычланган,
Безнең җанда — күпме кирәксез җыр!
Ә үзебез — һаман күңелле, җор;
Бер кайгысыз буын: шат һәм туклар,
Тик бездә дә бар бит яхшылыклар.
Күпләр әле безгә ышанмыйлар,
Ялгышалар, ләкин һич танмыйлар.
Алар — зурлар, кырыс күңеллеләр,
Алар сөенмиләр һәм көлмиләр,
Алар безне белми һәм күрмиләр,
Яр буенда тыныч, тик йөриләр.
Безнең күңел — яңа дөнья, иртәнге нур,
Анда ялгышлар да, табышлар да булыр.
Зурлар күрә бездә язгы ташу көчен...
Язын сулар гел болганчык була,
Көзен тынар, тоныкланыр өчен.

*

## АВЫЛГА КАЙТУ

Ашыктырып этә иңнәремнән
Туган якка буран.
Өянкеләр авыл башынача
Каршы чыгып торган.
Карт өянке, давылдандыр инде,
Каерылган, сынган.
Күтәрелеп килә алсу кояш, —
Җир йөрәге сыман.
Ал кояшка таба йөзне тотып,
Күпме юллар үттем!
...Дөньяда тик безнең авылдадыр
Ипи исле төтен.
Олы хисләр, олы омтылышның
Туган якта башы.
Шушы җирдә туган хыялларым
Шунда чынга ашты.
Туган авыл — соңгы станция...
Кайтам сине уйлап,
Ике рельс кебек ялтыраган
Чана юлы буйлап.

*

## МИҢА БҮГЕН КЫРЫК

Яшьлектә без күпме антлар эчтек,
Күпме хыял кордык!
Берәм-берәм таралышты дуслар,
Үз оясын корып.
Яшьлектә без шундый кыю идек, —
Әйтерсең бер йодрык.
Бер-беребезне танымыйча бүген...
Шаккатышып тордык.
Төшемдәме?.. Кемдер дәште миңа:
«Дусларыңнан курык!»
Дуслар кайда?.. Дошманнарым бүген
Кырыкмаса-кырык.
Берьялгызым калган чагымда да
Болгамадым койрык.
Күңелемә бары үзем хуҗа,
Үз теләгем — боерык.
Гомеремнең санау сәгатьләрен
Куйдым тагын борып.
Нишлисең бит? — Еллар агышының
Үз кырыгы кырык.
Бу дөньяда булыр кебек әле
Әллә ниләр кырып...
Басып торам гомер уртасында...
Тулды миңа кырык.

*

## ҖЫР БӘЙРӘМЕ, МОҢ БӘЙРӘМЕ БҮГЕН...

*Җырчы Вафирә Гыйззәтуллинага*

Мең тугыз йөз алтмыш бишнең көзе... —
Ул кич әле һаман хәтердә...
Илаһи йорт — Тукай клубында
Яшь кыз җырлый, җырлый Вафирә.
Бер кайгысыз идек әле генә, —

Сизми калдык күңел тулганны,
Сизми калдык шул кич моңлы җырга —
Вафирәгә гашыйк булганны.
Дөнья гаме бары моңлы җанда,
Моңлыларга бирсен чыдамлык.
Аның моңы таш бәгырьгә төшсә,
Ташны ярып шытып чыгарлык.
Килми бәхет елап чакырганда,
Килми ирек сыктап, зарланып...
Җыр авазы — азан авазыдай,
Биек аның изге мөнбәре.
Бүген аның моңлы туенда без, —
Сизми калдым күңел тулганын;
Сизми калды халык, ничәнче кат
Вафирәгә гашыйк булганын.
Җыр-бәйрәме, моң бәйрәме бүген, —
Бу кич калыр мәңге хәтердә.
Онытгырып бөтен кайгыларны
Бәхет җырын җырла, Вафирә!

*

## ҮЗЕБЕЗГӘ КАЙТАБЫЗ

*Нурихан Фәттахка*

Утыртмадылар түрләргә,
Чөймәделәр күкләргә...
Аның телле-тешле сүзе
Ошамады күпләргә.
Без гөр килеп кул чапканда,
Карап торды аптырап...
Шуңа бүген аның йөзе
Безнекеннән яктырак.
Без Казанда балкыганда,
Ул шәм якты Чыңгызда.
Без табындык — күкрәктәге,
Ул — күктәге йолдызга.
Ул барасы юл читендә
Маяклар кабынмаган.
Анда әле Болгар исән,
Казан да алынмаган.
Анда әле безнең тарих
Көл белән күмелмәгән.
Анда әле минем телем
Кырыкка бүленмәгән.
Тигез анда бар милләтләр,
Уртак анда киң җиһан...
Шушы хөррият илендә
Патша икән Нурихан.
Кем килмәде, кем китмәде,
Кем булмады атабыз?!
Менә бүген без яңадан
Хөр мәмләкәт ханлыгына —
Нуриханга кайтабыз!

## ТРАМВАЙДА

Дыңгыр-дыңгыр,
Шалтыр-шолтыр,
Шыгыр-шыгыр,

Шалт!
Трамвайга эләктек без,
Шуңа күңел шат.
Алдан:
— Һо-о-оп, әйдә!
Уртадан:
— О-о-ой!
Кочагыма сеңде иркәм,
Менә чыкты җай.
Моңа кадәр кыймый йөрдем,
«Әдәп сакладым».
Их, трамвай, оныттырдың
Андый чакларым.
Ике йөрәк залп бирә:
Дөп тә, дөп тә дөп.
Иреннәре пешкән чия,
Их, алсаң өзеп!
Дыңгыр-дыңгыр,
Шалтыр-шолтыр,
Шыгыр-шыгыр,
Шалт!
Трамвай дус, кешеләрне
Гел күп төяп чап!

*

***

Батырлыклар турында язар идем,
Батырлыклар турында...
Таулар түбәсенә менеп йөрсәм,
Диңгез төпләреннән энҗе җыеп,
Сөйгәнемә такыялар үрсәм,
Җәлил яткан төрмәләрне күрсәм...
Батырлыклар турында язар идем.

*

***

Шатлыкларны үлчәп буламыни
Фиалкалар көлеп торганда?..
Ләйсән яңгыр алдамыймы, диеп,
Елак болытлардан сорама.
Ромашкалар янып көнләсеннәр,
Ак розалар гайбәт сөйләсен...
Гел кояштан гына тормаса да,
Аны бит син иң нык сөясең.

*

## ФЕВРАЛЬ ЧӘЧӘКЛӘРЕ

Тагын килде февраль, тагын көлде —
Урамнарга тулды ак шатлык;
Гөлләр тезде февраль тәрәзләргә —
Ак бәсләрне гөлгә охшаттык.
Ни гаҗәп бу: февраль чәчәкләре
Китерә күк җиргә җәйләрне.
Өермәләр янда уйнаганда,

Ни гаҗәп бу: җанда — җәй гөле.

*

***

Диңгез буенда
баштанаяк суга чумган киемнәрен
ярга элеп киптергәндә
шаша-шаша көлгән кызый
койка башына эленгән гади чалбарга
башын куеп,
ярсый-ярсый елады.

*

## ЯШЬНӘП ЯШӘ!

*Сибгат ага Хәкимнең 70 еллыгына*

Әйт син менә, шигырьләрен аның
Йөрәгенә шифа итми, йә, кем?
Күңелләрне иҗат уты белән
Гел яктыртып тора Сибгат Хәким.
Җырларының телдән төшкәне юк,
Аларны үз итеп көйли һәркем.
Шулар аша халык йөрәгенә
Ачык тота юлны Сибгат Хәким.
Ишетмәсәк шигъри аһәңнәрен
Бер сөенеч калыр иде ятим.
Безнең өчен кече күңелле дә,
Олы җанлы дус та Сибгат Хәким.
Әсәрләре тормыш мәгънәсенә
Талпындырып яши безне һәр көн.
Шигъриятнең аксакалы, әмма
Шигырьләрдә гел яшь Сибгат Хәким.
Җиңел генә бирелмидер аңа
Иҗаттагы казанышлар, бәлкем...
Чигенмичә, әйдә җиңеп кенә
Яшьнәп гомер итсен Сибгат Хәким.

*

## МӘДХИЯ

*Шагыйрь Нури Арсланга*

Сырышмады сиңа вак шәхесләр,
Сырпалмады сиңа куштаннар.
Синең янда зур буласы килә —
Исемеңне белеп кушканнар.
Күреп тордык, урамнардан узсаң,
Чибәрләрнең күзе кызганны.
Дошман җиңалмаган Арсланны
Әсир итте Казан кызлары.
Күңелең киң — казакъ даласыдай,
Ил җилендә тузгый чәчләрең.
Татарстан — синең төп Ватаның,
Монда — урган, монда — чәчкәнең.
Ил явында булсын, җыр явында —
Чигенмәдең син бер карыш та.
Син — җиңүче бүген бар фронтта.
Йөзең нурлы, җаның — Арслан.

*

## КОЯШ

*Кояш Тимбиковага*

Нурлар сибеп чорга,
Моңнар салып җырга,
Без туганнан бирле
Кояш көн дә чыга.
Чыга гәҗитләрдә,
Чыга журналларда...
Чыгып китә юлга
Кара бураннарда.
Балкып керә Кояш
Авыл йортларына.
Аның нуры күчә
«Казан утлары»на.
Кайчак Кояш, ярсып,
Трибунага чыга:
Өтеп ала уты, —
Чыдый алсаң, чыда!
Авыр сүзләр аның
Күңелләрен телә...
Кайгыларын йотып,
Кояш бездән көлә.
Барып чыга Кояш
Җирнең читләренә,
Нурын сибә Кояш
Китап битләренә.
Яна күктә кояш,
Ә син тиң бит аңа!
Мәңге балкы җирдә,
Кояш Тимбикова!!!

## КАДЫЙ ЙӨРӘКЛӘРГӘ...

Арча кызларына мин һәрвакыт
Изге теләкләрдә,
Энәләре гүя күңгә түгел,
Кадый йөрәкләргә.
Күзләреннән тама кояш нуры,
Орчык — түшләрендә.
Шушы кызлар гомер буйларына
Керер төшләремә.

*

## ШАГЫЙРЬЛӘР МӘҢГЕ КАРТАЙМЫЙ...

*Шагыйрь Рәдиф Гатауллинның 50 еллык юбилеенда*
*сөйләгән шигъри нотык*

Шагыйрьләр күктән иңәдер...
Рәдиф Марстан* иңде...
Шагыйрьләр мәңге картаймый! —
Кем бирер аңа илле?!
Елаган чагын күрмәдем, —
Тешләрен кысып көлде...
Дошманнарын сынамадым...
Дуслары аның җилле.
Авыз эченә сыймаган
Кемнеңдер озын теле;

Дөньяга хәбәр тараткан:
Рәдифкә, имеш, илле.
Күңеле аның давыллы,
Шигыре — кайнар җилле,
Җырларына кызлар гашыйк, —
Кем бирсен аңа илле?
Шагыйрьләр була акыллы
Һәм була... бераз тиле...
Тиле булып була микән
Сәгатең сукса илле?
Алда — яулар, алда — көрәш,
Бирмәбез ятка билне.
Сакласак без шагыйрьләрне,
Саклarбыз туган телне.
Сөйләсәләр сөйләсеннәр:
Рәдифкә, диеп, илле...
Шул иллене бәйрәм итик
Гөрләтеп бөтен илне!

### ГАЙҖАН БАБАЙ КОТЛЫЙ...

*Шәйхи Маннурга 70 яшь тулу уңае белән*

Гайҗан бабай сөйли, һаман сөйли:
«Маннурга да 70 тулды, — ди.
Ут сиптереп йөргән егетем, әй,
Минем белән яшьтәш булдың, — ди.
Берзаманны Муса Җәлил белән
Йөргән идең тормыш юлында.
Хәзер менә көчкә күтәрерлек
«Муса» атлы роман кулыңда.
«Ат» дигәч тә... атым — колхоз малы,
Союзныкы — синең пегасың.
Без картларны оныткансың әллә? —
Әйләнәңә яшьләр җыйгансың...
Ай, усал да үзең. Сине күргәч,
Авторларның оча котлары.
Халтурщикка көн дә «мат» куйганга,
Исән-имин «Казан утлары».»
Гайҗан бабай кинәт тынып кала,
Агымсуга карап уйлана.
Күңелендә ташый изге теләк:
«Йөз ел яшәп, Маннур, туйма ла!»

*

### МИҢНУЛЛИН ТЕАТРЫ

*Драматург Туфан Миңнуллинга*
*60 яшь тулу уңае белән*

«Татар бетә», — дип, кемнәрдер
Астыртын хәйлә корды.
Халкыбызны саклап калды
Академ театры.
Телсезләргә тел бирде ул,
Уйсызны уйлаттырды;
Т.Миңнуллин яза торды,
Сәлимҗан куя торды.
Йоклаганны уяттырды,
Көлдерде, уйнаттырды
Г.Камал исемендәге

Миңнуллин театры.

*

## ҖИЛЛЕ ЧАК УЛ ИЛЛЕ

*50 яшен тутырган*
*Зиннур Бәшировка*

Бүген кояш җирне нурга күмеп,
Бер туйганчы көлде.
Ул да беләː нур иясе затка —
Зиннурга бит илле.

Якыннары, дус-ишләре бүген
Чәчәк тотып килде.
Ир-егетнең чөнки гайярь чагы,
Чәчәк чагы — илле.

Зиннур сыман нык иманлы затлар
Әйдәп бара илне.
Ир-егетнең мәйдан тотар чагы,
Батыр чагы — илле.

Өч баласы — өч өмете аның,
Язмышы да көйле.
Ир-егетнең җылы өйле чагы,
Көйле чагы — илле.

Дошман һәрчак янәшәдә йөри,
Бирә күрмә билне!
Дуска таян. Дошман кырык булса,
Дусларың бит илле.

Яши-яши акыл утыртсак та,
Гашыйк йөрәк тиле.
Тик гашыйклар гына картаймыйлар,
Тутырса да илле.

Зиннур — димәк, нурлы йөзле кеше,
Зиннур — тәмле телле.
Өйсезләрне өйле итә-итә
Тулган аңа илле.

Зиннур туган, янып яшә мәңге,
Сөендереп илне!
Ир-егетнең җир җимертер чагы,
Җилле чагы — илле!

## ЯШӘ, ӘНВӘР ХӘЙРИ!

*Галим Әнвәр Хәйригә*
*50 яшь тулу уңае белән*

Дус-дошманны төрле уйга салып,
Таралды бер хәбәр:
Илле яшен тутырган, ди, имеш,
Нәҗип улы Әнвәр.
Дус сөенә, дуслар бәйрәм итә,
Дошман гайбәт чәйни...
Барын белеп, барын күреп тора,
Көлеп тора Хәйри.
Халкым хәле исләремә төшсә,
Чымрап куя тәннәр...
Милләт йөген иңнәренә салып,
Иңрәп бара Әнвәр.

«Татарымның таңы атармы?» — дип,
Аның жаны әрни.
Дан арттырып, таң аттырып яши
Мәңге уяу Хәйри.
Татар бүген — җиде юл чатында, —
Шундый безнең хәлләр.
Җиде юлның иң җиллесен сайлап,
Туры бара Әнвәр.
Кайгы качкан. Безнең шатлык бүген
Диңгез булып җәйри.
Илне-җирне, безне сөендереп
Яшә, Әнвәр Хәйри!

*

## БЕРДӘНБЕР

*Күренекле сәясәтче һәм дәүләт эшлеклесе*
*Фәрит Мөхәммәтшинга 50 яшь тулу*
*мөнәсәбәте илә*

Исемеңне мулла дөрес кушкан, —
Язмышыңны алдан белгәндер:
Гарәп сүзе — Фәрит, татарчасы —
«Һич тиңдәшсез» була, «Бердәнбер».

Әтиең дә бишек көйләгәндер,
Әниең дә назлап сөйгәндер.
Алар өчен син бит мәңге бала,
Алар өчен син бит Бердәнбер.

Кара чәчле нефть малаеның
Катлам-катлам уе тирәндер.
Мең катламлы бу катмарлы җирдә
Син сайлаган язмыш — Бердәнбер.

Бик елыйсы килгән чагыңда да
Елмаясың һәрчак кемгәдер...
Кеше өчен мең шатлыгың булса,
Үз хәсрәтең яшерен — Бердәнбер.

Гөнаһыңны эзләп, мең кат күзләп,
Көндәшләрең сынап йөргәндер.
Син көләсең, чөнки син беләсең:
Дөнья — фани, гомер — Бердәнбер.

Бу дөньялар һәрчак болай булмас,
Тормышлар да әле көйләнер.
Берәү китә, берәү килә торыр,
Ватан калыр. Ватан — Бердәнбер.

Ватан белән бергә халык калыр,
Ил язмышы мәңгә төрләнер...
Халык өчен син Бердәнбер булсаң,
Ул да сиңа газиз, Бердәнбер.

Еллар узар. Безнең бу көннәрне
Тарихчылар мең кат өйрәнер.
Тарих өчен олы түрә булсаң,
Безнең өчен, син бит, Бердәнбер!

## ЙӨЗ ЯШӘ!

*60 яшен тутырган*
*Мөҗип әфәнде Низамиевка*

Туган җирен аның сорасагыз, —
Ул атаклы Сарман ягыннан.
Сафлык алган Сарман суларыннан,
Сарманда ул канат кагынган.
Туган халкын аның сорасагыз, —
Татарның да чып-чын татары.
Телен бутап сөйләп йөргәннәрне
Ул милләткә кире кайтарды.
Кайтарды ул җыйган хәзинәне,
Чакырды ул һәрчак иманга...
Ул вакытны ашыктырып яши,
Ул таң белән бергә уяна.
Гомер буе кеше өзелмәде
Ул утырган нурлы бүлмәдән...
Арабызда бармы берәр кеше
Киңәш сорап аңа килмәгән?!
Китапханә саен кереп йөри,
Барып керә төнлә клубка...
Бураннарда юлга чыгып китә,
Төренә дә җылы толыпка.
«Җырлы булсын халык, моңлы булсын
Һәм яшәсен илдә гөрләшеп...»
Шундый уйлар белән яна-көя
Җан җылысын йөри өләшеп.
Күңеленнән бүген һәммәбез дә
Аны котлый, аңа эндәшә...
Мәдәният иңгән халкың белән
Мөҗип агай, җирдә йөз яшә!

## ЯКТЫ ЙӨЗЛЕ МӨНИРГӘ

*50 яше тулган көнне әйтелгән сүз*

Илле ел «ИЛ» дип яшәгән
Ирнең урыны түрдә...
Кем сокланмый якты йөзле,
Татлы сүзле Мөниргә*?!
Тау-ташларны кичә-кичә
Үрмәли һаман үргә.
Дошман көеп, дуслар сөеп
Карап тора Мөниргә.
«Атказанган» исеме бар, —
Бирсә бирә Мөниргә!..
Әүлиядай Сәүдиясе, —
Кавышканнар гомергә.
Канатлы булып туган ул, —
Аягы тими җиргә.
Мин дә кайтам канатланып
Килгән саен Мөниргә.
Чыккансың икән мәйданга,
Дошманга биләң бирмә.
Сабантуй батырлары да
Сокланадыр Мөниргә.
Җирдә күпме ир-ат күрдем...
Җитәме соң Мөниргә?!
Алыштырмыйм бер Мөнирне
Мең егеткә, мең иргә!

*

## ӘЙДИ БЕЗНЕ АЙРАТ

*Мәшһүр сүз остасы*
*Айрат Арслановка багышлыйм*

Ул Ходайга якыная бара
Еллап түгел, айлап...
Телсезләргә тел иңдерер өчен,
Җиргә иңгән Айрат.
Берәү яши, безгә пычак кайрап,
Берәү яши сайрап.
Елата да, юата да безне
Былбыл телле Айрат.
Коллык йөге башны баскангамы? —
Хәтеребез саерак.
Кол Галинең кылган гамәлләрен
Сөйли безгә Айрат.
Мәгънәле сүз моңлы, көйле була,
Әйтелә ул җайлап.
Өзелгәндер татар бәгыреннән
Моңлы бала — Айрат.
Алга дәшсен безне иманлы сүз,
Шигырь булсын байрак!
Шигырь-байрак тотып, мәңгелеккә
Әйди безне Айрат.
Ходай аны безгә бүләк иткән
Миллионнардан сайлап.
Халкым булмас, Илһам җырламаса,
Сөйләмәсә — Айрат.

*

## ТҮЗСЕН ГЕНӘ ЙӨРӘК

*70 яшьлек юбилей көнендә мәшһүр артист*
*Шәүкәт Биктимеров авызыннан әйтелгән сүзләр*

Йола куша: туган көндә һәрчак
Зурлау, мактау кирәк.
Мактый дуслар, мактый хәтта хатын, —
Түзсен генә йөрәк!

Кул сузардай дуслар сирәк булды,
Ишелгәндә ярлар.
Яңгыр булып күктән таш яуганда,
Кайда иде алар?

Ярылмыйча ничек түзгән икән
Йодрык хәтле йөрәк?! —
Олау-олау ачы хәсрәтләрне
Барган чакта сөйрәп...

Ышанмассыз, ил болгавыр чакта:
«Мин бәхетле!» — дисәм.
Уйнап түгел, уйлап яшәгәнгә
Безнең башлар исән!

Кемнәргәдер артык зат булсак та,
Без гавамгә кирәк.
«Алтын» диеп түгел, «халкым» диеп
Типте безнең йөрәк.

Акты еллар: язны, җәйне уздык,
Инде көзләр җиткән.
Артка карап, олавымны барлыйм, —

Уңыш мулдан микән?

Мин Ленин да, Әлмәндәр дә булдым,
Булдым һәрчак үзем...
Әлмәндәрле халык мәңге яшәр, —
Бирсен Ходай түзем.
Егылмадык, югалмадык илдә —
Без һәрвакыт кирәк!
Халык безгә терәк булган кебек,
Без — халыкка терәк.
Чәчләргә дә көл төсләре кунган, —
Яндык бугай артык...
Янсак яныйк, азаккача барыйк
Ил арбасын тартып!

*

## УЗА ГОМЕР, УЗА

*Язучы һәм мөхәррир Роза Хафизовага*
*70 яшь тулу уңае белән*

Көннәр түгел, еллар гына түгел, —
Безнең гомер уза...
Гомеремнең ун елына хуҗа
Роза Хафизова.
Мин — «Ялкын»да, мин мәкалә язам.
Ул — мөхәррир, сыза.
Сызса сызды, тик бозмады безне
Роза Хафизова.
Без — авылдан, без давылдан чыккан, —
Бакма кайсыбызга!
Бер «Ялкын»га, бер салкынга салды
Роза Хафизова.
Ун ел буе шул «Ялкын»да янып
Әверелдем кузга.
Таяк тыгып, кузны бутап торды
Роза Хафизова.
Хәтеремдә үткәннәрне барлыйм,
Җырлар суза-суза.
Ун ел өчен ун мең рәхмәт Сезгә,
Роза апа, Роза Сәет кызы,
Роза Хафизова!

*

## ҮЗ ТУКСАНЫ ТУКСАН

*Әмирхан ага Еникигә 90 яшь*
*тулу уңае белән*

Әмирләр һәм ханнар килә тора,
Тик Әмирхан бирми орып та...
Үз дәүләте — Дәүләкәне булды,
Үз кырыгы булды кырыкта.
Ил кайгысы — ирләр җилкәсендә...
Гамьсезләргә яшәү җиңел лә.
Ил кайгысын артык күтәргәнгә
Олпатланды иртә — илледә.
Иман сатып күпләр көн күргәндә,
Ул чыкмады юлдан карыш та...
Юлсызларга юл күрсәтеп барды,
Ил маягы булды алтмышта.

Ашыкканнар йөз кат ашка пеште,
Ул ашыкмый, әмма җитешә...
Мәҗнүн кебек мәхәббәттә янып,
Хатирәләр язды җитмештә.
Бәхетсезгә бәхет килми икән,
Сабыр гына күпме көтсәң дә...
Ир бәхете ил бәхете белән
Йөргәнлеген күрде сиксәндә.
Ул халыкта, ул тарихта калыр,
Чор сәгате мең кат сукса да!
Үзем, дими: «Милләт яшәсен!» — ди, —
Үз туксаны аның туксанда.
Әмирләр һәм ханнар килә, китә,
Ул читтәрәк тора гел көлеп.
Көлә-көлә йөз яшенә керә,
Ул — Әмирхан, ул бит мәңгелек!

## МӘКТӘП БУЛСА, МИЛЛӘТ ЯШИ

*Мамадыш-Әкил мәктәбенең*
*80 еллыгында укылган шигырь*

Хәбәр җитте Казаннарга:
«Бәйрәмгә, — дип, — кил!»
Колач җәеп каршы алды
Мамадыш-Әкил.
Сиксән яшь тулган мәктәпкә, —
Уйна, җырла, көл!
Сабан туе кебек гөрли
Мамадыш-Әкил.
Мәктәп булса, милләт яши,
Яши туган тел.
Телле дә ул, динле дә ул
Мамадыш-Әкил.
Киләчәккә барыйм дисәң,
Тарихыңны бел.
Үткәннәрен барлый бүген
Мамадыш-Әкил.
Мәктәпсез авыл бик ямьсез,
Шыксыз һәм ятим...
Мәктәп яшәгәндә, яшәр
Мамадыш-Әкил.

*

## БЕР КАЙТЫРМЫН ӘЛЕ...

*Сибгат Хәким истәлегенә*

Кытлык булмас җирдә шагыйрьләргә,
Туу белән үлем булган чакта.
Чәч агаргач шигырь язып кара...
Һәркем шагыйрь юләр балачакта.
Еллар йөге баскач иңнәреңә
Очып кара хыял канатында.
Гомер буе җыйган байлыгыңны
Син чәчәргә тиеш, таратырга.
Ай-кояшка тиңдәй Тукай барда,
Туфан барда шагыйрь булып кара...
Охшатам мин моңлы язмышымны
Кояш нуры иңгән болытларга.
Гашыйк идем язгы бураннарга,

Гашыйк идем җәйге рәшәләргә.
Исемемне онытмаслар әле
Гашыйк җаннар җирдә яшәгәндә.
Мин киткәч тә дөнья матур булыр.
Моңсуланыр Аккош күле генә...
Аккош булып бер кайтырмын әле,
Ышанмагыз минем үлемемә.

*

## ҖИДЕГӘН

*Түбән Кама шәһәрендә мәшһүр «Җидегән чишмә» берләшмәсен оештырган каһарман якташларыма*

Аваз килә ерак-ераклардан,
Җан авазы, —
Чорлар дәшәме?
Атом бүлгән чорда фида җаннар
Ил кайгысын бүлеп яшәде.
«Милләт» диеп утка керде алар,
Ә кемнәрдер кабер казышты...
Химкомбинат «Яәҗүҗ-Мәәҗүҗедәй»
Ут эчендә татар язмышы.
Офыкларны баскан кара төтен
Бер таралыр микән җил белән?
Халыклар һәм илләр адашканда
Маяк булды безгә «Җидегән».
Бүлгәләнде кавем, илләр, җирләр,
Бүленми тик патша тәхете...
Безнең хыял — тәхет яулау түгел,
Безнең хыял — халык бәхете.
Бәхет эзләп халкым җирләр гизгән,
Татар һәрчак төпкә җигелгән.
Җиңелгәнне алдап була икән
Орден-медаль, тәти җим белән...
Җиде юлны кушкан Җидегән бу —
Күпме язмыш монда кавышкан!
Тетри заллар, тетри мәгърур җаннар
«Без мәңгелек!» дигән тавыштан.
Без — мәңгелек, бары бергә булсак,
Без — мәңгелек туган җир белән.
Ялгыз чакта нәни чишмәдәй без,
Бергә чакта — көчле «Җидегән».

## БЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ

*Халкыбызның күренекле улы Тәлгат Абдуллинга*

Ир язмышы — ил язмышы, диләр...
Бәхет эзләп ерак барылган.
Елатты да, юатты да безне,
Кочагына алып Маргилан.

Татлы язмыш түгел мөһаҗирлек,
Еллар безне кат-кат сынады.
Кичләр җитсә, моңсуланды эти,
Телләрендә — Тимер*, Туймазы.

Себерләрдә уелдымы икән
Әниемнең маңгай сырлары?..
Себердә дә, үзбәк җирендә дә

Ул «Чирмешән»**, диеп җырлады.

Күпме татар, чит җирләргә китеп,
Тирләр түккән, даннар казанган!..
Канатлары канап, каерылса да,
Аерылмаган җаны Казаннан.

Безнең кыйбла гел Ватанда булды,
Яшәсәк тә әллә кайларда.
Татар булып пешеп җитәр өчен
Казаннарда кирәк кайнарга.

Милли мәҗлес — туй мәҗлесе түгел,
Булдык анда тәкъдир язганга...
Ауган дәүләт белән тузган торак
Каршы алды чөнки Казанда.

Адашмадык язмыш юлларында,
Давылларда сынып аумадык.
Без яңадан илле, җирле булдык,
Без Казанны кабат яуладык.

Ир бәхете — ил бәхете белән,
Бәхет түгел патша тәхете...
Мин дусларым, туганнарым белән,
Туган халкым белән бәхетле!

## ТАТФАК БАРДА ҖИРДӘ ТАТАР БАР

*Татфакның 50 еллыгына*

Без тарихлы, телле халык диеп,
Горурланып бүген әйттеләр!
Татар барда җирдә — хәтәр булса,
Татфак барда — илдә хәтер бар!
Тарих безне йөз мәртәбә изеп,
Мең мәртәбә бозып бутады.
Кара төндә йолдыз булып янды
Татфак белән татар китабы.
Бәйрәм итә бүген татар иле,
Күркәм бүген бәйрәм табының...
Син — бишеге ана телебезнең,
Син — төп йорты татар аңының.
Җитәр вакыт: дарелфөнүн йортын
Татар исме белән атарлар...
Беләм чөнки: татар барда — хәтәр,
Татфак барда җирдә татар бар.

*

## ЙОЛДЫЗ БУЛЫП ТУГАНСЫҢ

*Җырчы Венера Ганиевага*

Син, Венера, туганда ук
Йолдыз булып тугансың.
«Йолдыз чире» йокмый сиңа,
Сау-сәламәт шуңа син.

Бирешмәдең мактауга да,
Сине дан да бозмады.
Синең җырны тыңлаганда
Сизмим гомер узганны.

Рәхмәт сиңа! — Илһам бирден,

Моң бирдең язарыма.
Синең хакың — алтын хакы
Җырчылар базарында.

Баш иябез, табынабыз
Илаһи сәләтеңә.
Татар моңы салган өчен
Опера сәнгатенә.

Башыңдагы Җыр таҗыңның
Коелмасын укасы!
Яңа Венералар ачсын
«Йолдызлар фабрикасы»!

Бу дөньяда: «Мин йолдыз!» — дип,
Күпләр хыял коргандыр.
Әмма күктә «Разил» дигән
Йолдыз булмый торгандыр.

Кайчагында безне дә ул
Күккә чөя куштаннар.
Әмма йолдыз исемен бит
Сиңа гына кушканнар.

Без беләбез, күккә менеп,
Йолдыз булып булмасын...
Син бәхетле: туганда ук
Йолдыз булып тугансың.

## ИҢНӘРЕНДӘ АККОШ КАНАТЫ

*Халкыбызның аккош канатлы биючесе*
*Нинель Юлтыевага*

Дучар итеп була ятимлеккә,
Тик батырып булмый халыкны.
Ятимә кыз — нәни балерина
Сөембикә булып калыкты.
Аккош булып йөзде сәхнәләрдә,
Очып йөрде илдән илләргә —
Аны күргәч, мәгърур патшалар да
Мәҗбүр булды башын иярргә.
Биюче зат — кошлар нәселеннән,
Ул һәрвакыт оча биектә.
Ул безне дә зәңгәр күккә дәшә,
Күңелләрне безнең биетә.
Алиһә дип, фәрештә дип була
Күктән иңгән мондый талантны!
Җаны аның — Сөембикә рухлы,
Иңнәрендә Аккош канаты.

*

## ЯКТАШ

Бу дөньяның авыр нужасы да
Җиңел, бергә тарткач.
Авыр чакта шакымыйча кер син:
«Саумы, диеп, якташ!»
Егылганга кул суз, тартып торгыз,
Кагылганны яклаш.
Бер-береңә терәк булыр өчен

Кирәк һәрчак якташ.
Дошман күпме гайбәт сөйләсә дә,
Бер-береңне макташ:
«Безнең яктан яман кеше чыкмас,
Шәп кеше син, якташ!»
Бергә булыйк, үргә меник дисәң,
Бер-береңне саклаш.
Кайгыларны, шатлыкларны бүлеп,
Җырлап яшик, якташ!

*

**ЭПИГРАММАЛАР**

*Прозаик Азат Ганиев*
*белән сөйләшү*

— Яшисең кайда, Азат дус?
— Казан түгел, Әлмәттә.
— Язасыңмы соң, Азат дус?
— Язам, язам, әлбәттә.
— Ник соң бер дә басылмыйсың?
— Эш күп: йөрим кармакка.
— Романыңны урлатабыз
Әйтеп Шәкүр каракка.

*Язучы, актер һәм режиссер*
*Рабит Батуллага*

Театрлар гримыннан
Буялып калган мыек
Миңа һаман ирек бирми
Әдип дияргә, кыеп.

*Шагыйрь*
*Рөстәм Мингалимовка*

Кулымдагы балдагымның
Исемнәре гел Рөстәм.
Тагын поэма язармын,
Күрсәтмә булса өстән.

*Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты,*
*композитор Мирсәет Яруллинга*

Артыннан йөреп булмады —
Аек ара тар ие...
Юкса Тукай бүләгенә
Лаек оратория.

*Җырчы Рафаэль Сәхәбиевкә*

Синең турыда ни дип язарга соң?
«Тазаргансың, дустым, тазаргансың».

***

Кыяфәт — чын француз,
Тавышлары — итальян.
Буй-сынны ул Европадан,
Моңны татардан алган.

*Язучы Марсель Галиевкә*

Тыйнак булдык — күрмәделәр,
Усалландык — багалар.

Ышанмасаң, укып кара:
Шәп бит: «Карап багалар»,
Шәп бит: «Кара, багалар»,
Шәп бит: «Кара баганалар»...
Уф, үзем дә көчкә әйтәм:
Шәп бит: «Кар абагалар!»
*Шагыйрь Фәннур Сафинга*

Язам дисәң, кырларың бар,
Җырлыйм дисәң, җырың бар.
Тик син гел сөю җырлыйсың —
Әллә инде күңелең тар,
Әллә, чынлап, ярың бар?!
*Язучы һәм «Чаян» журналы хезмәткәре*
*Фаил Шәфигуллинга*

«Дөнья матур!» — Туймыйм күпме язып та, —
Мәкаләләр күп кирәк бит газетка.
Сорасалар бер хикәя «Чаян»га, —
Кыек эшне табабыз ул каян да.
*Рифкат Гомәревкә*

Без белмәгән җырларны да
«Саз» моңы яраттыра.
«Саз»га оркестр кирәкми, —
Баян да ярап тора:
Рифкат уйный, кызлар җырлый,
Егет-җилән дә тик тормый, —
Шаккатып карап тора.
*Вафирә Гыйззәтуллинага*

Гыйззәтуллинаның берсен
Кояшка тиң күргән Тукай.
Кояш булгач, ай да кирәк:
Кайда ул ай? —
Ай син бугай...
*Шагыйрь дуска*

Табыннарны онытып тор, —
Поэзиягә табын!
Табыннар сиңа табыныр
Чыккач шигырь китабың...
*Зилә Сөнгатуллинага*
Тукайлардан калган моңны
Сакладык без, өзмәдек...
Бәгырьләрне телә-телә
Җырлый Зилә-Зиләйлүк.
*Зөһрә Сәхәбиевага*
Ул җырласа, галәм өнсез калыр,
Зәңгәр күктән йолдыз коелыр.
Зөһрә булу Җирдә бәхеттер ул,
Йолдыз булу җырда кыендыр.
*Асаф Вәлиевкә*
Асаф кебек җырлап кара! —
Гайбәт сөйләү ансат ла...
Юккамы татар кызлары
Барсы гашыйк Асафка?!
*Зөфәр Билаловка*

Гаҗәеп шәп егет иде,
Гаҗәеп шәп җырчы иде.
Хәзер шәпләрнең дә шәбе:
Чөнки Ходай бүләк итеп
Аңа иң шәп җырчыбызны —
Зәйнәп-былбылны бирде.
*Газинур Фарукшинга*
Газинурлар батыр була,
Утка куя күкрәген...
Җырыңда син яшен булдың,
Күкләр булып күкрәдең, —
Моңнар тулы күкрәгең!
*Гали Ильясовка*

Мактанса татар кешесе,
Гали җырчысын атар...
«Ул, — дияр, — безнең Карузо, —
Татарский итальян,
Итальянский татар».
*Зөһрә Шәрифуллинага*

Күңелләргә моңнар иңсә,
Тар дөньялар була киң.
Ярый әле җирдә син бар, —
Син былбылга кемнәр тиң?!
*Хәйдәр Бигичевка*

Гасырлардан иңрәп аваз килә,
Җырлый күкрәп, җырлый тын гына...
Бәгырендә аның Тукай рухы,
Аның җаны тоташ моң гына.
*Венера Ганиевага*

Әллә инде челтер чишмә ага, —
Челтер-челтер моңнар түгелә.
Аның моңы чишмә булып коя
Җыр яраткан һәммә күңелгә.
*Айдар Фәйзрахмановка*

Юлдаш итеп якты җырлар алыйк, —
Безгә әле бик күп барасы...
Аның җырын тыңлап уйга калсам,
Басыладыр йөрәк ярасы.
*Зәйнәп Фәрхетдиновага*

Буй-сын, җыр-моң өләшкәндә
Оныткан безне Ходай.
Безгә дигән матурлыкны,
Безгә дигән бөтен моңны
Зәйнәпкә биргән бугай.
И-их!

*Рәшит Абдуллинга*

«Җыр» дигән кара урманга
Без бит бергәләп кердек.
«Төсле җыр» белән башладың,
Төссез җыр язма берүк!

*Лидия Әхмәтовага*

Бөгелә дә, сыгыла да
Тал чыбыклары сыман.
Тал бөресе кебек җанга
Күпме гүзәл моң сыйган!

*Рамил Миндиярга*

Казанымны уксыз-утсыз
Яулап алды Миндияр.
«Казанны мин яуламадым,
Яулады бит моң», — дияр
Өфе егете Миндияр.

*Резедә Әкбәровага*

Сәхнәләргә чыккан чакта,
Кояш балкый йөзендә.
Театрда уйнап җырлый,
Җырлап уйный Резедә.
*Галина Казанцевага*

Кагылмыйк без җырчыларга,
Җырчыны тарих таныр.
Галиналар бик күп түгел,
Без китәрбез, ул калыр,
Без китәрбез, җыр калыр.

*Равил Харисовка*

Шәп Равилләр шактый бездә,
Шәп Харислар җитәрлек.
Ул Равил дә, Харисов та, —
Шуңа исең китәрлек!

*Зиннур Нурмөхәммәтовка*

Биеп-җырлап җанга килеп керде,
Күңелләргә иңде моң нуры.
Зиннурларның җирдә иң зуры ул,
Иң зурларның — якын Зиннуры!

*Искәндәр Биктаһировка*

Җырлый-җырлый иген иккән ирләр,
Җырлый-җырлый урман кискәннәр.
Җырларыңда синең иген үсә,
Кара урман шаулый, Искәндәр!
*Харрас Әюпкә*
Баш мөхәррир усал була,
Шагыйрь була гаепсез.
«Иң баш» та ул, иң юаш та,
Мөхәррир дә, бик шәп ир дә —
Яши алмас Татнәшрият,
Яши алмас әдәбият
Бүген Харрас Әюпсез.

*

*Һ. Һейнедән, алман шагыйре*

***

Киңәш биреп акыл өйрәттеләр,
Мактадылар аннан күтәреп.
— Тик берazга гына түз, — диделәр, —
Теләкләрең тиздән үтәлер.
Инде күптән ачтан үләр идем,
Киңәшчеләр бик күп булса да...
Әгәр дә ки бер рәхимле бәндә
Ярдәм кулын миңа сузмаса.
Рәхимле җан! Тик ул сөйде мине,
Оныталмам хәтта үлгәндә.
Тик кочаклый гына алмыйм аны...
Әй кызганыч!.. Үзем — ул бәндә.

*

*Р. Гамзатовтан, авар шагыйре*

**МИНЕМ ГОМЕР**

Малай чакта, әй көнләшә идем
Чапкан чакта атта егетләр.
Ә төн җитсә, алар, кочаклашып,
Авыл буйлап җырлап үттеләр.
Онытыла иде бар дөньясы,
Хәнҗәр күргәч ирләр билендә...
Малай инде! Әй ялвара идем:
«Ияртегез, — диеп, — мине дә».
Бөтерелә тузан. Ә мин торам
Еламыйча көчкә тыелып, —
Кичкә кадәр оясында калган
Лачын баласыдай, боегып.
Көннәр буе офыкларга карап,
Егетләрне көттем сагынып.
Атлар белән бергә вакыт чапты,
Тузан кунды чәчкә чал булып.
Башка егет хәзер ат иярли,
Башка егет. Хәнҗәр билендә...
Чал чәчемне онытып кычкырам мин:
«Ияртегез, — диеп, — мине дә!»
Хушлашырга хәтта оныта ул...
Чаба егет, чаба гел алга.
Дулкын ярга бәргән йомычкадай,
Ә мин калам басып далада.
Һәм дәшәләр миңа: «Сиңамы, дип,
Үрмәләргә кыя ташына?!
Мәртәбәле үзең, чәчеңдә — чал,
Җырлап утыр учак каршында».
Әй, яшьлегем, минем гомеремә
Киттеңмени бары сугылып?!
Минем урын учак янындамы,
Үз утыммы бара суынып?!
Дага бөгәр куәт булмаса да,
Яшь-яшь килеш әле хисләрем.
Бар кызларның йокылары качар,
Җырлап үтсәм әгәр кичләрен.
Картлык тими бөтен кешегә дә...
Ышаныгыз, дуслар, шагыйрьгә.

Чәчләренә чал кунса да хәтта,
Япь-яшь килеш керә ул гүргә.
Яшьтәше мин барча кешеләрнең,
Бәла түгел еллар тузаны.
Җырлар язсам, мәңге картаймамын,
Һәм сизелмәс гомер узганы.

*

***

Катылана торгач, металл булсам —
Ясамагыз миннән вак акча!
Шомарганчы кеше кесәсендә,
Әйләнүең яхшы агачка.
Насыйп икән әгәр металл булу —
Утка салып, корал коегыз.
Кыныгызда миндәй хәнҗәр торса,
Тынычлыкта булыр уегыз.

*

**ШИГЫРЬ**

Тып-тын торам, чакырмыйм да инде,
Эзләмим дә җуйган сүземне.
Чакырмыйча килгән күз яшедәй
Килсен миңа бүген ул үзе.
Көтмәгәндә килсен күңелемә
Һәм кәгазьгә төшсен соңыннан.
Сөендереп, ишек шакымыйча,
Килеп кергән якын дус сыман.

*

*С.Есениннан, урыс шагыйре*

***

Син сөйлисең: «Сәгъди, диеп,
Тик күкрәктән үбә иде».
Алла хакы өчен түзче,
Өйрәнермен әле мин дә.
Син җырлыйсың: «Евфратымда
Гөлләр чибәр җир кызыннан».
...Их, әгәр дә бай булсам мин,
Язар идем бүтән җырлар.
Өзәр идем гөлләрне мин,
Сөяр идем сине бары...
Дөньяда тик бер чибәр бар,
Гөлләр гөле — ул Шаганэ.
Зинһар өчен, тыйма мине!
Минем өчен җирдә чик юк...
Шагыйрь булып туганмын мин
Һәм үбешәм шагыйрь кебек.

*

*Ф. Оңгарсыновадан, казакъ шагыйрәсе*

***

Күңел дулкыннарым синең ярга кага —

И туган җир, далаң иркен, кочагың киң.
Читтә булсам, сагынуымны канат итеп,
Кошлар кебек, сиңа карап очамын мин.
Анам җаны кебек якын җир-туфрагың,
Далам минем — иркәм минем, сөйгән ярым.
Сине ничек яратырга икәнлекне
Китаплардан укып кына өйрәнмәдем.
Синдә ташлар йомшак кебек, күкләр аяз,
Синдә җанны тетрәтерлек дастаннар бар.
Бу тормышым, бу гомерем, бу язмышым
Сиңа гашыйк булуымнан башлангандыр.
Кичермә син, әгәр җаның яраласам...
Серләремнең бөтенесен сиңа ачам.
Ватансыз һәм илсез, диеп атасыннар,
Өметеңне акларга да ярамасам.

*

## КАЗАКЪ ЙОЛАЛАРЫ

Казакъ яши гореф-гадәт, йола белән.
Мин аларның барысын да яхшы беләм.
Ата-ана картайганда, чаларганда —
Сый-хөрмәтнең иң зурысы тик аларга.
Татлы ризык: затлы кием, парчасы да —
Олы кеше кулындадыр барчасы да.
Иртә-кичен кунак килсә, чакырусыз,
Сорамыйбыз һичкайчан да: «Кайдан, кем сез?»
Аягүрә — яшебез дә, картыбыз да,
Табында бар тәмле тел дә, ипи-тоз да.
Кызлар үсеп, гашыйк булса бер егеткә
Сүз катарга да оялып, гомере үтә.
Яшь киленнәр өй биләмәс, тезген алып,
Олыларны хөрмәт итә безнең халык.
Бик усал без усалларга, тел тигәнгә.
Җиң сызганып тотынабыз, эш дигәндә.
Белмәсәң — бел, дустым, безне, якын барып —
Шундый инде казакъ дигән акын халык.
Иге-чиге булмаган күк далабызның,
Күңеле киң казакъ атлы балагызның.

*

## ДУСТЫМ

Бер дустым бар. Аның белән
Күпме гомер узылган.
Ул дустымның исеме — юл...
Чиксезлеккә сузылган.
Айкап чыксам төбәкләрне,
Җыйсам дала гөлләрен,
Кай якларга барсам да мин,
Шул дус белән бергәмен.
Кадерле ул картка, яшькә —
Чын дуслыкка ни җитсен!
Кайчак дөнья йөз чөерә...
Ә син аңа хаҗәтсең.
Дус барда җиңел табамын
Табышмакның чишемен.
Аның белән бергә кагам

Серле шигырь ишеген.
Сагынып анам кочагын,
Сыктап көткән чагымда,
Шул дустым белән очамын
Туып-үскән ягыма.
Гомер бик еш дучар итә
Япа-ялгыз калырга.
Арсаң хәсрәт-моңнарыңнан,
Дус бар, йөрәк, кайгырма.
Кыйналсам да, һәрчак алга
Дәшәмен сине, тормыш.
Анам җаны кебек дустым —
Юл — мине адаштырмас.

*

## ТУГАН ИЛ

Чүлләрдә үсте чәчәкләр,
Бакча булды далалар,
Калкып чыкты зур калалар:
Бу — безнең абыйлар эше,
Беләсезме, балалар?!
Бодайлар үсә кырларда,
Пешә алсу алмалар,
Җир астыннан нефть ургый:
Бу — абый-апалар эше,
Беләсезме, балалар?!
Зур заводлар, фабрикалар,
Ап-ак йортлы калалар,
Кыюлар, батырлар иле:
Бу — безнең туган илебез,
Беләсездер, балалар?!

*

## ЗООПАРКТА

Бервакытны әтием
Алып барды шәһәргә.
Зоопаркта күрдек без
Бүреләр, төлкеләр дә.
Читлектәге арыслан
Йөрми җәнлек ауларга.
Китә алмый моннан ул
Туган иле — тауларга.
Лачын салган канатын, —
Сусаган ул ирекккә,
Моңсу күзен төбәгән
Биеккә, зәңгәр күккә.
Маймылга конфет биреп,
Өйгә кайтып киттек тә...
Кызганып йөрим хәзер:
Яшәү читен читлектә.

*

## БАЛЫК

Беркөн бабам ятьмәсенә
Эләкте олы балык.

Янына килдем балыкның,
Карыйм дип кулга алып.
Ә ул шу-ундый олы икән...
Атландым өстенә үк.
Мине җиргә очырды ул,
Койрыгын тик бер селкеп.
Маңгаемда яра хәзер,
Йә ела, йә елама...
Ачуланган, ахры, миңа,
Җибәрмәгәч елгага.

*

*В. Азаровтан, урыс шагыйре*

**ДИҢГЕЗ АКЧАРЛАГЫ**

Ак яллы дулкынга сыенып,
Акчарлак кычкыра ачынып.
Югыйсә, кай якка очса да,
Үз ирке — күк ачык, юл ачык.
Сап-салкын диңгезнең кочагы,
Туктаусыз дулкыннар куа ул.
Еракта, офыклар артында,
Канатлар кагынып туа җил.
Җылы җил тарата томанны,
Эретә гасырлар суыгын.
Акчарлак тәпие астына
Балыклар чәчәләр уылдык.
Яр буйлап бер малай йөгерә,
Белмичә сагышны, кайгыны.
...Ә диңгез төбендә төш күрә
Диңгезче бабасы каегы.

*

*Л. Ошанинан, урыс шагыйре*

**ӘДӘБИЯТ ИНСТИТУТЫН**
**ТӘМАМЛАГАН ДУСЛАРЫМА**

Җир түгәрәк, матур, гаҗәеп зур, —
Кая илтмәс безне юллары?!
Тик кайда да истән чыкмас инде
Герцен йорты, Тверь бульвары.
Шигырь өчен монда ант эчелде,
Яңгырады йөз тел тостлары.
Сез булганда, димәк, мин дә яшим, —
Исәнмесез, барча дусларым!
Безнең йортка Горький исем биргән...
Мондый бәхет тия кемнәргә?!
Димәк, безнең, мәңге шәкерт булып,
Узасы бар килер көннәргә.
Карт тупыллар, башын түбән иеп,
Шигырь укый монда ташларга...
«Шигърият ул — мәңге яшьлек» булса,
Яшьлек, димәк, монда башлана.

*

***

Мин үземне гел яшь санап йөрдем,

Бактым исә — чәчләр чаларган.
Мин дусларга һәрчак учак яктым,
Җавап көтми генә алардан.
Бар кешегә яхшы булып булмас,
Бар юлларны үтеп булмастыр,
Бар сылулар сыймас кочагыма,
Соңгы җырым, ахры, тумастыр...
Үткән юлым — уч төбендә кебек,
Мин бер юлдан туры атладым,
Гомер буе бер максатка бардым, —
«Мәхәббәт» дип аны атадым.
Мин дөньядан күпне өмет итмим,
Шигърияткә яшим табынып.
Мин бәхетле — кеше күңелендә
Бер шигырем янса кабынып.

*

## УРМАНДА

Урман тып-тын. Ялгызлыктан туеп,
Ычкындырдым ишек келәсен...
Юрадым мин: әгәр кояш чыкса,
Минем янга бүген киләсең.
Күкләр күкрәп, яңгыр явып узды,
Яфракларга тезде энҗеләр.
...Килерсеңме, әллә юкмы, диеп,
Юрау юрыйм һаман мин — юләр!
Урман шаулый. Син киләсе юлдан
Кара мәче — кара төн уза.
Ә мин һаман күктән кояш көтәм,
Ә мин һаман көтәм могҗиза.
Урман тынды. Ялгызлыктан туеп,
Ычкындырдым күңелем келәсен...
Таңнар ата: кояш чыгамы ул?
Синме әллә миннән көләсең?

*

## САРЫ КОЛМАК

Сары сарган колмак яфрагына...
Ерак әле юкса көзләргә.
Тәрәзәмнән карый сары колмак...
Көзгә кадәр ничек түзәргә?!
Үрелеп карый бүлмә эченә ул,
Җир яктысы җитми, күрәсең.
...Мин үзем дә колмак сабагыдай:
Утлар күрсәм, килә керәсем.
Тамыры соң әллә корыганмы?
Усал җилләр әллә тигәнме?
...Мин үзем дә авырлыклар күрдем.
Тик булмады башым игәнем.
Сары яккан колмак яфрагына
Туган якның ачы туфрагы.
...Сары сарган саен матурая,
Ныгый бара колмак яфрагы.

*

***

Мин эшче дә булдым, җитәкче дә,
Солдат булдым, булдым төзүче.
Кайнарлыгын тойдым иреннәрнең,
Дошманнардан алдым үчемне.
Дуслар кулы кулым җылыттылар,
Күкрәгемдә йөрттем ут... хаклык.
Дөнья гизеп чәчем агарса да,
«Ул яшь» диеп әйтсен ил, халык.

*

***

Нәрсә кирәк безгә бәхет өчен? —
«Алтын сарай кирәк», — димә син.
Кем бирер соң безгә ул бәхетне?
Тик без генә бары — син дә мин.
Кем коткарыр атом упкыныннан,
Киләчәккә күпер салыр? — дим.
Кемнәр эшләр моны? — бары тик без,
Тик без генә — син дә мин.

*

***

Син елыйсың... Нигә елыйсың син?
Нинди кайгы эзен калдырды?
Кая китте яшьлек чаялыгың?
Тормышыңнан әллә ардыңмы?..
Кайгыларың онытм, елмай әле...
«Бәхет» дигән илгә юл тотыйк,
Кичер мине... кайчак уйга чумып,
Йөрәгеңне куйсам онытып.

*

***

Кояш нигә сукыр тычкан өчен? —
Караңгыда яши, пошмый да;
Җир астында борма юллар тишеп
Үткәрә ул җәйне, кышны да.
Ләкин беркөн Кояш сүнә калса,
Караңгылык басса дөньяны...
Сукыр тычкан үләр... Сәбәп нидә? —
Белә алмас ләкин ул аны.

*

***

Ә мин яшим. Бары мендәр белә
Авырлыгын төшләр күрүнең...
Егерме ел элек күке әйтте:
«Дүрт ел калды, — диеп, — гомерең».
Артта калды баганасы чикнең,
Кичтем инде җиде диңгезне.

Енисейны үттем. Таныш миңа
Дөяләр һәм испан үгезе.
Ашыгырмын һәрчак Мәскәвемә,
Яңгыр яугач, салкын кар күргәч...
Әле тагын дүрт ел яшәрмен мин,
Гомеремне яшәп бетергәч.

*

*А. Старостиннан, якут шагыйре*

***

Мин — Себер, тундра улы,
Телим тынычлык, тынлык.
Мин әзер боздай эрергә,
Һәм яшәргә үз илемдә
Бер кәрлә каен булып.

*

***

Бүлмәм минем ялгызлыктан тилмерүче йөрәк кебек.
Өстәлемдә саф чәчәкләр — дустым китте миңа биреп.
Тәрәзәмнән ил күренде, чәчәкләрдән бозлар ереп.

*

*А. Комендантастан, Литва шагыйре*

***

Төн. Тынлыкка чумган бөтен дөнья,
Атларыбыз дагаланмаган,
Җирләребез әле сөрелмәгән,
Кошларны да курку алмаган.
Ә мин әле шушы көнгә кадәр
Куркынычның үзен күрмәдем.
Табигатьтән күпме нәрсә алдым!
Ә үзенә берни бирмәдем.
Мин табигать баласыдыр, ахры,
Кошлар мине сүзсез аңлыйлар...
Урманнарым шундый кешелекле! —
Бар афәттән мине саклыйлар.

*

*А. Бедюровтан, Алтай шагыйре*

## ТУЛГАН АЙ ӘКИЯТЕ

Ястык итеп язымны,
Ятам мин күккә карап.
Җылы сүзләр табалмыйм...
Җил, сагышымны тарат.
Серле, сихерле сүзләр
Йөри колак янымда.
Тотам, дип, кулым суздым —
Очты-китте тагын да.
Баш очымда, биектә,
Илемнең тау-ташлары.
Күзләремнең төбендә
Илемнең аккошлары.

Күзем ачам,
Күзем йомам...
Тыңлыйм күкнең тавышын,
Кошлар оча,
Кошлар кайта.
Барысы — илем кошы!
Ап-ак көмеш канатлар
Җилгә тиеп сызгыра.
Телләремә алтайча
Иң кадерле сүз куна.
Яшел ястык язымны
Онытып кошлар санадым.
Кошлар булып кайтучы
Сүзләремне таныдым.
Җанымдагы сагышлар
Яшькә кушылып актылар.
Чит телләрдә адаштым...
Кошлар килеп таптылар.

*А. Байзуллаевтан, балкар шагыйре*

## ЗӘҢГӘРСУ КЫЯЛАР

Гөр килә сабыйлар уены,
Чияләр чәчәге коела.
Аларган тауларга күз салам:
Алдымда зәңгәрсу кыялар.
Җырлады егетләр туйларда,
Чем-кара күзләрдә — дөньялар.
Аналар, апалар куанды,
Дәшмәде зәңгәрсу кыялар.
Китәләр дөньядан бабайлар,
Үзәннәр кайгыга урала.
Ә таулар һаман да бер көе, —
Тик тора зәңгәрсу кыялар.
Гомерләр, дәверләр узалар.
Сугыш бар... каберләр... туйлар бар...
Мәңгегә торырлар бу таулар,
Торырлар зәңгәрсу кыялар.

*

*А. Антоновичтан,урыс шагыйре*

## ЯЗ БЕЛӘН САУБУЛЛАШУ

Нишлим инде,
Тагын үз күңелем,
Нишлим инде, тагын үз җаным...
Кошлар җыры тиздән онытылыр —
Көзгә таба инде юл алдым.
Яз аенда — иң зур рәхәт, ләззәт,
Серле тавышларда сихер бар.
Урманнарда дәрвишләнеп йөрү,
Учак янындагы юлчылар...
Урманнарга язын күк төс керә,
Урман аша кырлар күренә.
Манарасы белән күзгә кереп,
Чиркәү тора аның түрендә.
Ул чиркәүдә безгә җырларга да,
Озатырга да хәтта үлгәнне,

Башны орып бәхет ялварырга,
Еларга да туры килмәде.
Яз аенда дөнья шундый гади!
Ә шулай да никтер ялгышам.
Бар агачлар олы юлга озата,
Шигырьләргә сеңә сагышлар.

*

*А. Гавриловтан, урыс шагыйре*

**ЭЗЛӘР**

Кеше үтте диңгез яры буйлап,
Чылбыр булып ятты эзләре...
Дулкын юа — эзләр барыбер кала...
Юылмастыр кебек үзләре!
Диңгез дулкыннары һәм кешеләр
Көрәшәләр мәңге тир түгеп...
Ә мәңгелек бар эзләрне юа,
Һәм эзләрдә кала мәңгелек.

*

**НАРАТЛАР**

Җирне кочып тамырлары белән,
Давылларга куеп күкрәген,
Елга шавын тыңлый карт наратлар,
Ишетмичә күкләр күкрәвен.
Җилләр ярсып җиргә екмак була,
Упкын көтә ачып авызын...
Тик упкынга җилләр ега алмый
Чал наратын кыя тавының.
Бураннар да ешрак була монда...
Кырыслыкка бик бай бу яклар.
...Батырлыкка өйрәтәләр безне
Таш кыяда үскән наратлар.

*

***

Комнар кайный мәхәббәт һәм уттан...
Салкын тора минем акылым.
Бохараның биек манарасы
Күрә алмас Рәсәй аклыгын.
Комнарны мин белмим, белә алмыйм,
Комнар белми минем кайгымны.
Сиңа минем олы әҗәтем бар,
Туган якның ап-ак каены.
Бохараның биек манарасы, —
Нигәдер гел сиңа юл алам...
Минем өчен билгесез, ят илләр
Күзләреңә кереп югалган.
Күзләремә зәңгәрлекләр сеңгән,
Ак эзләрем — кырыс кышларда...
Тик шыгырдап куя кайчагында
Ерак дала комы тешләрдә.

*

*Ш. Алишевадан, кумык шагыйрәсе*

***

Еллар үтә,
Айлар үтә,
Үтә сәгать, минутлар.
Җитә дә күк,
Җитми дә күк
Морадына өметләр.
Берәү туа,
Берәү үлә,
Шатлыкка кушыла бәла.
Ә Җир шары
Тыныч кына
Әйләнә дә әйләнә.

*

**БЕРӘҮГӘ**

Укыганда
Шигырьләрем
Нигә борының чөясең?
Сөюне куй,
Башка нәрсә
Язып кара, диясең.
Мәхәббәттән
Авырыйм мин,
Ләкин көтмим азагын.
Хәзер язмый
Бу сөюне,
Әйт соң, кайчан язармын?

*

*М. Калмыкаевтан, нугай шагыйре*

**САГЫНУ**

Кайтсам икән, Җиленчәгем, катыңа,
Күрсәм икән дулкыныңда Ай юлын.
Күмәр идем хәсрәтемне комыңа,
Бүләр идем җан дусыңдай кайгымны.
Кайтсам икән, Җиленчәгем, ярыңа...
Шифа суың җан гөлемә охшаган.
Кобан иле сеңгән минем каныма,
Тамырларым эсселектән сусаган.
Кайтсам икән, Җиленчәгем, яныңа...
Күңелләрем тартыла гел аклыкка.
Бер утырсам дулкын юган ташыңа,
Тулыр иде киң күкрәгем шатлыкка.
Җиленчәгем хәләл сөттәй кадерле,
Ул мәңгегә тугры калган ярына.
Җырчы килеп сиңа колак сала да,
Яңа моңнар таба үз җырларына.

*

*В. Портновтан, урыс шагыйре*

**ФРОНТОВИК АГАЧЛАР**

Пышылдаша агач яфраклары,
Исләренә төшә яшь чаклар...
Тора алар, солдат каберләрен
Тамырлары белән кочаклап.
Кемнәр аңлар юкәләрнең күңелен,
Имәннәрнең серен кем ачар?
Яфрагы күк калтырамый усак,
Агач җанлы түгел агачлар.
Үз әнисе кебек сыкрый каен,
Иңнәренә салып шәлләрен.
Каен кочагында солдат ята...
Кемнәр белә каен хәлләрен?!
Күпме алар — яуда егылганнар! —
Күпме батыр, күпме «хәбәрсез...»
Моңсуланып бераз тын калыгыз
Ялгыз каеннарны күрсәгез.
Чәчләренә сугыш төсе сеңгән...
Дошман киткән. Ул бар, ул калган.
Алланадыр нарат таңнан түгел,
Яралардан тамган ал каннан.
Һәр агачның төпләрендә бүген
Бардыр кебек солдат кабере.
Агачларга уйма үз исемең,
Ул исемсез килеш кадерле.
Тәннәрендә кургаш саклый алар.
Ул агачлар утта көйрәгән.
Туган җиргә шулай берегергә
Батырлардан алар өйрәнгән.

***

Очрашырга иде йолдызда бер...
Җирдә юктыр сөю, тугрылык.
Мең мәшәкать тулы бу хәятта
Мәхәббәткә, ахры, урын юк.
Качып китик дөнья рәхәтеннән,
Качыйк әйдә дус һәм дошманнан!
Синең күзләр чәчәкләргә түгел,
Йолдызларга күбрәк охшаган.
Очрашырга иде, кавышырга...
Юлга чыгыйк карап йолдызга.
Күпме кеше, ярын табалмыйча,
Янәшәдә генә юл уза.
Мин йолдызда учак ягар идем,
Син ашыгыр идең яныма.
Элеккечә... безнең мәхәббәткә
Шаһит булыр иде таң гына.
Сине каян эзләп табыйм икән? —
Җавабың юк, күпме дәшеп тә.
Безгә шундый рәхәт булыр иде...
Рәхәт булган кебек яшьлектә.
Очрашырга иде йолдызда бер...

*

**ДӘФТӘР ТУРЫНДА БАЛЛАДА**

Кәгазь капчыкларны турый-турый,
Дәфтәр ясый идек төннәрен.

Ул капчыклар ачы сагышларын
Ташымады икән кемнәрнең?
Кәгазьләрне тигезләргә теләп
Сыйпый иде арык кулларым,
Тик хәрефләр төртелә дә кала...
Хәтерләтеп сугыш юлларын.
Сыңар куллы әти тиз картайды
Кәгазь капчык белән хат ташып.
Өй борынча кайгы өләште дә
Төннәр буе чыкты саташып.
Хәтерлим мин һаман әтиемнең
Ил сагышы тулы күзләрен;
«Кыскарак яз, улым, мәгънәле яз,
Кәгазь сакла», — дигән сүзләрен.

*

***

Җилгә чәчеп мөлкәтен,
Ярлыланган көз, бөлгән.
...Ай тәрәзне ватар күк
Очлы мөгезе белән.
Гөнаһ кылган кешедәй
Бимазаланып беттем.
Тыны да чыкмый бүген
Төн төсле кара этнең.
Кунаклар туймый җырлап,
Туймыйлар ашап, сөйләп...
Эт канәгать, ул өрми:
Эт күңеле — бер сөяк.
Мал суйдык. Җыйдык кунак.
Күздә яшь килеш көләм.
...Ай тәрәзәне шакый
Канлы мөгезе белән.

*

## ҮГИ АНА ЯФРАГЫ

Кемнәр сине «үги» дигән,
Үги ана яфрагы?
Читкә — үги...
Үги итмәс
Туган җирнең туфрагы.
Күрми сине ваемсызлар,
Күрми чәчәк-күршеләр...
Бары хаста чакта гына
Эзли сине кешеләр.
Яр сукмагы буйлап киләм,
Киләм синнән көнләшеп.
...Мине шулай авыр чакта
Алсалар иде дәшеп.
Кемдер үги итсә итсен,
Кемдер көлеп карасын...
Мин бәхетле — җырым белән
Төзәтсәм җан ярасын.

*

## ӘБИЛӘР ЧУАГЫ

Көзге урман. Малай яфрак яга,
Малай тели кызык ясарга.
...Өнсез калган агачларга гүя
Төтен түгел, ап-ак чал сара.
Урман кача томан кочагына,
Урман чума сагыш, моң-зарга.
Ялкын чәчле малай яфрак яга...
Күңелләргә көзге моң сара.

*

## АЛМАЧУАР ЧАПТАРЫМ

Хәтеремдә: «Батыр бул!» — дип,
Атым сөйгән чакларың.
Яудан исән алып чыкты
Алмачуар чаптарым.
Чаптарымның күкрәге киң,
Йолдыз төсле күзләре.
Атка менми, яуга керми
Егет җаны түзәрме?!
Җилдә сибелә яллары —
Гүя кызлар толымы.
Уктай оча, белә чөнки
Минем барыр юлымны.
Бар атларны узып чаба,
Чаба алга, яктыга.
Ике тамчы судай охшаш
Ул Чапаев атына.
Чабышларда һәрвакытта
Ул тик беренче килде.
Дошманнарны җиргә екты
Яшен уты шикелле...
Онытылмас Ватан өчен
Утка кергән чакларым.
Мең үлемнән алып чыкты
Алмачуар чаптарым.

*

*Т. Матмуратовтан, каракалпак шагыйре*

## ӘЙТӘ ИДЕҢ

Чәчләреңә гөлләр кадасам,
Әйтә идең: «Яман бала син».
Яман булсам, ялгыз бакчада
Минем белән нигә каласың?
Йөзегеңне куйсам яшереп,
Әйтә идең: «Яман бала син».
Яман булсам, язган хатымны
Түш кесәңә нигә саласың?
Иңнәреңә кулым куйганда,
Әйтә идең: «Яман бала син».
Яман булсам, мине күргәч,
Алсу йөзең нигә яна соң?
Иреннәрең балын эчкәндә,
Әйтә идең: «Яман бала син».
Яман җирдә гөлләр үсәме? —

Йөрәгемдә йөрткән лалә син.

*

*О. Цокуновтан, урыс шагыйре*

**ЙОЛДЫЗЛАР КОЕЛГАНДА**

Әйләнеп карарга вакыт юк,
Көннәре, төннәре ашыга.
Әйтерсең киләчәк иленнән
Бәхетләр юл чыккан каршыга.
Кайчакта уйланып ятасың...
Һавадан йолдызлар коела.
Учакта ут яна. Вакытлар
Тукталып калгандай тоела.
Тәрәзә артында кара төн
Океан шикелле чайкала.
Шәһәрләр, авыллар югала...
Югала... Бары тик ай кала.
Чайкалып океан төбендә
Йоклыйсың берни дә шәйләми.
Хәтерең түрендә бары тик
Күрәсең үзеңнең шәүләңне.

*

*Н. Поляковадан, урыс шагыйрәсе*

**ЮЛ УРТАСЫ**

Ярты юлны уздым инде —
Әле күпме барасы?!
Сине кем уйлап тапкан соң,
Чакырым баганасы?
Каерылып артка карыйм,
Бер чакырым үтәм дә...
Тау түбәсеннән күренә
Барыр юл да, үткән дә.
Үткән юллар авырлыгы
Хәзер татлы төш кенә.
...Йөгең җиңел була икән
Таудан түбән төшкәндә.

*

*Г. Лоркадан, испан шагыйре*

**ХУШЛАШУ**

Мин киткәндә бу дөньядан —
Япмагыз балконнарны.
Әфлисун ашый балалар.
(Балконнан күрәм аны.)
Уракчылар бодай ура.
(Балконнан карыйм аны.)
Мин киткәндә бу дөньядан —
Япмагыз балконнарны.

*

**АЙ КАЛЫККАН ЧАКТА**

Ай калыккан чакта

кыңгыраулар тына.
Урман сукмаклары —
чытырманлык кына.
Ай калыккан чакта
диңгез — җирнең өсте,
ә йөрәгем минем
ялгыз утрау төсле.
Ай тулганда лимон
кирәк икән кемгә?
Табыннарда — яшел,
салкын җимеш кенә.
Ай калыккан чакта,
төнге бакчаларда —
янчыкларда елый
көмеш акчалар да.

*

## ГИТАРА

Әнә башлана
гитара үксүе.
Челпәрәмә килә
таң касәсе.
Әнә башлана
гитара үксүе.
О, син көтмә аннан
тынлыкны,
сорама син аннан
тынлыкны!
Бертуктамый
гитара елый,
арыкларда аккан судай елый.
Кардан яз сораучы
җилләр кебек елый,
ялварма син, көтмә
тынлыкны!
Шулай елый кечке кояш таңны сорап,
шулай елый юл югалткан юләр ядрә,
шулай елый уттай кызган кайнар комнар
салкын гүзәллеген сагынып төнбоекның.
Шулай саубуллаша кошлар тормыш белән
елан угы алда торганда.
О, гитара,
биш йөгерек хәнҗәрнең
бичара корбаны!

*

*Я. Ухсайдан, чуваш шагыйре*

## ОХШАТАЛАР МИНЕ ТАТАРГА

Охшаталар мине татарга, —
Чәй куялар керә-керешкә.
Бар дусларым әйтә яратып,
Түбәтәй, дип, сиңа килешә.
Бу охшашлык белән һәрвакыт
Дошманнарның җанын үртәдем...
Якты татар йөзен үземдә

Туган көннән бирле йөртәмен.
Гомер буе йөрде озатып
Татарларның утлы карашы...
Татар белән шатлык бүлештем
Һәм бәйләштем йөрәк ярасын.
Ничә тапкыр Уфа урамын
Мин Гафури белән урадым, —
Әзер идем алып төшәргә
Йолдызларның иң-иң ерагын.
Ә өстәлдә шаулап, шатланып,
Каршы алды безне самавыр,
Чәй эчерде миңа Гафури,
Чынаякта гүя кайнар җыр.
Киләчәктә, аның шикелле,
Әдип булу — бөтен исәбем...
Ул өйрәтте мине очарга
Кош баласын — шагыйрь кисәген.
Уртак тарих, уртак язмышның
Уйлый-уйлый усал чорларын,
Мин унҗиде яшьтә татарның
Сагыш тулы җырын җырладым.
Канат куйды миңа Гафури, —
Котылдылар хисләр тышаудан.
Шуңа күрә дә мин шигырьдә
Гафурига бераз охшаган.

Кичә генә күргән шикелле...
Әллә соң бу төштә булдымы? —
Муса Җәлил йөртә Мәскәүдә,
Уң кулына кыскан кулымны.

Мин Җәлилнең батыр рухына
Шул чаклардан бирле ышанам:
Җәлил белән яшьтән дус идек, —
Мин татарга шуңа охшаган.

Казан, Казан! Синдә йөрдек без
Җәлил белән ерак язларда.
Чуваш улы Яков Ухсайның
Дуслары күп шәһре Казанда.

Туган якның аяз төннәрен
Мин Казанга тагын алыштым...
Хәсән Туфан атлый янәшә —
Ахирәтем, җаным, чал дустым.

Аның белән уртак күңелем,
Уем уртак, уртак хисләрем.
Аның белән утка керермен,
Аның белән сулар кичәрмен...

Җыр күгендә насыйп булырмы
Аның кебек биек очарга?
Туфан белән шактый юл уздык, —
Мин татарга шуңа охшаган.

Бар дусларым әйтә яратып,
Түбәтәй, дип, сиңа килешә,

Кая барма — шунда дусларым —
Кочагына алып күрешә.

Бу охшашлык белән мин һәрчак
Дошманнарның җанын үртәдем.
Туган көннән бирле үземдә
Якты татар йөзен йөртәмен.

***

Чәй эчәм — һаман суык,
Мич ягам — җылысы юк...
Иңбашымнан тун төшми.
Берь ялгызым. Җан өши.
Бөтен дөньям җылына күк
Килсә тик якын кешем.

*

*С. Мәҗитовтан, каракалпак шагыйре*

**ИРЕК ТАҢЫ**

Таң сызылып атты көнчыгыш яктан,
Уянды барча халык, безгә ни булды?
Кара төннәр үтте, уянды бар җан,
Куанды барча халык, безгә ни булды?
Алланып таң атты, ул — ирек таңы,
Онытылды инсанның михнәтле чагы.
Яктырды җиһанның бар тирә-ягы,
Кузгалды барча халык, безгә ни булды?
Аткан таң дөньяны нур белән күмде,
Золымнан корыган гөлләр дә көлде.
Арынып карадан, ак якка дүнде,
Шатланды барча халык, безгә ни булды?
Төннәрне таратып, алтын кояш торды,
Ул кызганмый җир өстенә алтын нурлар койды,
Һәммә гашыйк аткан таңга омтылды...
Уянды барча халык, безгә ни булды?
Бераз хәйран калып, таңга карап тор,
Таң җилендә чәчләреңне тарап тор,
Таң җилләре моң-зарыңны таратыр...
Җырлады барча халык, безгә ни булды?
Ак таңга сәлам бир, тор, каракалпак,
Таң нурында коен, әйдә, каракалпак,
Изелдең, каргалдың... Эшең иде хак.
Кузгалды барча халык, безгә ни булды?

*

**КЫЗЛАРГА**

Җиргә яңа язлар килә,
Бакчаларга чыга кызлар.
Гөл ачыла, былбыл сайрый, —
Моңланмагыз, чая кызлар.
Хур кызымы, пәризатмы —
Сезнең йөзләр айдай якты,
Битегездә сипкел артты, —
Язлар килде җиргә, кызлар.
Бакчадагы гөлдәй янып,

Күбәләктәй очып-кунып,
Җиләк кебек пешеп-тулып
Йөрегез сез, гүзәл кызлар.
Бакчаларда — заман җиле,
Яратасыз туган илне,
Яратасыз туган телне...
Шулай үсә безнең кызлар.
Үткән дәвер артта калды,
Таза дәвер урын алды,
Йөрәкләргә ялкын салды...
Иң кадерле кунак — кызлар.
Килгән кунакка бүләк сал,
Аннан сора хәл вә әхвәл,
Заманның тәрбиясен ал...
Хезмәт итсен илгә кызлар.
Бакча җимеш белән тулсын,
Кыз-егетләр тигез булсын,
Күңелләрдә хөрлек тусын, —
Тырышыгыз, гүзәл кызлар.
Белем өчен юллар ачык,
Наданлыктан яктыга чык,
Торма күләгәдә качып, —
Безгә кирәк кыю кызлар.
Елга булып белем аксын,
Ә наданлык ары чапсын,
Белемлеләр җирдә артсын, —
Олы эшләр көтә кызлар.
Ватан өчен игелек кыл,
Халкың өчен файдалы бул,
Алда безнең — туп-туры юл, —
Туктап тормыйк, әйдә, кызлар.
Аерса олы-кечесен,
Белсә илдә ни көчлесен,
Татыса ачы-төчесен, —
Шулар күпне белә, кызлар.
Тарих безгә карар яман,
Әгәр кызлар булса надан,
Халык кара булыр һаман
Сездән башка, гүзәл кызлар.
Бул син илдә кояш төсле,
Тик белемле генә көчле,
Ирек җиле безгә күчте, —
Югалтмагыз аны, кызлар.
Чык бакчага иртә таңнан,
Бәхет тапмас йоклап калган,
Ялкауларның сүзе ялган, —
Тыңламагыз аны, кызлар.
Безнең заман — гаҗәп заман,
Безнең язмыш — безгә таман,
Әйтәм әле, әйтәм һаман:
Җиргә хуҗа булсын кызлар.
Сезгә атап хатлар яздым,
Тик сүзләрнең таптым азын:
Сез — Ватанның яңа язы,
Илнең киләчәге, кызлар.

*Т. Адышевадан, кыргыз шагыйрәсе*

## ШИГЪРИЯТ

Син — авазы гашыйк яшьлекнең,
Син — якты ут юлдан язганга,
Син — күзгә су салкын чишмәдә,
Сатып булмый сине базарда.
Син — давыллы, шаулы диңгездәй,
Мин — тик көймә синең дулкында.
Син — җәй җиле, юлың тауларда,
Канатыңа синең җыр кунган.

*

## МӘХӘББӘТЕМ

Кешеләрне сөям, кешеләрне,
Алар белән бергә буй җиттем.
Алар күңеленнән җылы алдым.
Кешеләрсез гомер, һай, читен.
Каурый кадыйм бәйрәм бүрегемә,
Дуслар дәшәм бәйрәм ашына...
Язмыш атлы чаптар атка менеп,
Кешеләргә һәрчак ашыгам.
Кайгы килсә, хәсрәт килсә миңа,
Кешеләрдән кодрәт, көч алам.
Уйлый алмыйм хәтта, кайчандыр, дип,
Җир өстендә кеше булмаган.
Бар шатлыгым кешеләргә бирәм.
Ялгыз калсам, батам сагышка...
Мин кешеләр арасында яшим,
Урман эчендәге агачтай.

*

*Г. Галадан, поляк шагыйре*

## ИСТӘЛЕККӘ ЧӘЧӘК ӨЗЕГЕЗ!

Болын кызы бишек көен көйли...
Чәчәк белән үргән толымын.
Ә мин ятам яңа туган кебек,
Бишегендә назлы болынның.
Су өстендә — сары төнбоеклар,
Җыйган алар болын моңнарын.
Балык сыман, өнсез-телсез калып,
Мин аларның җырын тыңладым.
Чикерткәләр җырлый. Ишетәм күк
Әбиләрнең орчык эрләвен.
Бөтен дөнья бүген, туарылып,
Сөйли кебек күңел серләрен.
Һәр көтүче монда фикер йөртә
Фәлсәфәче галим шикелле.
Кояш көлә. Кояшның да йөзе
Нәкъ минеке төсле... сипкелле.
Таныйсызмы безне — полякларны? —
Болын кебек якты йөзебез.
Сез Польшаның бишегендә бүген,
Истәлеккә... чәчәк өзегез!

*

## ҖИМЕРЕК КҮПЕР

Җимерек күпер. Тик субайлар калган.
Аргы якка ничек үтәргә?
Өянкеләр һаман дәшеп тора,
Ә юл һаман илтә күпергә.
Елга ага, һаман кысылып ага,
Субайларны төреп яшелгә.
Елганың да бар бит үз хәтере,
Елга уен тирән яшерә.
Көл шикелле йомшак туфракта мин
Үткәннәрдән хәбәр эзләдем...
Көл-туфракта яңа үлән шыта,
Көл-туфракта — тояк эзләре.
Чыгар өчен елга аръягына
Күпер шәүләсеннән атладым.
Колагымда — тояк тавышлары:
Чаба кебек Хубаль* атлары.

*

**ЕЛГА ЯРЫНДА**

Учларыңа суын алсаң,
Карала куллар.
Агыза шәһәр елгага
Юынтык сулар.
Кармак та юк, калкавыч та,
Ишкәкләр ишми.
Елап арган акчарлаклар
Елгага төшми.
Аккошлар да башын сузган,
Теләнче сыман.
Яр буенда үскән таллар
Ишелеп сынган.
Иңри-иңри кага ярга
Кап-кара күбек.
...Яр буенда йөргән халык
Бер гамьсез кебек.

*

*О. Балюконитедан, Литва шагыйрәсе*

**МОГҖИЗА**

Чүлләрдә без тамчы су эзлибез,
Карый-карый күзләр ялыккан...
Кыш буена аквариумда ятып,
Әлсерәгән мескен балыктай.
Яратырлар, назлап иркәләрләр:
Син тыңлама. Алар сөйләсен.
Корыган агач кулын күккә сузган...
Яңгырдан соң белми үләсен.
Чүлгә китеп тамчы су эзлибез,
Көтеп җирдән олы могҗиза...
Ирек эзләп савытын ваткан балык
Бер тамчылап үзенә су җыя...

*

*Т. Кожомбердиевтан, кыргыз шагыйре*

## БЫЛБЫЛ ҖЫРЫ

Былбыл җыры — хисләр өермәсе,
Былбыл җыры — газап һәм рәхәт.
Былбыл җыры — тантана һәм сагыш,
Былбыл җыры — синең мәхәббәт.
Кем өйрәткән аңа мондый җырны? —
Шушы җырга күпме моң тулган!
Былбыл тынса, җаным бушап кала...
...Йөрәк оча аның артыннан.

*

## КЫРГЫЗЛАР

Әй тирбәлә җилдә кыргыз җыры,
Иңнәренә салып бар моңын.
...Керә алсаң кыргыз йөрәгенә, —
Дөнья сөйләр акын барлыгын.
Таулар бездә — күккә ашкан дивар.
Ә болытлар — дөя көтүе.
Кем көнләшмәс кыргыз турсыгына! —
Кымызында күк һәм җир тәме.
Хәтта күлләр шигырь яза монда,
Алатаудай хыял югары...
Күкрәгеңне тутырып бер суласаң,
Очып китәр, коштай, җырларың.

*

*Н. Заболоцкийдан, урыс шагыйре*

***

Күңелеңә һич тынгылык бирмә,
Күңел тиеш көн-төн эшләргә.
Ул хыялый бәхет эзләмәсен,
Кирәк түгел татлы төшләр дә.
Куып йөрт син аны өйдән өйгә,
Алып чык син аны урамга.
Кыяларга менсен, упкын күрсен
Һәм адашып йөрсен буранда.
Таң йолдызы күктә янган чакта
Ул ятмасын йомшак түшәктә.
Ялкаулыклар дер калтырап торсын! —
Син җаныңа тынгы күрсәтмә.
Күңелеңә ирек бирә калсаң,
Ишетерсең аның көлгәнен...
Озакламый, кызганусыз-нисез,
Салдырыр ул соңгы күлмәгең.
Күңелеңне һәрчак тезгендә тот,
Күрсәт аңа бөтен күрәсен.
Берь ялгызы түгел, синең белән
Кешеләрчә яши өйрәнсен!
Күккә менсәң, ул менәргә тиеш,
Җиргә төшсәң, тиеш төшәргә, —
Күңелеңә һич тынгылык бирмә,
Күңел тиеш көн-төн эшләргә.

*

*О. Высоцкаядан, урыс шагыйрәсе*

## ЧЫН ДУС КИРӘК

Караклыкның иң зурысы —
Ышанычны урлау.
Күңелләргә сакчы кирәк,
Кералмасын бурлар.
Син, ышанып, серләреңне
Бер дустыңа чиштең...
Ә ул уйнап-көлеп кенә
Серне җилгә чәчте.
Усал ният белән түгел, —
Булсын, диеп, кызык, —
Серне чиште. Менә хәзер
Сөйләшәләр кызып.
Уйнап кына, серләреңне
Чит кулларга бирде.
Кызык өчен... Ләкин хәзер
Ала алмый кире.
Чын дус кирәк. Күңелләргә
Кералмасын бурлар!
Караклыкның иң зурысы —
Ышанычны урлау.

*

*Д. Нәсибтән, азәрбайҗан шагыйре*

## ӘТИЕМ СУРӘТЕ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

Яу каплады илнең зәңгәр күген,
Ирләр китте канлы сугышка.
...Син үлгәнсең, әти, илгә, җиргә
Тугры булып соңгы сулышта.
Сагынам сине, бик сагынам, әти...
Күңелемдә яши сүзләрең.
Рәсемеңә карыйм, һәрвакытта
Сөйли кебек синең күзләрең.
Мин калтырыйм, янам, тиргә батам...
Ни сөйлисең? — килә беләсем.
Сагыш тулы йөрәгемдә, әти...
Ә син нигә һаман көләсең?
Ярты юлда калды салган йортың.
Кирпечләргә күптән мүк үсте.
Син кайда соң, әти, килче, күрен?!
Синнән башка күпме җил исте.
Һәр кирпече, ташы якын сиңа...
Без көтәбез, ә син һаман юк.
Син нигезен салдың шушы йортның...
Йортың исән, нигез һаман нык.
Сөйли кебек рәсмең. Синең тавыш
Тутыра күк өйнең бүлмәсен.
Мин яшьләрдән буылам, әти, әти —
Син рәсемдә һаман көләсең.

*

## УЕНЧЫК

Син сугышка киткән чакта, әти,

Бүләк иттең миңа уенчык.
Тиз кайтырмын, тик көтегез, диеп,
Китеп бардың, сүзләр куешып.
Саубуллашмадың күк син ул чакта,
Бер кырыйда калды эшләрең.
«Уйна, — дидең, — мин кайтканга кадәр,
Озакламый кайтып төшәрмен».
Дәресләре күп бит бу тормышның...
Йөрәгемә сыйды бар дөнья.
Онытылды курчак. Тормыш үзе
Курчак булды. Баттым мин уйга.
Уйный-уйный шундый онытылдым...
Уйнап кына өйдем тауларны.
Бер кырыйда калды балачагым,
Чәчләрем дә иртә чаларды.
Гел үзгәрә торды җирнең йөзе...
Уенчыклар җирдә күп икән.
Бик катлаулы тормыш уенчыгы...
Әле аңа бик тиз күнекмәм.
Үсеп җиттем, егет булдым инде...
Син күрмисең, ахры, белмисең.
Шул вакыттан бирле уйныйм, әти,
Уен бетми, син дә килмисең.

*

*Г. Остердан, урыс шагыйре*

**БЫРГЫЧЫ**

Ул җырлады безгә бер җыр:
«Канлы, — диеп, — күкләр».
Күпләр яратмады аны
Һәм яратты күпләр.
Ул батыр да түгел иде,
Ул булмады дус та.
Тик быргыда уйный иде
Барыбыздан оста.
Соңгы телем икмәген дә
Бирмәде ул дуска.
Тик... быргыда уйнаганда,
Керә идек утка.
Җыр ишеткәч, онытылды
Йөрәктәге җөйләр.
Безне яуга алып барды
Ул уйнаган көйләр.
Сугыш тынгач, тирәсендә
Яралылар ята...
«Җыр ошыймы?» — диеп көлә,
Итәгеннән тарта.
Ул батыр да түгел иде,
Ул булмады дус та.
Тик быргыда уйный иде
Барыбыздан оста.

*

*Ю. Семендердан, чуваш шагыйре*

## ЖЫРЛЫЙ ЧУВАШ

Жырлый чуваш, мактап жырлый
Туган якның басу-кырын.
Аяз күктә көлә кояш,
Отып ала дуслык жырын.
Жырлый чуваш... Дуслыктан да
Олырак хис жирдә бармы?!
Аның жыры дәшеп ала
Күршеләрне, туганнарны.
Жырлый чуваш. Канатлы жыр
Йолдызларга сәлам илтә.
Чуваш жыры, дуслык жыры
Галәмнәрне иңләп үтә.
Жырлый чуваш... Жаны ачык
Дөньядагы бар яхшыга.
Яктыра күк бөтен дөнья
Аның якты карашыннан.
Жырлый чуваш... Бәхет булып
Биек күктә йолдыз яна.
Дуслар белән бергә яшәү —
Жирдә иң зур бәхет аңа.

*

## ИКЕ ВЕТЕРАН

Дошман яный минем Ватаныма,
Кулын суза Идел-анага...
Яшь егетләр, иртә таңнан торып,
Жыелдылар якты аланга.

Өйрәнделәр алар сугыш серен,
Өйрәнделәр мылтык корырга...
Ядрә кебек кызды йөрәкләре,
Күңел — күптән сугыш кырында.

Беркөн пуля каен гәүдәсенә
Керде тишеп мишень карасын.
Яшь сугышчы сөртте каен яшен
Һәм бәйләде аның ярасын.

Озакламый егет китеп барды,
Керде егет ялкын эченә.
Ул ант итте яуда үч алырга
Үзе өчен, каен өчен дә...

Бүлә алмас илен беркем белән, —
Бүлешсә дә икмәк сыныгын...
Кул-аягы яраланган килеш,
Уттан чыкты егет чыныгып.

Туган якка кайтты Жиңү яулап.
Басу-кырлар аны сагынган.
...Агатуй*дан кайтып килгән чакта
Бер өн килде алан ягыннан.

Борылды да туры шунда китте.

Балкый каен якты аланда.
— Хәлең ничек? Син яралы идең
Безне яуга озатып калганда...

Сөйли каен, башын ия-ия:
— Сез киттегез илне сакларга...
Ә без көттек... Кайда иптәшләрең?
— Ятып калды ерак якларда...

...Ветераннар урман башынача
Житәкләшеп бергә чыктылар.
Солдат күкрәгендә — орден-медаль,
Каен түшләрендә — чулпылар.

*

*П. Афанасьевтан, чуваш шагыйре*

**ЖИҢҮ КӨНЕ**

Әллә инде үзем хәтерлимме?
Әллә инде әни сөйләде? —
«Сугыш бетте!» — диеп әйтте кемдер,
Селкетте күк шул сүз өйләрне.
Мин әтигә карыйм: торып басты,
Яраларын кысты. Дәшмәде.
Калтыранып куйды бар гәүдәсе,
Һәм тын гына тамды яшьләре.
Аннары ул, мине кулга алып,
Күтәрде дә чөйде югары
Һәм, онытып бөтен яраларын,
Жырлап узды, иңләп урамны.
Әйтерсең мин шул көн күккә аштым
Жиңеп кайткан әти кулыннан...
Ул очырды мине ил күгенә,
Кош язмышы бирде улына.

*

**ПЫЛСИРМА ***

Житмеш жиде инешең бар,
Пылсирма.
Чәчәкләр белән түшәлгән
Юл сиңа.
Син чувашның язмышы күк
Бормалы.
Кемнәр генә синдә чатыр
Кормады!
Ярларыңа сыенышкан
Авыллар.
Син аларны йолып калдың
Давылдан.
Житмеш жиде инешең бар,
Пылсирма.
Мәхәббәт белән түшәлгән
Юл сиңа.
Яулар килгән. Монда атлар
Кешнәгән.
Су эчкәннәр баһадирлар

Чишмәңнән.
Суың эчсәм, чистарам мин,
Яшәрәм.
Син өйрәттең җирдә җырлап
Яшәргә.
Балачактан җырың җырлап
Килешем.
Мин дә синең өр-яңа бер
Инешең.

*А. Калганнан, чуваш шагыйре*

**СИН БИТ КЕШЕ!**

Чиксезлекнең башын да син,
Азагын да күрмәдең...
Тик шулай да яшәү серен
Аңлый кебек йөрәгең.
Син акылга, аңга ия,
Күпне күрә күзләрең.
Чал гасырлар кичә-кичә
Олыгайдың, үзгәрдең.
Исеңдә дә юктыр хәзер
Таш балталы чакларың...
Син тәмугның үзен күрдең, —
Күрдең атом шартлавын.
Хыялларың җиргә сыймый,
Күккә ашты юлларың.
Син күктә дә дуслар белән
Бүлештең бар булганың.
Яманлыктан сакла Җирне, —
Җиргә кирәк тынычлык!
Чәчәк илт син Зөһрә кызга,
Ал Марсның кылычын.
Җирең өчен җаваплы син.
Син бит — Кеше! Син — батыр!
Син — Җир улы. Сакла аны...
Ә Җир сине яратыр.

*

*А. Лукиннан, чуваш шагыйре*

**ЧУВАШ КЫЗЛАРЫНА**

Таңнар белән бергә торгангамы? —
Охшаталар сезне таңнарга...
Сез — таң җыры! — безнең күңелләрдә,
Сез — таң нуры! — безнең җаннарда.
Җырларыгыз моңлы булгангамы? —
Охшаталар сайрар кошларга.
Бар егетләр әзер сезнең белән
Җырлар җырлап бергә очарга.
Чыккан чакта Идел буйларына,
Охшаталар зифа тирәккә.
Идел дулкыннары, ярга түгел,
Кага кебек сезнең йөрәккә.
Кич утырып гөлләр чиккәнгәме? —
Охшаталар сезне гөлләргә.
Сөю хисе — сезнең йөрәкләрдә,

Иң татлы сүз — сезнең телләрдә.
Кара төндә балкып янгангамы? —
Охшаталар сезне йолдызга.
Безнең хыял, мәхәббәтен эзләп,
Йолдызларга кадәр юл уза.
Язлар килеп, хисләр ташыганда,
Охшаталар сезне Иделгә:
Сез — Идел күк бәхет китерүче,
Нур өстәүче туган илемә.

*

*В. Шефнердан, урыс шагыйре*

***

Шундый сүзләр була, алар — яра кебек, алар хыял төсле,
Алар сине һәрчак саклап йөри, алар шундый көчле.
Бер сүз белән кеше дарга менә... Сүз үлемнән йола,
Бер сүз белән гаскәрләрне яуга кертеп була.

*

*М. Лермонтовтан, урыс шагыйре*

***

Җан газабын, акыл көрәшүен
Салкын сүзләр белән сөйләү авыр.
Рәхәтият илен кем күрсәтер,
Аны кемнәр генә көйгә салыр?
Илаһи зур хисләр тоям бүген...
Ләкин...
Сүз табалмыйм...

*

*П. Эйзиннан, чуваш шагыйре*

**АЙ**

Зәңгәр күктә йөзеп йөри
Түм-түгәрәк сары Ай.
Бу — Ай түгелдер шикелле,
Бу — йомарлам сары май.
Үтә көннәр, уза төннәр —
Күзгә күренеп кими Ай.
Айны кемнәр ашый икән? —
Ай түгел лә... бу бит — май.
Әле һаман уйлап йөрим:
«Кая китә соң бу Ай?»
Чоланда бер тычкан яши,
Айны шул ашый бугай.

*

*П. Руммодан, эстон шагыйре*

**КЕМНЕҢ ЭТЕ ЮК...**

Кемнең эте юк? —
Кулын күтәрсен.
Этең булмагач,

Такси көтәсең.
Әйдә, ку, шофер,
Юллар туп-туры.
Болгасын такси
Төтен койрыгын.
Каршыга чаба
Бөтен багана...
Ә мин, күз йомып,
Очам таганда.

*

## БАЛЫКЧЫ

*(Эстон халык җыры)*

Яр буе тулы халык.
Кармакка капмый балык.
Суалчаннар да симез...
Балыгын бирми диңгез.
Нишләтик бу диңгезне?
Тыңламый безнең сүзне.
Калмады тамчы түзем, —
Сукалап ташлыйк үзен.
Сукалап, чәчик арыш,
Үссен ул илле карыш.
Шаккатсын бөтен балык,
Нишләгән, дип, бу халык?..

*

*С. Шамкушанидан, грузин шагыйре*

## КАНАТ

Яңгыр төяп килде безгә
Зәп-зәңгәр болыт.
Чыңлады тамчылар көмеш
Кыңгырау булып.
Яшелләнеп, буразнада
Тишелде иген.
Игенче карт җиргә карап,
Иелгән бүген.
Як-ягына күз сала ул —
Матур бар тирә.
Туган як җире күңелгә
Бетмәс көч бирә.
— Саумы, әти! — дип кычкыра
Малае аның.
Үзе инде менеп җиткән
Башына тауның.
Талпына күңел очарга —
Күкләр бик биек!
Ә малае — әтисенең
Канаты кебек.

*

*Р. Бородулиннан, белорус шагыйре*

## АПРЕЛЬ

Кышка тигән, ахры,

Кояш нуры — камчы.
Күзләреннән әнә
Сытылып чыккан тамчы.
Көмеш тояк — апрель
Чабып килә каршы.
Туктап үлән эзли —
Ак-ак карны ашый.

*

*А. Васиннан, чуваш шагыйре*

**«ИКЕ»ЛЕ**

Бүген иртә таңнан бирле
Әти ачулы һаман:
— Кичә «ике»ле алгансың,
Нәрсә булды, Рамазан?!
Елый язып әйттем аңа:
— Гаепле, — дип, — икегез,
Мин берүзем нишли алам? —
Сез бит эштә идегез.
Моңа кадәр мәсьәләне
Чиштем әнидән сорап.
Дәрес әзерләргә, әти,
Бүген бит синең чират.
Әбиебез карт шул инде...
Кызганмыйсыз да аны.
Кичә, күпме тырышса да,
Әби «ике»ле алды.

*

*Х. Шировтан, төрекмән шагыйре*

**ТАҢ**

Зәңгәр яулык япкан иртә
Йокысыннан уянды.
Ул күзләрен ачу белән,
Алланып офык янды.
Һәм ул күрде шаян җилнең
Агачны уятканын,
Тулган Айның тау артында
Югалганын, батканын.
Аннан күрде юынганын
Чык белән үләннәрнең
Һәм ишетте чәчәкләрнең
Чылтырап көлгәннәрен.
Тыңлады ул тыпылдавын
Иң соңгы тамчыларның,
Кояш алтын кулы белән
Тәрәзә шакыганын.
...Таң күргәннең бөтенесен
Үз күзем белән күрдем —
Чөнки бүген, иртүк торып,
Болында уйнап йөрдем.

*

**МӘСЬӘЛӘ**

— Өч конфет бирермен сиңа,
Мәсьәләне күчертсәң...
— Үзең эшлә. Чишеп булмый,
Кешедән генә көтсәң.
— Дүрт конфет бирермен сиңа,
Күчерт, булма ла үчле.
— Алай булгач, дүрт конфетка
Өстәрсең тагын өчне.
— Мә алайса...
— Бирәү җитми...
— Бирмәм дә әле көлсәң.
Синнән сорап тормас идем
Шуларны куша белсәм.

*

*Я. Пиркулиевтан, төрекмән шагыйре*

## ЧЫПЧЫК

Шау чәчәк атты
Безнең алмагач.
Чыпчык җим эзли —
Әллә инде ач?..

Күзәтеп торам
Шушы чыпчыкны:
Оча да оча —
Ачуым чыкты.

Килә дә куна,
Алмый да уйга:
Алмагачның бит
Чәчәген коя.

— Кит моннан, — дим мин, —
Кит, — дим, — шаярма!
Югыйсә безнең
Бозылыр ара.

Куркытмак булып,
Алам кулга таш.
Ә ул туктамый,
Чыркылдый тоташ.

— Мин, — ди, — уйнамыйм,
Чүплим кортларны;
Кортларның миннән
Оча котлары.

Кортны кабам да
Ояма очам:
Балаларым тук,
Үсә алмагач.

...Һәм очты чыпчык —
Күккә үк ашты.
Ә мин, оялып,
Ташладым ташны.

*Ш. Чарыкулиевтан, төрекмән шагыйре*

## КУЯННАР

Таң сызылып килгәндә,
Мендек биек тауларга,
Кулларда безнең — капкын,
Исәп — киек ауларга.
Тау итәге-үзәнгә
Келәм җәеп куйганнар.
Шул келәмдә шаярып,
Уйнап йөри куяннар.
Бар дөньяны онытып,
Карап тордым аларга.
Күрмәде мине алар,
Якын булса да ара.
Менә соп-соры куян
Башын күтәрде: күрде!
Аннан чабып китте дә
Куаклыкка сикерде.
Маңгаема тир бәрде,
Бөтен тәнем ут кына —
Әй курыктым, куяннар
Эләгер дип, капкынга.
Оялдым мин шулкадәр
Тимер капкын куйганга.
...Үзем каптым капкынга,
Чапты-китте куяннар.

*

*В.Берестовтан, урыс шагыйре*

**КҮПНЕ КҮРГӘН БҮРЕК**

— Бүрек, бүрек, кая бардың?
— Кая булсын, киногa.
— Бүрек, бүрек, сөйлә әле
Ниләр күрдең син анда?
— Әй-лә, шунда, күрсәтәләр
Әллә нинди юк-барны.
Хуҗамның тезе өстендә
Рәхәтләнеп йокладым.
— Бүрек, бүрек, кая бардың?
— Кая булсын, кунакка.
— Бүрек, бүрек, кемне күрдең,
Сөйлә әле шул хакта?
— Әй-лә, шунда, чакырганнар
Әллә нинди юк-барны:
Кәпәч, таяк, эшләпә һәм
Чәчәкле зонтикларны.

*

*Рөстәм Кутуйдан*

**ӘКӘМ-ТӨКӘМ ҺӘМ МИН**

Үрмәләп әкәм-төкәм
Ишеккә килеп җиткән:
— Күршеләр ничек яши?
Ә мин көлеп җавап бирәм:
— Күк күкри, яшен яшьни.
Бик моңсу әкәм-төкәм,

Күзеннән сөртә яшен...
— Ник елыйсың, дускаем?
Кем куркытты? — дип дәштем.
— Кызганам сине, — диде,
Яшисең япа-ялгыз.
Кайгың булса, яшермә,
Яңгыр суында агыз.
Бара торгач үрмәләп,
Китерде сиңа юлым.
Картаеп беттем инде,
Күз яше белән тулдым...
Әкәм-төкәм белән без
Чәй кайнаттык, чәй эчтек.
Төне буе сөйләшеп,
Гомерне кабат кичтек.
Җиз самавыр янында
Бушады тулган күңел.
Безгә бүген дөньяда
Берни куркыныч түгел!

*

## КАР БАБАЙ

Язгы урамны буйлап,
Кар кызы йөзә уйнап.
Башында — тишек чиләк,
Үзе кычкыра көйләп:
— Юл бирегез! Мин киләм,
Күз яше аша көләм.
Алданмагыз, бу — аккош, дип,
Йә болыт диеп уйлап.
Язгы ташу суларында
Кар кызы йөзә уйнап.
— Исәнмесез!
— Саумысез!
— Күзләремә күренәме, —
Кар кызы бугай бит сез!
— Кайда яши Кар бабай,
Мин яраткан Ак агай?
Билдә — көмеш балтасы,
Кайда аның капкасы?

*

## ЙОРТ ИЯСЕ

Өй караңгы. Таңга кадәр
Йорт иясе йөренә;
Калак булып шалтырый ул,
Йә ут булып күренә.
Йә чикерткәгә охшатып,
Кубызында чиертә.
Үрмәкүчтәй үрмәли ул,
Табагач була түрдә...
— Мин, — ди, — бу йортның иясе,
Көн дә, төн дә саклармын.
Син мәктәбеңә соңлама,
Синең укыр чакларың.
Минем дустым — җен баласы

Дәфтәрләрең туздырган...
«Укымышлылык» ягыннан
Хәтта синнән уздырган.
Аңа миннән сәлам әйт! —
Минем эшләр бик әйбәт!

*

## ТӨНГЕ ӘКИЯТ

Карурманда бер йорт бар,
Колаклары — әрекмән...
Яши анда бер карчык,
Белмәгәне юк икән!
Өе тулы сер аның:
Кем елаган, кем көлгән,
Кем адашкан урманда,
Кайда яфрак селкенгән...
Аш пешерә, чәй куя,
Түрдә Шүрәле ята.
Кичен бии башлыйлар,
Аш һәм ботка ашыйлар,
Учак ягып гөрлиләр,
Утырмага йөрмиләр.
Шүрәле казан асты,
Кунак килеп чыкмасмы? —
Су анасы, Йорт иясе
Ярата идән астын.
Дуслары күп урманда,
Куян, кош-корт бар анда.
Бик ямансу чакларда
Бара алар — уты сүнгән,
Балалар йокыга түнгән
Тәрәз төбен сакларга.
Шык-шык тәрәз чиртәләр,
Аннан кайтып китәләр...
Әби белән карт Шүрәле
Ялгыз гомер итәләр.
Карурманда бер йорт бар,
Колаклары әрекмән.
Явыз карчык һәм Шүрәле
Шул йортта яши икән...

## ҮГЕЗ

Капкадан керде үгез,
Оран салды: «Мин — үгез!
Мин яратам үземне,
Сез дә мине сөегез!»
Тәгәрәде савытлар,
Кыт-кыт килде тавыклар:
«Таптар бит, карап торсак
Бу әзмәвер капкорсак».
Кәҗә сакалын селки,
Түтәлдән кишер йолкый,
Теш аралый эндәшә:
«Шул да булдымы күрше?!»
Бер көчек, ишек ачып,
Чыкты да өрә ярсып:
«Бу үгез — куркак үгез,

Хәзер кача, күрегез!»
Үгез башын селкетте,
Аннан борылып китте.
Мөгрәде: «Бала-чага
Аяк астында чаба!
Сезнең белән, юл куймый,
Бәхәсләшеп тә булмый.
Булмый!»

*

## СУКМАК

Елан кебек боргалана
Урманда сукмак.
Яңгырдан соң урман исен
Туймассың сулап.
Озата бара урман буйлап
Кояшлы каен.
Артка таба борылып карыйм
Эт өргән саен.
Мин йөгерәм. Сукмак чаба
Каршыма җилләп.
Мөлдерәеп карап кала
Күз яшьле җиләк.
Чикерткәләр, бал кортлары...
Бар җирдә — күзләр...
Тирә-юнь тын. Бу халәткә
Кем генә түзәр?!
Чабам, чабам күл ягына
Шул тынлык аша.
Анда — чыр-чу, анда — шау-шу,
Анда — тамаша!

*

## ИКЕ БАБАЙ

Ут чыгарып базарда
Бәрелде ике маңгай.
Бәрелмәде ике маңгай,
Бәрелде ике бабай.
Берсе идәнгә ауды,
Берсе тотты билбауны.
— Баегансындыр, ай-һай! —
Диде беренче бабай.
— Базар синеке түгел,
Мин дә бит акча түлим.
— Әйдә, алышып карыйк,
Кемнеке булыр сарык?
— Үгездәй булма алай, —
Дигән икенче бабай.
...Әле һаман шул килеш
Кулларына билбау тотып
Көрәшә алар, имеш!

*

## ӘТӘЧ

Кикрикләре уттай яна,

Очып килә каршыга,
Йөгерә дә менеп куна
Зәңгәр койма башына.
Койрыклары — төсле фонтан,
Атлап килә хан сыман...
Дөнья матур, кояш көлә,
Әтәч кенә ярсыган.
Көязләнә, ыспайлана,
Гүя карый көзгегә...
Ачыла бар тәрәзәләр,
Сүз артыннан сүз тезәләр:
— Канат кагып очып китәр!
— Түбәләрдән биек үтәр!
— Болытларга барып җитәр!
— Чү, ашыкма, түз генә!
Очмый әтәч болытларга,
Куна койма башына.
«Кикрикүк!» дип ул
Дусларын
Уятырга ашыга.

*

## БАЙЛАР САБАСЫ

Гүзәл Байлар Сабасы,
Килә мунча ягасы.
Бакчада үсә җимеш,
Монда халык, баскыч куеп,
Болытка менә, имеш.
Күктән төшкән кебек барсы:
Уен-көлке, җыр, көлеш.
Аю тунына ятып,
Төрек челеме тартып
Сөйләшәләр: «Һай, яхшы
Сабаның токмач ашы!»
— Һай, әйбәт, бигрәк әйбәт, —
Болытлар ага әйдәп.
Нигә безгә трамвай
Елмайганда күктә Ай?
Күзлим дисәң оҗмахны,
Күреп кит безнең якны,
Безнең күңелле чакны,
Безнең бәхетле чакны!
Байлар Сабасын Ходай
Сөеп-назлап яраткан,
Әйтерсең монда кешеләр
Әкият иленнән кайткан.

*

## ЧЕЛЛӘ

Тилмерә мескен бозау,
Бар дөнья уттай кызган.
— Кем мине бәйләп киткән?
Гаебем бармы икән?
Бау бәйләп каккан казык,
Йөрмәсен, диеп, азып.
Мөгри бозау: «Му да му!

Үлемемме әллә бу?»

*

## КӨТҮЧЕ

Мин — көтүче. Кәҗә көтәм,
Кулда — чыбыркы.
Чыбыркы тоткан беләкләр
Җәен чыныкты.
Сикерә дә менеп китә
Кәҗә гел өскә,
Коймаларны бәреп керә,
Күрсә кәбестә.
Мин — көтүче, солдат кебек
Һәрвакыт сакта.
Көне буе чаба торгач,
Кичкә аксата.
Тәмле була, татлы була
Чык төшкән үлән...
Ә кичләрен сыйланам мин
Җылы сөт белән.
Кәҗә көтәм. Үзем көтәм
Еллар үтүен.
Үсеп җиткәч, тапшырырлар
Сыер көтүен.

*

## УРМАН ИЯСЕ

Агач төбендә —
Урман иясе,
Кулында — кишер,
Куян диярсең...
Күзгә яшь килә,
Аптырап торам, —
Кайда чытырман,
Кайда карурман?
Чыжлый пычкылар,
Күмеп җир ямен...
Кайда чикләвек,
Кайда җиләгем?
Кайларга качыйм
Мотор шавыннан?
Җил булып елый,
Сыкрый карурман.
Урман иясе
Утырган төпне
Бульдозер сөреп,
Таптатып үтте.
Башыннан сыйпап
Килә сөясем, —
Табыгыз качкан
Урман иясен!

*

## ШӘП ТӘ СОҢ!

Үгез бозау урам буйлап

Чабып йөрде, уйнады.
Чабып килде, сөзеп атты
Урамдагы койманы.
Әй сөенде, әй куанды:
Имеш, ул шундый көчле!
Коймада зур тишек калды, —
Бер күзле дию төсле.
Бакча буйлап бара үгез,
Үләннән коеп чыкны.
Ә маңгае шул арада
Йодрыктай шешеп чыкты.
Койма карый ачуланып,
Бер сыңар күзе белән.
Ә бозау шат, бакчада бит
Тезеннән аның үлән.

*

## ХӘЙЛӘКӘР ӘТӘЧ

— Әтәч, әтәчкәй, кулларың кайда?
— Кайда булсыннар — кесәгә тыктым.
— Әтәч, әтәчкәй, чалбарың кайда?
— Кетәклектәдер... кичә югалттым.
— Үзең чалбарсыз... башында — кәпәч...
Оялды бугай шул чакны әтәч —
Әй китте чабып,
Суалчан кабып,
Тавыклар күзләп,
Чалбарын эзләп.

*

## БӘЙРӘМ АЛДЫННАН

Бәйрәм җитсә, бөтен дөнья
Төренә гел кызылга.
Уйлыйм, уйлыйм... Мин, ахрысы,
Бик акыллы кыз бугай.
Миңа дигән алъяпкычын
Утыра әби тегеп.
Үзе кебек эшләсен, ди,
Пычранмасын, ди, кебек.
Көн буе таган атынам,
Атынам — һаман туймыйм.
...Әни миңа борчак төшкән
Күлмәк алырга уйлый.
Бөтен дөнья белә кебек
Җирдә шундый кыз барын...
«Үз бүләгең кайда?» — дигәч,
Флаг төсле кызардым.

*

## ГАРМУН

Кичә иске гармун таптым
Үзебезнең чормадан.
«Тимә аңа, — диде әби, —
Әй, кулың тик тормаган!
Күрәсеңме, картайган ул,

Тавышы да карлыккан.
Ничек шәп биетә иде —
Сора бөтен халыктан...
Бабаңны көтте сугыштан...
Бир гармунны, бир, улым.
Син бүтәне белән уйна —
Менә — синең гармуның».

*

## ЭЧТӘЛЕК


Язмышка рәхмәт. *М.Галиев* .....................
«Елый-елый, сугыша-сугыша җирдә...» ..............

**Беренче карлыгачлар. 1962—1968**

«Маҗаралар дөньясында...» .....................
«Иң беренче төшкән карлар...» ....................
«Зәңгәр кабырчыклар эзләп килдең...» ................
«Язлар миңа сине китермәде...» ...................
Минем әти ..............................
Илле яшь тутырган абыйлар .....................
Гашыйк булгач ............................
«Аны миннән көннәр генә алды...» .................
«Җилләрне син күп күргәнсең, дисең...» ..............
Ал чәчәк ...............................
Миләүшәләр бәхет өләшә .......................
Саубуллашыр өчен баргач... .....................
Икебез дә алдадык... .........................
Вазада яз ...............................
Гармун уйныйсың ..........................
«Кыш бабайның һәрбер кызы...» ...................

**Зәңгәр кабырчыклар. 1968—1971**

Автобиография ............................
Кеше ..................................
Төсләр .................................
Җир белән саубуллашу ........................
Диңгездә ................................
Диңгез белән саубуллашу .......................
«Һәр көз саен таллар телсез калган...» ...............
Җиргә мәдхия ............................
«Дөнья матур Такташ җырлаганча...» ...............
«Егет икән, әйдә, егет булыйк!..» ...................
Тормыш ...............................
Метаморфозалар ............................
«Елмаерга өйрәтермен сине...» ....................
Вакыт .................................
«Төн карасына каләмемне манып...» ................
Картлар зары ............................
Мәхәббәт ...............................
Мәхәббәттә алданганнар җыры ....................
«Иң беренче...» ............................
Алмагачлы өйдәнме син? .......................
«Юкәнең балланып килгән...» ....................
...га ............................ ......
Алма .................................
Үтенеч ................................
Мин Кояшны сөйдем .........................
Соңгы үтенеч .............................
«Көз. Чибәр кызый...» ........................
Кояшка мәдхия ............................
«Хатларыңны утка яктым синең...» .................
Якорь .................................
Вәгъдә ................................
«Төне буе шигырь язып чыктым...» .................
Тау кызына ..............................
«Останкино. Җиденче кат күктә...» ................
Бумеранг ................................
«Мәскәү, Мәскәү...» ..........................

Яз ....................................
«Көзгеләрне, тәрәзләрне ваттым...» .................
Казан поезды .............................
Казан белән саубуллашу ........................
«Бу Мәскәүдә көннәр резина күк...» .................
Әнкәйгә хат ..............................
Мәңгелек ут ..............................
Самолетта ...............................
Күз ...................................
Яшьлек ................................
«Мин Лермонтов йөзгән күлдә йөздем...» ..............
Дисбе .................................
«Мин яу булып түгел, яучы булып...» ................
Үпкә ........................... ......
«Сәгатенә ничә шигырь туа...» ....................
Шагыйрь ................................
«Юмарт булыйк әйдә...» .......................
Көтү .................................
Авылда туй ..............................
Эпитафия ...............................
Шигырь язды абзагыз ........................
Мизгел .................................

**Яшен тамыры. 1971—1977**

«Мин яшьтәше атом бомбасының...» ................
Иске көймә зары ............................
Игенчеләр нәселе ...........................
«Яшьләрне бит галәм кызыктыра...» ................
Бер көнем ...............................
«Минем гомер әле башланмаган...» .................
Һәйкәлләр ...............................
Идел .................................
Аучы .................................
Бөеклек .................................
Бакчасарай фонтаны .........................
Яңа «Карурман» ...........................
«Карап торам шәһәр урамына...» ..................
Урман .................................
Тормыш сабантуе ...........................
Тормыш асылы ............................
Беренче кар ..............................
Кояш көлә ...............................
Бәхет .................................
«Кабул булмый нигә бар теләгем?..» ................
«Туктатып булмый ла вакытны...» .................
Диңгез дулкыны ...........................
Минем дошманым ...........................
Иң беренче тирәк ...........................
Декабрь ................................
«Шәһәр өстендә ак болыт...» .....................
Диңгездә ява яңгыр ..........................
Өмет .................................
Сабантуй ................................
«Онытылды инде күз яшьләре...» ..................
Язгы шигырь .............................
Сине озатканда .............................
Рельслар ................................
Чакырма ................................
«Бүген тагын мине ташлап киттең...» ................
«Бертуктаусыз уйный, шаярасың...» ................
Әкият .................................
Рәсем .................................
Кабатлана язлар ...........................
Гаепле .................................
«Сине эзләп, мин тауларга мендем...» ................
Тамашачы бугай... ..........................
«Син күрмисең, әйе, күрмисең син...» ................
Саубуллашу ..............................
Чәчәк бәйләме .............................
Яңгыр иле ...............................

**Ядкарь. 1977—1987**


Сөембикә манарасы ..........................
Кабан күле ..............................
Трамвайда ..............................
Кичке кояш .............................
Борынгы Болгарда ...........................
Казан вокзалы .............................
Сагыну ................................
Утлы хәтер *(Реквием)* ......................
Кырык беренче ел сабантуе .....................
Хатлар язам .............................
Сугыш икмәге .............................
Мәхәббәт һәм нәфрәт .........................
Егерме миллион ............................
Тормыш арифметикасы ........................
Язгы буран ..............................
Кайтабыз ...............................
Кыз сурәте ..............................
Тик минеке ..............................
Яшенле яңгыр .............................
Көз офыгы ..............................
Егет булдым .............................
Театр .................................
Күке авазы ..............................
Туган көндә .............................
Очрашу ................................
Кайтаваз ................................
Татар кызына .............................
«Карахмәтләр кирәк булса цирк өчен...» ..............
Бөекләр турында уйлану .......................
Моңсу шаяру .............................
«Минем турыда шигырь язмыйсың, дип...» .............
Көлү .................................


**Бер алманы бишкә бүләек. 1967—2006**


Ватаным ................................
Татарстан ...............................
Җиребезнең шәфкать туташы ....................
Кояшлы җыр .............................
Кайтчы, әткәй! .............................
Рамазан ................................
Бәхетем башкаласы ..........................
Иделем акчарлагы ...........................
Җиңүчегә ...............................
Идел суы ...............................
Бер алманы бишкә бүләек ......................
Таң җыры ...............................
Дулкын ................................
Ядкарь ................................
Юлларым ...............................
Чаптарым ...............................
Кызлар җырлый ............................
Сагынам ................................
Ләйсән ................................
Нигә, әни, нигә картаясың? ......................
Ява карлар ..............................
Насретдин ...............................
Кояш кемгә елмая? ..........................
Зәңгәр көймә .............................
Мәхәббәт сурәте ............................
Үзең килче... .............................
Сине күрсәм .............................
Сөйләмә мәхәббәт турында ......................
Кояштай елмай ............................
Үпкәләмә ...............................
Кайт син миңа ............................
Төсле җыр ..............................
Көтәм .................................
Йөрәк дәшә ..............................
Чаба поезд, чаба ............................

Иң якты йолдыз ............................
Кар кызы ...............................
Зинһар өчен, кермә төшләремә... ...................
Ташлык авылы җыры .........................
Акбүз ат ................................
Җитеннәр ...............................
Урман чишмәсе ............................
Ак пароход ...............................
Ай батканда, таң атканда .......................
Бишек җыры .............................
Җырлыйк әле .............................
«Татарстан» поезды ..........................
Кайларда бәхетле илләр? .......................
Моңланма ...............................
Әлифба .................................
Сау бул, җәй! ..............................
Сират күпере ..............................
Безнең җыр ..............................
Сәгать суга ...............................
Һай, дуслар ...............................
Көзге шатлык .............................
Соңгы чәчәк ..............................
Син генә ................................
Елмайсын сабыйлар ..........................
Язгы наз ................................
Саумы, Казан! .............................
Җыр чакыра ..............................
И машина, машина... .........................
Балачак ялкыны ............................
Балачакны сагыну ...........................
Алма сатам, чия сатам... .......................
Дуслык учагы .............................
«Әйдә барыйк, кызлар карыйк» ..............
Мин бер генә тапкыр яраттым ....................
Туачак кызыма, улыма ........................
Моңлану ................................
Сана, кәккүк, сана таңнарымны ...................
Яшьлегем канатында .........................
Кышкы учак ..............................
Хатлар көтәм авылдан ........................
Мәхәббәт дарулары ..........................
Бәхетем ачкычы ............................
Буранлы көннәрдә адаштым .....................
Карт өянке ...............................
Беренче мәхәббәт урамы .......................
Туган телдә дәшсәм генә... ......................
Оныт инде ...............................
Инеш ..................................
Елгалар саеккан чагында ......................
Мин бит синсез торалмам .......................
Илһам .................................
Кайтам инде дөнья урап .......................
Хөррият ................................
Мәхәббәтне җиргә яз китергән ....................
Бәхет нигә ерак? ............................
Сөембикә ................................
Соңгы мәхәббәт ............................
Сәйдәш моңы ..............................
Күктән иңгән бәхет ..........................
Кабан күле сыман ..........................
Балачагым ...............................
Сыктау .................................
Мин һаман ялгыз ...........................
Төнге учак ...............................
Сөйгәнем кайда? ............................
Бергә узыйк Казан урамын ......................
Яңа ел бураннары ...........................
Мин бит сезне сайладым .......................
Кайт, аккош, күлеңә .........................

Бәхет белән тулган көн .........................
Таң атканда тәрәз ачтым ........................


**Хыялый Мияубикә. 1962—1976**

Ни өчен? ................................
Уенчыклар ...............................
Хыялый Мияубикә ..........................
Елаудан үзе туктады ..........................
Санарга өйрәнгәндә ..........................
Барысын да яратам ..........................
Йокла, энем! ..............................
Хуш, иске ел! ..............................
Табигать балалары ..........................
Язгы урман ..............................
Кыярга кырау төшә ..........................


**Без — кояш балалары. 1976—1981**

Без — кояш балалары ..........................
Май кояшы ..............................
Соңгы кыңгырау ............................
Кыш ..................................
Яшә, көмеш кыңгырау! ........................
Урманда ................................
Туган ягым ...............................
Кошлар кайта .............................
Ярата икән әни .............................
Яңгырасын бөтен илгә .........................
Кышкы йокы .............................
Максат .................................
Мәңгелек яз ..............................
Гөрләвек ................................
Безнең диңгез .............................
Үпкәләгән ...............................
Минем сеңелем .............................
Кояш кебек ...............................
Курыкмыйм ..............................
Тегермән ................................
Тәрбияле малай ............................
Тизрәк кил ...............................
Җил ..................................
Кысла ..................................
Минеке .................................
Саескан .................................
Өч рәсем ................................
Песи төш күргән ...........................
Хат ...................................
Сәгать ..................................
Карга белән Кәҗә ...........................
Әтәч ...................................
Мәҗлес .................................
Гөлҗимеш ...............................


**Нур саласым килә сүзләремә. 1962—2006**

Музейда янгын .............................
Үзгәрергә! ................................
Чират ..................................
Агыйделдә боз китә ..........................
Кабул өстендә давыл. *(Юлъязма)* ..............
Тыйнаклык ..............................
Йолдызлар белән янәшә .......................
Батырлыкка мәдхия ..........................
Адаштым мин Кабул урамында ...................
Мин Җәлилне укыдым ........................
Солдат җыры ..............................
«Күздә моң, күңелдә торгынлык...» .................
Урман җыры ..............................
Олыларга бер сүз ............................
Авылга кайту .............................
Миңа бүген кырык ..........................
Җыр бәйрәме, моң бәйрәме бүген... ................
Үзебезгә кайтабыз ...........................

Трамвайда ...............................
«Батырлыклар турында язар идем...» ................
«Шатлыкларны үлчәп буламыни...» .................
Февраль чәчәкләре ..........................
«Диңгез буенда...» ..........................
Яшьнәп яшә! .............................
Мәдхия ................................
Кояш .................................
Кадый йөрәкләргә... .........................
Шагыйрьләр мәңге картаймый... ..................
Гайҗан бабай котлый... .......................
Миңнуллин театры ..........................
Җилле чак ул илле ..........................
Яшә, Әнвәр Хәйри! ...........................
Бердәнбер ...............................
Йөз яшә! ...............................
Якты йөзле Мөниргә .........................
Әйди безне Айрат ...........................
Түзсен генә йөрәк ...........................
Уза гомер, уза .............................
Үз туксаны туксан ..........................
Мәктәп булса, милләт яши ......................
Бер кайтырмын әле... .........................
Җидегән ...............................
Безнең язмыш .............................
Татфак барда җирдә татар бар ....................
Йолдыз булып тугансың .......................
Иңнәрендә аккош канаты .......................
Якташ ................................
Эпиграммалар .............................

**Шагыйрьләр мәҗлесе**

*Һ. Һейнедан*
«Киңәш биреп акыл өйрәттеләр...» .................
*Р. Гамзатовтан*
Минем гомер .............................
«Катылана торгач, металл булсам...» ................
Шигырь ...............................
*С. Есениннан*
«Син сөйлисең: «Сәгъди, диеп...» ..................
*Ф. Оңгарсыновадан*
«Күңел дулкыннарым синең ярга кага...» .............
Казакъ йолалары ...........................
Дустым ................................
Туган ил ...............................
Зоопаркта ..............................
Балык ................................
*В. Азаровтан*
Диңгез акчарлагы ...........................
*Л. Ошаниннан*
Әдәбият институтын тәмамлаган дусларыма ............
«Мин үземне гел яшь санап йөрдем...» ...............
Урманда ...............................
Сары колмак .............................
«Мин эшче дә булдым, җитәкче дә...» ................
«Нәрсә кирәк безгә бәхет өчен?..» ..................
«Син елыйсың... Нигә елыйсың син?..» ...............
«Кояш нигә сукыр тычкан өчен?..» ................
«Ә мин яшим. Бары мендәр белә...» ................
*А. Старостиннан*
«Мин — Себер, тундра улы...» ....................
«Бүлмәм минем ялгызлыктан тилмерүче йөрәк кебек...» ......
*А. омендантастан*
«Төн. Тынлыкка чумган бөтен дөнья...» ...............
*А. Бедюровтан*
Тулган ай әкияте ...........................
*А. Байзуллаевтан*
Зәңгәрсу кыялар ...........................
*А. Антоновичтан*
Яз белән саубуллашу .........................

*А. Гавриловтан*
Эзләр ..................................
Наратлар ................................
«Комнар кайный...» ..........................
*Ш. Алишевадан*
«Еллар үтә...» .............................
Берәүгә .................................
*М. Калмыкаевтан*
Сагыну .................................
*В. Портновтан*
Фронтовик агачлар ..........................
«Очрашырга иде йолдызда бер...» ..................
Дәфтәр турында баллада ........................
«Җилгә чәчеп мөлкәтен...» ......................
Үги ана яфрагы ............................
Әбиләр чуагы ..............................
Алмачуар чаптарым .........................
*Т. Матмуратовтан*
Әйтә идең ...............................
*О. Цокуновтан*
Йолдызлар коелганда ........................
*Н. Поляковадан*
Юл уртасы ...............................
*Г. Лоркадан*
Хушлашу ................................
Ай калыккан чакта ..........................
Гитара .................................
*Я. Ухсайдан*
Охшаталар мине татарга .......................
«Чәй эчәм — һаман суык...» .....................
*С. Мәҗитовтан*
Ирек таңы ...............................
Кызларга ................................
*Т. Адышевадан*
Шигърият ...............................
Мәхәббәтем ...............................
*Г. Галадан*
Истәлеккә чәчәк өзегез! ........................
Җимерек күпер ............................
Елга ярында ..............................
*О. Балюконитедан*
Могҗиза ................................
*Т. Кожомбердиевтан*
Былбыл җыры .............................
Кыргызлар ...............................
*Н. Заболоцкийдан*
«Күңелеңә һич тынгылык бирмә...» .................
*О. Высоцкаядан*
Чын дус кирәк .............................
*Д. Нәсибтән*
Әтием сурәте белән сөйләшү .....................
Уенчык .................................
*Г. Остердан*
Быргычы ................................
*Ю. Семендердан*
Җырлый чуваш ............................
Ике ветеран ..............................
*П. Афанасьевтан*
Җиңү көне ...............................
Пылсирма ...............................
*А. Калганнан*
Син бит — Кеше! ...........................
*А. Лукиннан*
Чуваш кызларына ...........................
*В. Шефнердан*
«Шундый сүзләр була...» .......................
*М. Лермонтовтан*
«Җан газабын, акыл көрәшүен...» ..................
*П. Эйзиннан*

Ай ....................................
*П. Руммодан*
Кемнең эте юк... ............................
Балыкчы (эстон халык җыры) ....................
*С. Шамкушанидан*
Канат ..................................
*Р. Бородулиннан*
Апрель .................................
*А. Васиннан*
«Ике»ле ................................
*Х. Шировтан*
Таң ...................................
Мәсьәлә ................................
*Я. Пиркулиевтан*
Чыпчык ................................
*Ш. Чарыкулиевтан*
Куяннар ................................
*В. Берестовтан*
Күпне күргән бүрек ..........................
*Р. Кутуйдан*
Әкәм-төкәм һәм мин ..........................
Кар бабай ................................
Йорт иясе ................................
Төнге әкият ..............................
Үгез ...................................
Сукмак .................................
Ике бабай ................................
Әтәч ...................................
Байлар Сабасы .............................
Челлә ..................................
Көтүче .................................
Урман иясе ...............................
Шәп тә соң! ...............................
Хәйләкәр әтәч .............................
Бәйрәм алдыннан ...........................
Гармун .................................

Литературно-художественное издание
**Валеев** Разиль Исмагилович
(**Валеев** Разиль)
ПРОИЗВЕДЕНИЯ
В ЧЕТЫРЕХ ТОМАХ

**Том 1**

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке
Әдәби-нәфис басма
**Вәлиев** Разил Исмәгыйлович
(**Вәлиев** Разил)
ӘСӘРЛӘР
ДҮРТ ТОМДА

**1 том**
Мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.П.Клипова*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, С.Н.Галимуллина*
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 24.10.2006. Форматы 84x108 1/32.
Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 27,72 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 28,77.
Нәшер-хисап табагы 16,17 + форз. 0,36. Тиражы 3000 д. Заказ З-921.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.